ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№1 (408)
ГЫЙНВАР 2026

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

КАЗАН МОГҖИЗАСЫ: КИЛӘЧӘК АЛАР КУЛЫНДА

4 612750 670011

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
Реклама 16+
WWW.PROTATARSTAN.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫН САТЫП АЛЫРГА

ozon.ru　　market.yandex.ru　　tatmedia.shop/ru

«ТАТМЕДИА» АЖ, 420066, ТР, Казан ш., Декабристлар ур., 2, ОГРН 1071690057843

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНДА РЕКЛАМА БИРЕРГӘ

Рәссам Л. Гамбургер эше. 1925 ел

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫН УКЫРГА

protatarstan.ru　　t.me/pro_tatarstan　　vk.com/protatarstann

Реклама 16+

№01 (408)
ГЫЙНВАР 2026

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Сафа Гәраев, Илсөяр Закирова, Ксения Сёмина, Фәнзилә Җәүһәрова, Николай Крушинин, Айдар Шәйхин, Гата Шамский
Фотографлар: Лилиана Вәлитова, Александр Ефремов, Дмитрий Сивков, Айдар Мөшәрәпов, Евгения Чеснокова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Казан шәһәре Совет районы Лицей – инженерлык үзәгенең 2025–2026 уку елында федераль һәм халыкара дәрәҗәләрдәге олимпиада һәм конкурсларда җиңүче һәм призёр булган укучылары һәм аларның остазлары. Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-2913
Басарга кул куелды: 19.01.2026
Чыгу көне: 23.01.2026

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ӘКИЯТЛӘР САНЫ

Басмабызның гыйнвар санында без сезне әкиятле Татарстанга чакырабыз. Әкият бездә – һәркайда, бары тик аны күрә белергә һәм фантазияңне эшкә җигәргә генә кирәк.

Казанда әкиятләрне тудыручылар, әкиятне өйрәнүчеләр һәм дөньяга танытучылар яши. Әкиятне өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә язучылар. Прозада да, шигырьдә дә теркәүчеләр. Әкиятне киндергә күчереп, сәнгать әсәренә әверелдерүчеләр. Мультфильм итеп җанландыручылар.

Әкият каһарманнарын җирле сынчылар да тудыра. Бу сыннар аннары Казаныбыз һәм республикабыз шәһәр-районнарының урамнарында, паркларында кунакларны, туристларны көтеп тора. Бергәләп сурәткә төшәргә чакыра. Әкият каһарманнары булган артистларыбыз да безгә кызыклы хәлләр турында сөйли, балачактан яхшы таныш әкият персонажларына әверелеп яшәп карауның сере белән бик теләп уртаклаша.

Әле без тагын әкият турында шуны да әйтә алабыз: ул уйдырма гына, билгеле, әмма һәрбер әкияттә дөреслекнең җиме бар, димәк, әкияттән гыйбрәт алырга икәнен дә онытмаска кирәк. Әкият ул – игелекле. Ул гел яхшы тәмамлана. Шуңа сезне Татарстан әкиятенә чакырабыз да инде – игелек һәм яхшылык дөньясына!

Сезнең әкият яратучы редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2026 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1998 сум 00 тиен китереп бирешле,
1939 сум 20 тиен соратып алганда.
2026 елга ТР буенча язылу бәясе:
3995 сум 90 тиен китереп бирешле,
3878 сум 29 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 105 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 105 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА

«БИК КУЕ БУЛГАНГА, МОНДА ҖЕН-ПӘРИЛӘР БАР, ДИЛӘР...»



Көндез генә ул агачлар агач булып күренә. Ә менә төнлә... Тул-
ган ай яктысында алар, терелеп, урман ияләренә әверелә, ди.
Казан артында яшәүчеләр әле һаман да моңа ышана, дип тә
сөйлиләр. Дөресме-юкмы, әмма шунысы тәгаен билгеле: сын-
чы Бакый Урманче, узган гасырның 70 нче елларында үз Шүрә-
лесен эзләп, нәкъ менә шул, Тукай сурәтләгән урманга барган:
«Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр; Төрле албас-
ты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр...» Сынчы, иптәшкә Кырлай
урманчысын да алып, бик озак эзләгән Шүрәлесен. Ниһаять,
тапкан! Ботаклы-чатаклы агачлар – әйтерсең лә яшеренеп
яткан ияләрнең үзе! Сынчы табигать тудырганны төзәтә генә –
һәм Шүрәлеләр җанлана! Әлеге урман ияләре хәзергә кадәр
Яңа Кырлай авылындагы Тукай музее янында ачылган паркта
яши!
Ышанмасагыз, үзегез барып күрегез!

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

8. Җирән клоун серләре
Арлекинны кем уйный

12. Халык авыз иҗаты
Әкият кайчан брендка әйләнә

18. Мультфильмда кунакта
Әкиятне ничек җанландырырга

22. Галәмнәр арасындагы күпер
Туган Батыр ничек таныла

28. Бакыр төсендәге тылсым
Су анасы кайда яши

32. Курчак театры
Могҗиза ничек туа

36. Миһербанлы ияләр дөньясы,
Яисә Шүрәле нигә моңлана

игелекле эшләр

42. Дөньяда иң шәп урын
Апаслылар ни өчен матурлык ярата

50. Әкиятме? Юк, чынбарлык!
Казанның киләчәге кайда тәрбияләнә

62. Гамьле әңгәмә
Сәнгатьне ничек саклап калырга

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

мәңгелек кыйммәтләр

68. Даһилар урыны
София Гобәйдуллина илһамны каян алган

72. Онытылмас исемнәр
Чыгътай татар тарихында нинди эз калдырган

76. Мәдәни календарь
Беренче татар китапханәсе кайчан ачылган

80. Татарстан авыллары
Полиглотлар кайсы авылда яши

88. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Вафа Бигәев йорты ничек сакланган

Фото: tatar-inform.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

26.12

Эльвира Нәбиуллина, Россия Үзәк банкы рәисе, – Казанда AAOIFI* вәкиллекле үзәген ачу уңаеннан видеоэлемтә буенча:

– AAOIFI стандартлары – хәзерге вакытта Россиянең актив икътисадый элемтәләре булган илләрдәге инвесторлар белән бер телдә сөйләшә алу мөмкинлеге ул. Казандагы вәкиллек AAOIFI оешмасының үзе белән дә, әлеге оешма әгъзалары белән дә һөнәри диалог алып барырга ярдәм итәчәк.

** AAOIFI – ислам финанс институтларына булыша торган хөкүмәтнеке булмаган оешма, аның төп максаты – бөтен дөнья буенча ислам банклары һәм финанс оешмалары өчен стандартлар эшләү һәм раслау.*

27.12

Андрей Никитин, РФ транспорт министры, – Казан авиация заводында:

– Импортны алыштыра торган Ту-214 самолётын җыя башлау илебез авиакомпанияләре өчен самолётларны серияләп җитештерүгә юл ача. План буенча «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе» ГАҖ 2027 ел ахырына егерме Ту-214 очкычын җыярга тиеш. Серияләп җитештерү яңа эш урыннары ача, төбәкнең һәм технологик компетенцияләрнең үсешен тәэмин итә.

ИГЕЛЕКЛЕ ӘШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР



23.12

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Рәисе, – Яңа ел алдыннан федераль һәм республика ММЧ вәкилләре белән очрашуда:

– Ислам дөньясы Россиядән йөз чөермәде. Әгәр безнең арадагы товар әйләнешенә күз салсак, аның яртысы диярлек ИХО илләренә туры килә. Без нефть химиясе һәм машина төзелеше продукцияләрен әлеге илләрдә танытырга телибез. Шулай ук туризм, спорт, мәдәният тармакларында хезмәттәшлек, уртак проектлар эшләү белән дә кызыксынабыз. Мәсәлән, Оманда Татарстанның сәүдә вәкиллеген ачарга планлаштырабыз.

Фото: Россия Банкының матбугат хезмәтеннән алынды; mintrans.gov.ru, tatarstan.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәләр /

мәңгелек кыйммәтләр

төп тема

Бу санда тәкъдим итәбез:

Арлекинны **кем** уйный

Әкият **кайчан** брендка әйләнә

Әкиятне **ничек** җанландырырга

Су анасы **кайда** яши

Шүрәле **нигә** моңлана

Әкияткә рәхим итегез!

«Татарстан»ның быелгы беренче саны әкияткә багышлана. Әкиятне тудыручыларга һәм аны сөйләүчеләргә. Әкиятне җыючыларга һәм өйрәнүчеләргә. Әкият каһарманнарына. Хәтта әкият һөнәре булган затларга...

Ни өчен әкият, диярсез, бәлки. Ә бик табигый: кыш, Яңа ел бәйрәме һәрчак әкият атмосферасына, тылсымга ышану, могҗиза көтү вакыты саналган. Әкиятләр нәкъ менә могҗиза турында сөйли дә бит!

Алар кешелекнең үзе белән бергә яралган, безне һәр чорда, дәвердә озатып килгән, авырлыкларны җиңәргә, алга атларга, өметне югалтмаска көч биргән. Әкиятләрдә яхшылык гел җиңеп чыга, димәк, дөнья гармониясе дә бозылмыйча, тигезлек какшамыйча кала.

Балачактан тыңлаган, яраткан һәм инде хәзер үз балаларыбыз, оныкларыбызга сөйләгән әкиятләр тылсымын тагын бер мәртәбә тояргa чакырабыз сезне.

Әкияткә рәхим итегез!

«МИНЕМ АРЛЕКИН, БЕРКАТЛЫРАК КҮРЕНСӘ ДӘ, ЗИРӘК УЛ»

Евгения Чеснокова

«Әкиятләрдә уйнау бик ошый. Мондый рольләрдән рәхәтләнеп тәм табарга була, җүләр сатарга, гомумән, ни теләсәң, шуны кыланып карарга».

Әнә шулай дип ачылып китеп сөйләде безгә Арлекин... дөресрәге, яңа гына кинотеатрларда чыккан киноәкиятнең каһарманы – артист Рузил Миңнекәев. Шуны да әйтергә кирәк: «җүләр сатып һәм ни теләсә, шуны кыланып», барыбызга да балачактан яхшы таныш образны ул искиткеч башкарып чыккан.

ҖИРӘН КЛОУН

Италиянең дель арте комедиясендә Арлекин персонажы, традицион күзлектән караганда, үтә дә тормышчан зат. (Алексей Толстой фильм-әкияте өчен курчакларны нәкъ менә шуннан алган бит). Шулай булгач, бу образда артист кинәнеп «җүләр сата» ала, билгеле. Әле тагын да күңеллерәк булып күренсен өчен, аның чәчләрен дә ут кебек җирән төскә буяганнар. Гримерлар бу төсне юа торган супершампунь бар дип ышандырганнар, ди. Димәк, Рузилнең җирәнлеге – вакытлы күренеш.

Фото: Евгения Чеснокова, kino-teatr.ru

Шулай да әкияти җирән төс тиз генә юылып төшмәгән, вәгъдә ителгән «эликсир»ның тылсымны җиңәргә көче җитмәгән, күрәсең. Рузилгә исә баштан ук җирән булу ихтыяҗы исәптә тотылмаган башка проектларда да «арлекинлыгын» кулланырга туры килгән.

БУШЛЫК БЕЛӘН ХИМИЯ

Кино төшергәндә кыенлыклар гримга гына бәйле булмаган.

– Графика күп кулланылган фильм булганга, уйнаганда катлаулы моментлар шактый булды, – ди ул.

Әйе, заманча фильм-әкиятләр – күп технология кулланылган тырыш хезмәт нәтиҗәсе. Әйтик, агач Буратиноны (ә ул фильмдагы бердәнбер чын актер уйнамый торган персонаж) яшь актриса Вита Корниенко җанландыра.

– Вита белән бергә өйрәнергә туры килгән бу технология белән мин үзем беренче мәртәбә очраштым, – ди Рузил. – «Аватар» диярсең. Буратиноның электр җепләре белән уратып алынган махсус костюмы бар иде, йөзендә дә – ниндидер ноктадар, шулар буенча персонажның мимикасы «укыла». Моны күзәтеп тору – шаккаткыч, билгеле!

Дөрес, экранда курчакны җанландыруга юнәлтелгән катлаулы графика нәтиҗәсендә, тере актёрларга еш кына бушлык белән уйнарга туры килгән.

– Партнёр урынына вакыт-вакыт бушлык белән эш итәргә, ничек тә бәйләнеш җепләре тартырга туры килде, – дип сөйли Арлекин-Миңнекәев.

ТЫЛСЫМЛЫ ШӘҺӘР ҺӘМ ДУРЕМАРНЫҢ СӨЙКЕМЛЕ СӨЯГЕ

«Буратино»ны төшерер өчен, Мәскәү янында аутентик Италия шәһәре мохитен тудыра торган бик зур декорацияләр төзегәннәр. Бу чыннан да әкиятне хәтерләтә иде, диләр артистлар.

– Эчке ягында йортлар, әлбәттә, бутафория, ә менә тыштан карасаң, каркаслары сокландыра – чын дип ышана башлыйсың хәтта. Без ул шәһәрдә урамнарны өйрәнеп озак йөрдек, мин хәтта андагы лабиринтларда адашып беттем, – ди Рузил Миңнекәев. – Телефонымны актарып карасагыз, галереяның яртысы нәкъ әнә шул фильмдагы шәһәр сурәтләре белән тулы.

Әле тагын бер серне ачарга кирәктер: чынлыкта, Миңнекәевнең фильмда бик тә, бик тә... Дуремарны уйныйсы килгән икән.

– Ул минем фильмдагы иң яраткан персонажым, – ди актёр. – Аның белән бәйле теге йә бу эпизодны ничек уйнап була икән дип, озак баш вата идем. Әмма Дуремарны уйнаган Лев Зөлкарнәев – бик оста актёр, мин аннан яхшырак уйный алачагыма ышанмыйм хәтта.

ӘКИЯТ ТӘМАМЛАНМЫЙ...

Рузил юкка гына әкиятләрдә төшәргә яратуы хакында әйтмәде безгә. Аның әле алда тамашачыны тагын ике проекттагы роле белән сөендерәсе бар. Дөрес, аларның берсен, нәкъ менә хәзер режиссёр Алинә Насыйбуллина төшергәнен, актёр, күбрәк авторлык киносына карый, ди. Әмма нигезендә «Шүрәле» әкияте ята. Ә менә чын әкият дигәне – «Руслан һәм Людмила. Тылсымлы сәяхәт». Анысы инде – чын уен киносы. Нәкъ менә «Руслан һәм Людмила» әкияте прологында Пушкин безгә әкияти Лукоморье турында сөйли бит.

Рузил Миңнекәев Пушкин әкиятендә Русланны уйный, димәк, аның әле алда явыз сихерче Черномор белән көрәшәсе һәм җиңәсе бар. Ай-һай, йөрәкләрне җилкетә бу тарих, колачлы булырга охшап тора...

ХИКМӘТЛЕ ӘКИЯТ...

Безнең Арлекиныбыз – яшь эти, шуны да онытмыйк. Ул үзенең өч яшьлек малаена да әкиятләр укырга ярата икән.

– Хәзерге баланың – үз әкияте, мин аларда берни аңламыйм, – дип көлә актёр. – Әмма төп әкиятләрне дә улымның белүен телим,

Буратино
6+

шуңа аларга аерым басым ясыйм. Һәрхәлдә, «Колобок» белән «Красная шапочка»ны без инде беләбез.

Буратино турындагы яңа экияттә дә аталар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр төп лейтмотив булып бара. Шуңа бу фильмны бөтен гаилә белән барып карау әйбәт.

Рузил үзе бу урында Бродский юлларына мөрәҗәгать итә:

«Мой Арлекин чуть-чуть мудрец,
Хотя простак на вид...»

Хәер, фильм белән бәйле бу фәлсәфи фраза бик тә урынлы, дип уйлыйм. Үзенең вайбы буенча яңа киноәкият китапның оригиналына гаҗәеп рәвештә якын булып чыккан. Карло Коллодиның Пиноккио турындагы тарихы турында әйтүем. Ә бит Алексей Толстойның «Алтын ачкыч, яки Буратино маҗаралары» үзе шуңарга барып тоташа.

Толстой сурәтләгән совет фильмындагы Буратиноның башбаштаграк малай икәнен без яхшы хәтерлибез. Ул әллә ни фәлсәфәгә бирелеп, тирән уйлануларга чумарга кирәк тапмый. Ә менә яңа экияттә төп каһарман берөзлексез яшәү мәгънәсе турында уйлана. Уйланып кына калмый, шөбһәләнә, борчыла, дөньяда үз урынын эзли. Һәм фильмның буеннан буена аңарга этисе Карло белән мөнәсәбәтләр тынгы бирми.

ӘКИЯТ ТЫҢЛАП ҮСКӘН КЕШЕДӘ КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНЫЧ БУЛА

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты халык иҗаты бүлегенең баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова татар әкиятләре, аларның каһарманнары һәм әкиятнең кеше тормышындагы роле турында сөйли.

ТАТАРНЫҢ БРЕНДЫ БУЛГАН ӘКИЯТЛӘР ТУРЫНДА

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондында тупланган әкиятләр саны меңнән артып китә. Тылсымлы әкиятләрдән «Камыр батыр», «Таңбатыр», «Ак бүре» иң популярлары санала. Тормыш-көнкүреш әкиятләре арасында «Зирәк карт», «Акыллы килен» күп вариантларда мәгълүм. Хайваннар турындагы әкиятләрдән «Торна белән Төлке», «Кәҗә белән Сарык»ны шунда ук искә төшерәбез.

Бренд булырлык әкиятләргә килгәндә, берничәсен генә аерып, алар популяр дип әйтү бик үк дөрес түгел. Чөнки һәр әкиятнең үз тыңлаучысы бар. Әгәр алар, меңнәрчә ел дәвамында халык хәтерендә сакланып, безнең көннәргә килеп җиткән икән, бу һәрберсенең популяр булуын күрсәтә.

Татар халкының күп әкиятләре, аларның геройлары бренд була ала. Әмма бер әйбер онытылырга тиеш түгел: алар – халык мирасы, бу образларга, әкиятләргә патент алырга омтылу бөтен халыкның рухи мирасына кул сузу була. Икенчедән, халык нигездә Тукай әсәрләре аша популярлашкан геройларны – Шүрәле белән Су анасын гына яхшы белә. Башка персонажларны һәм образларны да популярлаштырырга кирәк. Мәсәлән, Таңбатыр, Камыр батыр, Алпамыш кебек көч-гайрәткә ия каһарманнар, Тулпар ат, җил җитмәс Акбүзат, әкият героена ярдәмгә килгән Алып Каракош, кешеләрне терелтү көченә ия Яшәү суы, Алтын алма һ.б. Тормыш-көнкүреш әкиятләре каһарманы – тапкыр һәм зирәк Җирән чичән. Гүзәллек символы – Айда яшәүче Зөһрә кыз. Явыз персонажлар булса да, Дию белән Аждаһа да – үз геройларыбыз.

Әкиятләр буенча сыйфатлы, заманча анимацион фильмнар төшерелмәсә, алар интернет челтәрләрендә җанланмаса, брендка менеп җитә алмыйча югалачаклар.

ЯХШЫЛЫКНЫҢ ҖИҢҮЕ ТУРЫНДА

Кайсы гына әкиятне алсак та, ул яхшылыкның җиңүе турында. Кеше аларны тыңлаганда киләчәккә ышаныч белән карый башлый. Әгәр әкияттә яхшылык җиңми икән, бу әсәрнең нигезендә тормышның башка законнары ята, дигән сүз. Аларда геройларны җиңел генә яхшы, начар дип аерып та булмый. Кагыйдә буларак, бу төр әкиятләр мифологик хикәяттән башлангыч алган. Мәсәлән, Тукайның ике әкият-поэмасы – «Шүрәле» һәм «Су анасы». Шагыйрь популяр персонажлар турындагы мифологик хикәятләрне шигъри формага салган. Бу ике әсәрдә кайсы герой тискәре яки уңай дигән сорауга җавап бирү кыен. Шулай да, анализ ясап, төнлә урманга барган, табигать дөньясының тынычлыгын бозган егетнең яки ярамаган вакытта су коенган, Су иясенең тарагын урлаган малайның дөньялар арасындагы чикне яки гармонияне бозуын аңлау читен түгел.

ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕНДӘГЕ КАҺАРМАННАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТРАНСФОРМАЦИЯСЕ ТУРЫНДА

Әлбәттә, әкиятләрнең төп герое – батыр егет: Камыр батыр, Таңбатыр, Тимер Кендек һ.б. Ул, башка дөньяларга үтеп кереп, анда яшәгән Дию пәриен яки Аждаһаны җиңеп, урланган патша кызын алып кайта. Әкиятләрдәге егет – акыл, көч символы. Кайбер әкиятләрдә төп каһарман хатын-кыз да була. Әкиятләрдә хатын-кыз исә – зирәклек, матурлык, нәзакәтлек символы. Көч белән акыл, матурлык белән зирәклек, рухи кыйммәтләр-



Татар халык әкиятләренә иллюстрация. Рәссам Булат Гыйльванов. Татарстан китап нәшрияты архивыннан.

нең барысы бергә тормышта гармонияне сакларга ярдәм итә. Шуңа күрә көч дөньяга матурлыкны кайтару өчен көрәшә дә.

Тылсымлы әкиятләрдәге мифологик персонажлар – Дию, Аждаһа, Убырлы карчык, алардан башка әкият булмый. Беренче икесе үлеләр дөньясын гәүдәләндерә. Убырлы карчык – татар әкиятләренең иң кызыклы персонажы. Ул, ике дөнья чиге сагында торып, төп геройга киңәшләре белән ярдәмгә килгән, юл табарга булышкан зирәк карчык. Убырлы карчыкның «Үги кыз» әкиятендәге амплуасы «убыр» дигән мифологик персонажга якынрак. Ул – рус әкиятләрендәге Баба Ягага якын герой.

Әкият озын гасырлар дәвамында формалашкан, камилләшкән. Тексттагы сюжет, образ, һәр вакыйга, һәр реплика үз урынын алган. Бу сәгать механизмы кебек. Сәгать йөрсен өчен, һәр детальнең урынында булуы кирәк. Образлар яки сюжет трансформациягә дучар булган очракта, әкият җимерелеп төшәчәк. Алар консерватив жанр булганга гына, безгә кадәр килеп җиткән. **Хәзерге вакытта әкиятләрдәге аерым күренешләр, персонажлар балалар психикасына тискәре йогынты ясый дип, аларны үзгәртергә омтылыш сизелә. Бу да әкиятләрнең җимерелүенә китерелә. Ә җимерек әкият сөйләргә дә, укырга да кызык түгел, ул юкка чыга.**

БУ ТАТАР ӘКИЯТЕ, ДИП КҮРСӘТЕП ТОРУЧЫ БИЛГЕЛӘР ТУРЫНДА

Әкиятләр бик борынгы чорда, халыклар һәм милләтләр формалашканчы ук барлыкка килгән. Шуңа уртак сюжетларга корылган әкиятләр шактый. Алар галимнәр тарафыннан өйрәнелгән, тупланган һәм «Әкият сюжетлары күрсәткече» дигән хезмәт төзелгән. Мәсәлән, Ганс-Йорг Утер тарафыннан тулыландырылган «Халыкара әкиятләр күрсәткеченең» соңгысы 2004 елда дөнья күрде. Теләсә кайсы әкиятнең сюжетын шул күрсәткечтән табарга мөмкин.

Менә бу сюжет, билге татар әкиятенә генә хас дип аерып күрсәтү кыен. Шулай да берничә билгене атарга була. Мәсәлән, татар әкиятләре геройлары, башка халыкларныкыннан аермалы буларак, дивана, җүләрсымак түгел. Киресенчә, өченче яки төпчек ул үзенең акылы, зирәклеге, көче яки шәфкатьлеге белән аерылып тора. Икенчедән, күп кенә әкият геройлары белем алырга чыгып китә, мәдрәсәдә укый, һөнәр үзләштерә. Халыкның аң-белемгә омтылышы әкиятләрдә дә чыгылыш таптан. Өченчедән, татар әкиятләре мич башында көтеп ятарга өйрәтми. Геройлар үз тырышлыгы белән дөнья күрә. Әлбәттә, татар әкиятләрендә дә авантюрист геройлар аз түгел. Алар максатларына ирешү өчен төрле хәйләгә бара, шулай да геройларның гамәлләренә беренче чиратта эш-гамәл, тырышлык, максатчанлык хас.

ӘКИЯТЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАСЫ ТУРЫНДА

Борынгы әкиятләр балаларга аталмаган, шуңа күрә аларны тәрбия чарасы дип карау бу жанрның функцияләрен бик тарайта. Әкиятләрдә дидактика, ачыктан-ачык акыл өйрәтү очрамый. Әгәр бу күренеш очрый икән, ул соңгырак чорларда «бозылган» текст.

Әкият кешенең аңнан тыш халәтенә (подсознание) тәэсир итә. Бу тәрбия генә түгел, тормышка әзерләү, авырлыкларны җиңәргә омтылыш тудыру, иң әһәмиятлесе – кешедә үз-үзенә ышаныч барлыкка китерү. **Әкият тыңлап үскән бала борчу, кайгы, авырлыкларны җиңелрәк узачак.** Психологлар бала көткән аналарга да әкият тыңларга яки укырга киңәш бирә. Бу «әкият терапиясе» дип атала. Әкият тыңлап үскән балалар арасында үз-үзенә кул салу очраклары азрак булуын, кешенең беркайчан да тормыштан өмет өзмәвен дә әйтәләр. Дөрес, аның тагын бер шарты бар, **бала әкиятне дә, бишек җырын да әнисенең туган телендә тыңласа, ул көчлерәк тәэсир итә.** Ягъни баланың теле әнисенең туган телендә ачылырга тиеш. Шуңа күрә борынгылар туган тел дип түгел, ана теле дип атаганнар. Бары ана теле авазлары гына, тиешле нокталарны активлаштырып, баш миенә тәэсир итә.

ӘКИЯТЛӘРДӘГЕ ТАРИХИ ЧЫНБАРЛЫК ТУРЫНДА

Тарихи чынбарлыкны фольклорның тарихи жанрлары чагылдыра. Бу – риваятьләр, эпос, бәетләр, тарихи җырлар. Алар тарихи вакыйгаларны халык кабул итүе аша чагылдыра. «Әкият» сүзе татар телендә «уйдырма, ялган, сафсата» дигән күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла. **Шуңа күрә әкияттән тарихи чынбарлык эзләү кирәкле эш түгел. Алар халыклар тарихыннан күпкә борынгы.** Әмма фольклорның теләсә кайсы жанры күпмедер мәгънәдә тарихи да була ала. Мәсәлән, татар әкиятләрендә халык тарихының төрле чорына караган лексик берәмлекләр очрый: хан, би, патша, кол, бай, хезмәтче... Бу сүзләр ханлык, патшалык, колбиләүчелек, байлар һәм хезмәтчеләр булган чорларны раслый. Әкиятләр реаль тарихи шәхесләрнең исемен дә сакларга мөмкин. Мәсәлән, татар әкиятләрендә Зөлкарнәй патша исеме сакланган. Борынгы Македониянең мәшһүр патшасы Александр Македонскийны күпчелек мөселман халыклары Искәндәр Зөлкарнәйн буларак белә. Әмма аның әкияттәге образын тарихи дөреслек буларак кабул итәргә кирәкми.

ӘКИЯТЛӘРНЕҢ КЕМ ӨЧЕН БУЛУЫ ТУРЫНДА

Озак гасырлар буена әкиятләр өлкәннәр өчен сөйләнелгән. Профессиональ әкиятчеләр төрле халыкларда булган. Алар әкиятнең магик көченә ышанган. Әкият тыңлау рухи һәм гамәли-эстетик ихтыяҗга әйләнгән. Бер яктан, вакытлыча гына булса да әкият дөньясына күчү кешегә тормыштагы авырлыклардан, дөнья мәшәкатьләреннән арынып торырга ярдәм иткән. Икенче яктан, яхшылыкның явызлыкны җиңеп чыгуы, һәр ситуациядән чыгу юлы табылу ышаныч, өмет уяткан.

Татарларда оста әкиятчеләрне тыңлау да, әкият сөйләшү дә узган гасырның 70 нче елларына кадәр сакланган. Кайчакта бары берәү генә – әкият сөйләүче булып танылган кеше генә сөйли. Бу, кагыйдә буларак, яхшы хәтерле, талантлы кеше була. Андый әкият-

Татар халык әкиятләренә иллюстрация. Рассам Лотфулла Фәттахов. ТР Фәннәр академиясенең ТӘҺСИ архивыннан.

челәрне тирә-якта беләләр. Алар икенче авылларга барып та әкият сөйли. Кайвакытта әкиятне бер-бер артлы берничә кеше сөйли. Бу форма кыска әкиятләрне күз алдында тота. **Һәр әкиятче үзенең сөйләү үзенчәлегенә ия, һәркайсы әкиятне үз хисләре аша уздыра, мавыктыргыч итеп җиткерә.** Талантлы башкаручылар тылсымлы озын әкиятләрне берничә кичкә бүлеп сөйләгән.

Совет дәверендә әкият сөйләү традициясе сүнеп бару белән бергә, аның башкару рәвеше дә үзгәрә. Мәсәлән, Новосибирск өлкәсе Колыван районы Умар авылында 2017 елда узган экспедиция вакытында «юмакчы» Рөстәм бабай белән Миңнеәхмәт бабайны искә алдылар. Алар сугыш елларында салкын язда, балалар бөре җыйганда кызыгып эшләсеннәр, эшнең авырлыгын сизмәсеннәр дип, әкият сөйләп торганнар.

ӘКИЯТЛӘРНЕ НИЧЕК ТУПЛАУ ТУРЫНДА

Татар әкиятләрен халык теленнән язып алу, туплау XIX йөзнең беренче яртысында башланып китә. Мартиньян Иванов тарафыннан төзелеп, 1842 елда татар теле өйрәнүчеләргә кулланма итеп бастырылган «Татарская хрестоматия» җыентыгына татар әкиятләре дә кертелә. Татар әкиятләрен туплау эшендә рус һәм чит ил галимнәре бик актив була. XIX йөзнең икенче яртысында татар фольклорын туплауда милләте белән немец академик Василий Радлов зур эш башкара. XIX йөздә венгр галиме Габор Балинт Казан губернасының Мамадыш, Лаеш өязләрендә берничә әкият язып ала.

XIX йөз ахырына татар халык әкиятләрен халыктан язып алу эше тагын да җанланып китә, шактый гына әкият җыентыклары дөнья күрә, фәнни яктан өйрәнү буенча беренче омтылышлар ясала. Милли фольклорны өйрәнүгә татарлар кушыла. Бу елларда Габделгаллям Фәезханов, Таип Яхин эшчәнлеген аерып күрсәтергә мөмкин. Казан университеты профессоры, милләте белән хакас кешесе Николай Катановның 1898 елда нәшер ителгән «Материалы к изучению казанско-татарского наречия» дигән хезмәтендә унбиш әкият тексты да урнаштырылган. Татар әкиятләрен туплап халыкка җиткерүдә күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри зур эш башкара. Пётр Поляков белән берлектә 1900 елда татар халык әкиятләрен рус теленә тәрҗемә итеп, «Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов» дигән хезмәт бастыра.

XX гасыр башында әкиятләрне өйрәнү тарихында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның роле зур була. Тукай 1910 елда Казан шәһәренең Шәрык клубында «Халык әдәбияты» дигән темага лекция сөйли. Халык иҗатына багышланган бу лекциясендә ул, татар фольклористикасы тарихында беренчеләрдән булып, халык хикәятләренең язма әсәрләрдән аермасын күрсәтә. 1915 елда Гали Рәхим тарафыннан төзелгән «Татар әкиятләре», 1924 елда Михаил Васильевның «Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды» китабы нәшер ителә. 1921 елда Казанда беренче фәнни оешма буларак Гыйльми үзәк ачылу белән татар фольклорын туплау һәм өйрәнүдә яңа этап башлана.

ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕ ФОНДЫ ТУРЫНДА

Шулай да әкиятләрнең төп фонды узган гасырның 30–70 нче еллар аралыгында гына булдырыла. Татар әкиятчеләре буенча җыелган мәгълүмат та шул чорга карый. Әкиятләрнең традицион яшәү сферасы тарая бара, бу традиция акрынлап юкка чыга. Шуның белән бергә әкиятчеләрнең аудиториясе дә кими, әкиятләр елдан-ел азая бара, аларның сәнгатьчә ягы да уңайга үзгәрми, халык арасында әкият язып алу кыенлаша.

Татарстан территориясендә жанр үзенчәлекләрен саклаган соңгы әкиятләр 70 нче елларга кадәр язып алына. Себер татарларында әкият сөйләү традициясе озаграк саклана.

Әкият традициясенең юкка чыгуы аның яшь буынга күчмәве белән дә аңлатыла. Яңа буынга күчмәгән әкиятләр халык теленнән төшеп кала, онытылуга дучар була.

30 нчы еллардан татар халык әкиятләрен фәнни нигездә, фольклористика таләпләренә туры китереп җыю эшен Гомәр Бәширов башлап җибәрә. Бу эшчәнлекнең нәтиҗәсе буларак, әкиятләр аерым китаплар булып дөнья күрә. 1939 елда Казанда Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерү институты ачылганнан соң, татар халык иҗатын планлы рәвештә фәнни нигездә өйрәнү башланып китә. Татар халык әкиятләрен популярлаштыруда Хәмит Ярми зур хезмәт куя. Әлеге юнәлештә зур хезмәт куйган шәхесләрнең тагын берсе – фольклорчы Халидә Гатина. Ул, 1945–1969 елларда утыз фольклор экспедициясендә катнашып, йөзләрчә текст туплый, аерым китаплар чыгара. Бу эшне алга таба Ленар Җамалетдинов дәвам итә.

ӘДӘБИ ӘКИЯТЛӘР ТУРЫНДА

Әдәби әкият ул – язучы иҗаты. Язучы хыялында туган сюжет үз образлары, үз персонажлары белән үзенчәлекле. Минемчә, әдәби әкиятләрнең иң матур мисалы – Абдулла Алиш әкиятләре.

Әдәби әкияттә һәр герой, халык әкиятләрендә очраса да, яңа яктан ачыла. Бу әкиятләргә нәкъ менә тәрбия функциясе, ачыктан-ачык дидактика салынган. Әдәби әкият, асылда, югарыда атап үткән Абдулла Алиш текстлары кебек булырга тиеш. Әгәр язучы халык әкиятеннән килгән сюжетка, образларга мөрәҗәгать итә икән, ул аларны алга таба үстерергә, яңа яктан ачарга омтылсын иде. Мәсәлән, Нәкый Исәнбәтнең «Кырлай егете», «Җирән чичән белән Карачәч сылу», Туфан Миңнуллинның «Кәрлә – мәктәп баласы» әсәрләре шундый иҗатның күркәм мисаллары.

Халыкның кадерле кыйммәтләренә, төшенчәләренә саксыз кагылмавыбыз яхшы.



Татар халык әкиятләренә иллюстрация. Рассам Булат Гыйльванов. Татарстан китап нәшрияты архивыннан.

ӨЧТӘН АЛЫП ҖИТМЕШ ЯШЬКӘ КАДӘРГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН, ЯКИ МУЛЬТФИЛЬМ НИЧЕК ТУА

Фото: Евгения Чеснокова

Евгения Чеснокова

Әкиятне кем җанландыра ала? Шәп мультфильм төшерү кемнең хәленнән килә? Әле һаман күңеле сабыйлыктан чыгып бетмәгән һәм әкияткә ышануын дәвам иткән кеше генә сәләтле моңа, дип саный «Татармультфильм» студиясенең баш режиссёры Сергей Киатров. Тагын әле аниматор бераз сәеррәк һәм иртәдән алып төнгә кадәр эшләргә әзер булырга тиеш...

– Беләсезме, элек пиратлар ничек команда туплаган? Портка кереп, талау белән шөгыльләнергә теләүчеләрнең барысын да үзләренә чакырган. Без дә студия ачканда: «Кем мультипликация һәм юлбасарлык белән шөгыльләнергә тели – рәхим итегез!» – дип кызыктырдык. Моны безгә көлә-көлә баш режиссёр сөйли.

КҮКТӘН ИҢГӘН ӘҖӘЛ

– Мультфильм төшергәндә, – дип, бераз һөнәри серләре белән уртаклаша Сергей Киатров, – һәрвакыт тамашачыны шаккатырасы килә.

Моны ничек эшләргә? Әйтик, ниндидер гадәти булмаган әйбер уйлап табу. Мәсәлән, «Әлдермештән Әлмәндәр» исемле беренче тулы метражлы татар мультфильмын алыйк. Аны, әлбәттә, Туфан Миңнуллин пьесасы буенча Камал театрында озак еллар барган мәшһүр спектакль мотивлары буенча эшләгәннәр. Әмма мультфильм спектакль түгел бит, монда ниндидер яңалык кирәк, кабатланырга да ярамый, мәгълүм тарихны башкача күзаллау сорала. Һәм мультипликаторлар Әлмәндәр картны алып китәргә килгән Әҗәл образын үзләренчә баетырга була.

– Спектакльдә аның костюмына тәртип номеры язылган иде, – дип искә ала Сергей Киатров. – Һәм кинәт минем башыма мондый уй килде: әһә, димәк, ул теге дөньядагы бик күп «агент»ның берсе, димәк, анда тулы бер күк канцеляриясе эшли... Һәм без бу серле дөньяны күрсәтергә булдык: әлеге офиста босс та, секретарь кызлар да, төрле хезмәт күрсәтүче персонал да бар. Балаларга һәр җан иясе артыннан үз Әҗәле килүен аңлату өчен, тагын әле күселәрне алып китүче агентларны да өстәдек...

Ә Абдулла Алишның «Кем көчле?» әкияте буенча мультфильм төшергәндә, бу ярышны Сабан туе вакытында уздырырга, ә автор сүзләрен мультфильмның яңа персонажлары – батырлар ярышын шәрехләүче комментаторлардан әйттерергә булдык.

Һәм һәрвакыт шулай – яңа персонажлар, яңа локацияләр, сюжет борылышлары. Шул рәвешле китаптагы әкият анимация дөньясында яңача гәүдәләндерелә.

Дөрес, кайвакыт үзеңнең уйдырмага хокукыңны якларга да туры килә. Мәсәлән, «Чукмар белән Тукмар» мультфильмында ике сугыш чукмары, татулашкач, бер савыттан ашый башлый. «Экспертлар» шунда ук табыла, алар Киатровка: тормышта беркайчан да алай булмый, әтәчләр бер тагарактан ашамый, дип акыл өйрәтә... Режиссёр аптырый – бу бит метафора, сүз бит гомумән әтәчләр турында түгел... Ә беркадәр вакыттан соң ул, авылга баргач, ике генә түгел, хәтта берничә әтәчнең рәхәтләнеп бер савыттан ашавын күрә... Ә сез әкият, дисез...

ӘБИ ПАТША, КИСЕКБАШ ҺӘМ КАМЫР БАТЫР

Студиянең әйдәп баручы иллюстраторы Арина Симольскаяның компьютер экранында – китапханә, фәнни лаборатория рәсемнәре... «Татармультфильм» химик Арбузов турында сериал әзерли, ә экрандагы рәсемнәр, дип аңлата миңа Арина, фон, персонажлар төшереләчәк локацияләрнең сурәтләре. Төп герой галим булганлыктан, мультфильмның фоны аңа туры килергә тиеш.

– Арбузов шушымы инде? – дип сорыйм декорациядә сурәтләнгән берәүгә күрсәтеп. Миңа шелтәле караш ташлыйлар:

– Бу Бутлеров!

Мультфильмда берьюлы берничә бөек химик булачагын кем белгән соң...



Компьютер экранында – «Юл хәрәкәте кагыйдәләре планетасы» сериалының яңа эпизоды. Студия аны республиканың ЮХИДИ һәм «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» ДБУ хезмәткәрләре белән берлектә эшли.

Атаклы галимнәрнең мультәкиятләргә эләгүе очраклы түгел.

– Иҗатыбыз аша агарту, үзенә күрә бер мәгърифәтчелек эшен дә башкарабыз, – дип аңлата Сергей Киатров.

Чыннан да, студия мультфильмнарында Шүрәле, Кисекбаш, Камыр батыр, башка әкият персонажлары белән янәшә чын тарихи шәхесләр дә бар. Мәсәлән, «Ревизские сказки» (бу – мультфильм исеме генә түгел, белүебезчә, Россия халыкларының архив исемлекләре дә) дигәнендә тылсымлы архивариус, аңа тиешле язмаларны алып барырга комачаулаучы Албасты янәшәсендә Пушкин, Пётр I, Екатерина II пәйда була. Алар төп геройларга тарихны дөрес юлга кайтарырга ярдәм итә... Соңрак ул мультфильм персонажлары, Зөләйха һәм Роман, «Мирас угы» тулы метражлы анимацион лентасының геройларына әйләнә, анда да алар Татарстан тарихы сәхифәләре буйлап сәяхәт итә һәм әкият аша туган якның мәдәни мирасы белән таныша.

Ә менә студиянең яңа «Болгар легендалары» мультфильмында Казан тарихының Александр Кириллович Шмидт кебек мөхтәрәм, әмма бөтенләй диярлек онытыла барган персонажы пәйда була. XIX гасыр башында ул губерна архитекторы була, Болгар шәһәрлегенең үлчәү сызымнарын төзи. Тагын ул әле Казанны алуда һәлак булган сугышчыларга һәйкәл авторы да.

Дөрес, аның сурәте безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән, шуңа күрә рәссамнар Александр Кирилловичның тышкы кыяфәтен уйлап табалар. Киатров әйтүенчә, алар геройны Пушкинга охшатып ясаганнар – бакенбардлар, цилиндр... Ике Александр да бер үк чорда яшәгән бит.

Реаль тарих белән әкиятнең үрелеше мультипликаторларны хафаландырмый. Чөнки бөтен тарихи концепцияне үзгәртергә сәләтле ниндидер яңа сәхифәләр даими ачыла тора бит...

– Шулай булгач, кайвакыт тарихка да әкияткә ышангандай ышанырга туры килә инде, – дип көлә Сергей Киатров. – Дөрес, кайбер тарихчылар бу сүзләремә үпкәли дә.

– Үземне хәтерләгәннән бирле рәсем ясыйм, – дип сөйли безгә «Татармультфильм»ның баш режиссёры Сергей Киатров.

«КӘҖӘ БЕЛӘН САРЫК» БЛОКБАСТЕР БУЛАЧАКМЫ?

«Татармультфильм» студиясе эшли башлаганда биредә Габдулла Тукай һәм Абдулла Алишның нәни татарстанлыларга яхшы таныш булган һәм яраткан әкиятләрен экранлаштырганнар.

– Үземне хәтерләгәннән бирле рәсем ясыйм, – дип сөйли безгә «Татармультфильм»ның баш режиссёры Сергей Киатров. Мөгаен, төп казанышларыбызның берсе татар анимациясенең тулы бер мәдәни катламын булдырудыр, – ди Сергей Киатров.

Бу катламда башка халык вәкилләре дә бар. Мәсәлән, «Идел баһадирлары» циклында төрле халык геройлары – татар Камыр батыр һәм чуваш Иван батыр, рус Вольга һәм мордва Сабан, удмурт Селта һәм мари Маршан катнаша. Һәм һәркайсының тавышы кабатланмас, чөнки аларны Идел буе республикаларында эшләүче профессиональ артистлар тавышландырган.

Студия арсеналында Сахалиндагы коллегалары белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе дә бар – алар нивх әкиятләре нигезендә берничә мультфильм төшергән. Шул ук вакытта Татарстан мультипликаторлары тудырган әкият дөньясының үз йөзе бар, бу мультфильмнарны шунда ук танып була. Ә нәни тамашачылар мультфильмнардагы әкият геройларын гына түгел, студиядә уйлап табылган персонажларны – шул ук Роман һәм Зөләйханы да, светофорда яшәүче һәм балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтүче төрле төстәге кечкенә кешеләрне (бусы – «Татармультфильм»ның тагын бер мәгърифәтчелек проекты) дә ярата. Ә кызылак-яшел койрыклы Нефтяша тиене турындагы сериал (ул Әлмәттә яши, нефтьчеләр белән дус, Тимур исемле малайны һәм башка балаларны табигатьне яратырга һәм сакларга өйрәтә) инде 50дән артык күренештән тора.

Сергей Киатров исә инде яңа сюжетлар турында уйлана.

– Идеяләр бар, алар күп, – ди режиссёр. – Яңа сюжетлар да бар, искеләренең дә кайберләрен яңадан төшерер идем. Ә нәрсә, «Дисней» искене яңадан төшерә бит, ә без алардан кимме әллә?

Шулай да сер итеп кенә берсен әйтте: «Кәҗә белән Сарык» әкияте буенча тулы метражлы мультфильм төшерү нияте бар икән. Өчтән алып җитмеш яшькә кадәрге балалар өчен блокбастер. Ничек уйлыйсыз? Мин түземсезләнеп көтәм!

«Әлдермештән Әлмәндәр» мультфильмыннан кадрлар.

«Болгар легендалары» мультфильмыннан кадр.



Мультипликаторларга Александр Кириллович Шмидтның кыяфәтен уйлап чыгарырга туры килгән.

«ТУГАН БАТЫР» МОГҖИЗАСЫ

ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ НИЧЕК ГЛОБАЛЬ МЕДИАТРЕНДКА ӘЙЛӘНДЕ

Ксения Сёмина

«Туган Батыр» проекты милли әкият каһарманы тудыру идеясеннән башланып китә дә киң колачлы мәдәни экосистеманы барлыкка китерә. Федераль платформалардагы сыйфатлы 3D-анимация, әйдәп баручы нәшриятларда ясалган комикслар, халыкара фестивальләр һәм яңартылган Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында куелган премьера – болар барысы да максатка юлның дөрес салынганын күрсәтеп тора. Ә максат бер генә – тулы бер буынны милли кыйммәтләргә таянып тәрбияләү һәм татар мәдәниятен бөтен дөньяга таныту.

ДӨНЬЯКҮЛӘМ ПРЕМЬЕРАЛАРГА ТАБА

Зөлфәт Хәким тудырган «Туган Батыр» галәмен һәм проектын алга әйдәп баручы иң төп көчләрнең берсе – югары технологияле CGI-анимация. Бүгенге көндә анимация юнәлеше – гаять зур аудиторияне колачлап алырга мөмкинлек бирә торган корал ул. Ә «Туган Батыр»,

Фото: «Туган Батыр» проекты матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА. 0+

сыйфатлы медиапродукт буларак, моңа тулаем әзер. Татарстан тарихында беренче мәртәбә республикада ясалган анимацион сериал – әйдәп баручы федераль онлайн-платформаларда. Болар – «Кинопоиск», Wink, «Триколор», Kion. 2026 елның башыннан сериалның беренче ун чыгарылышын Okko платформасында да карап булачак.

– Федераль платформаларга чыгу безнең өчен җитди сынауга әверелде, чөнки бу инде – бөтенләй яңа дәрәҗә. Һәм без бу сынауны лаеклы рәвештә уздык. Гадәттә, мәйданнар сезон тулаем әзер булмаган килеш аны кабул итми, безнең очракта 26 серия турында сүз бара. Әмма контентның дәрәҗәсе гаять югары булганлыктан, безнең очракта платформалар искәрмә ясады. Моны профессиональ җиңүләребез дә раслап тора: без «Перекресток цивилизаций», «Алтын мөнбәр», «Каракүз фильм 2025» фестивальләренең, шулай ук «Знай наших», «Родная игрушка» бәйгеләренең лауреаты, җиңүчеләре, – ди «Туган Батыр» проектының авторы һәм нигез салучысы, шулай ук эшмәкәр, хәйрияче, «Туган авылым» милли комплексының гамәлгә куючысы Радик Абдрахманов. – Караучылар санын берничә ай дәвамында күзәтеп барачакбыз. 2026 елда тамашачылар «Туган Батыр»ны эзләгечләрдә үзләре тапсын өчен, ресурсларны әлеге юнәлешкә актив юнәлтәчәкбез. Безнең төп бурыч – җитештерүне дәвам итү, беренче сезонны тәмамлау һәм чит ил базарларына чыгу. Моннан тыш, гыйнвар аенда атаклы Россия киностудиясе белән тулы метрның сценарием эшләргә керешәчәкбез.

Федераль платформалар халыкара мәйданнарга юл ача. Проект командасының 2026 елдагы планнары арасында – «Туган Батыр»ны төрки-гарәп дөньясында актив таныту. Казан ислам дөньясының рәсми мәдәни башкаласына әверелгән икән, димәк, затлы, намуслы каһарман – чын батыр турындагы тарих мәдәни коды ягыннан безгә бик якын торган башка мәдәниятләргә дә якын һәм кызыклы булачак.

ӘКИЯТ СӘХНӘДӘ ДӘ ҖАНЛАНА

Озакламый «Туган Батыр» сәхнә пространствосында да гәүдәләнеш алачак. Һәм әле нинди генә сәхнәдә – Татарстанның киләчәген символлаштырган яңа Камалда, әлбәттә. Аның премьерасы 2026 елның 1 июнендә узарга тиеш. Бу премьера – сәхнә тамашасында өр-яңа канун булдыру, моңарчы күрелмәгән яңа киңлеккә чыгу, дип көтелә. Классика белән заманчалык призмасы аша эшли белгән режиссер Айдар Җәббаров проектка Казан белән Мәскәүнең иң шәп сценографлары, декораторлары һәм костюмерлары десантын туплаган. Режиссёрның үзе өчен бу проект кайсы ягы белән кызыклы? Бүгенге тамашачының йөрәген җилкендерә һәм бер пультста тибә алырлык итеп борынгы эпосны яңарту – әнә шул аның максаты.

– «Туган Батыр» проекты бик кызыклы. Бу куелышта милли колорит белән заманча сәхнә технологияләрен бер бөтенгә тоташтыра алу гаять әһәмиятле. Музыка, ут, драматургия, биюләр, костюмнар, сценография, видеомэппинг, трюклар – теләсә кайсы яшьтәге тамашачы да аңлап кабул итә алырдай тере легенданы җанландыруга хезмәт итәргә тиеш барысы да. Әкият кысаларында милли каһарманның үткән юлын заманча театр теле белән сөйләп бирү – бу бик катлаулы да, искиткеч мавыктыргыч та бурыч. Мин хәзер бу проектка баштанаяк чумдым һәм аны бик кызыксынып әзерлим, – ди Айдар Җәббаров.

КОМИКС – ТӨРЛЕ ДӨНЬЯЛАРНЫ ТОТАШТЫРУЧЫ КҮПЕР

Туган Батыр тулы бер буын өчен чыннан да үз каһарманына әверелсен өчен, супегеройлар турындагы франшизаларда тәрбияләнгән яңа заман балаларына график новеллалар теле аша мөрәҗәгать итәләр. Россиядә комикслар җитештерү буенча культ исәбендә йөргән BUBBLE нәшрияты традицион эпосны инде зәвыклы һәм кыю визуаль продуктка әверелдергән.

– «Туган Батыр»-ның миссиясе бик анык – заманча каһарман образы аша яшүсмерләрне туган мәдәнияте бишегенә, тамырларына кайтару, ана теле белән традицион кыйммәтләр рухында тәрбияләү. Иң катлаулы бурыч – этнографик аутентиклыкка ихтирамны саклап калып, бер үк вакытта заманча креативлыкны кушып җибәреп, алар арасында визуаль баланс булдыру. Комикс форматы каһарманның дөньясын, ул яшәгән көнкүрешне колачлырак чагылдырырга мөмкинлек бирә, юмористик мизгелләрне калкытып куя. Икенче пландагы каһарманнарны да яхшырак ачып, бу тарих белән без шулай киң аудиторияне җәлеп итә алабыз, – ди BUBBLE комикслар нәшриятының үсеш буенча директоры Нина Поцелуйко.

МӘДӘНИ КОДНЫ ЯҢА БУЫН ТЕЛЕНДӘ ҖИТКЕРҮ

Проектны үстерү һәм киң аудиториягә таныту белән хәзерге вакытта актив рәвештә нәкъ менә яшь буын шөгыльләнә: яшүсмер блогерлар, «Туган Батыр»ның балалар директорлар шурасы әгъзалары. Проектның үсеше, барышы турында сөйләп, алар иҗат потенциалын да тормышка ашыра, үзләре өчен туган мәдәниятен дә өр-яңадан ача.

Әминә Әхмәдьянова – «Татар кызы» бәйгесенең муниципаль этабы җиңүчесе, «Туган Батыр»ны һәм татар мәдәниятен ул үзенең креатив блогерлык юнәлеше белән кушып таныта.

– Мин Туган Батырны 100% танып белүләрен телим, бу тарих белән кызыксынуларын, китапларын укуларын, ә малайларның төп каһарманга охшарга омтылуларын. Нәкъ аның шикелле булдыклы, көчле, акыллы булырга теләсен иде бүгенге үсмерләр, – ди Әминә. Балалар белән олыларның үзара бер команда булып эшләве әлеге әкиятне замана балалары ихтыяҗларына якынайтырга бик нык ярдәм итә, шунысын да әйтергә кирәк. – Мин бу проектның амбассадоры булуым белән горурланам, ул миңа өр-яңа шәп дуслар, танышлар бүләк итте. Контент төшерү буенча да – кәттә тәҗрибә. Ә иң мөһиме – ул безнең команда, аның бер өлеше булу – искиткеч.

Алимә Вәлиева өчен бу проектка юл күптәнге сокланудан башланган. Ул «Туган Батыр» проектының үсешен күзәтеп торган, ә аннары проектның җитәкчесе Айсылу Җамалиева аны бу команданың бер өлеше булырга чакырган:

– Блогтинг өлкәсендәге тырышлыкларымны Татарстандагы шундый мәртәбәле проектның күреп алуы минем өчен зур дәрәҗә, – ди Алимә. – Миңа «татар вайбы» бик якын, бу әкияти галәмнең рухы да.

Бүгенге көндә ул үзенең күнекмәләрен кадрны әзерләү һәм монтаж ясау буенча сыный, шул рәвешле яшьтәшләре өчен туган мәдәниятне ачып бирә торган контент әзерли, аларны милли дөньяга якынайта.

– Һәр төшерү процессы җылы хатирәләр калдыра – Дәү әни белән кош теле әзерләү булсынмы ул, команда белән күмәк идеяләр тудырумы. Минем видеоларны күреп, хәтта сыйныфташларым да проект турында ныграк кызыксына башлады. Димәк, бу – безнең кечкенә генә җиңүебез. Радик Мөхәрләмович әйтмешли, «Туган Батыр» турында бөтен дөнья белергә тиеш! Проект зур кызыксынудан яралган, аның җылысын һәркем дә тойсын иде, дип телим.

МАҖАРАЛАР ФОРМАТЫНДАГЫ ЭПОС

Ассәль Сәлахова әйтүенчә, проектта катнашу аңа тарихка сәяхәтнең искиткеч кызыклы мәҗара булуын тоярга ярдәм иткән. Персонажларны ничек тавышландырулары, анимацияне ничек тудырулары турында роликлар төшергәндә, ул милли бизәкләр һәм музыка белән мавыгып киткән.

– Миңа төп каһарманнарның холык-табигатен анализлау, аларның көчсез якларын ачу, мөнәсәбәтләрен аңларга омтылу ошый. Алар бит әле бик яшь, димәк, бу егетләр һәм кызлар белән без дә бу тарихны яңадан кичерә алабыз. «Туган Батыр»ның безнең буыныбыз өчен дөньякүләм танылган аниме һәм сериаллар дәрәҗәсендә булуын телим, – ди Ассәль.

Ул киләчәктә дә шушындый абруйлы, киң масштаблы проектларда блогер буларак катнашырга һәм аларны таныту юнәлешендә эшләргә тели.

Проектның амбассадоры булып 2025 елда аңа кушылып киткән Ислам Хәбибуллин үзенең ролен заман шаукымында милли традицияләрне саклауда күрә:

– Кыска гына вакыт эчендә без төрле форматларда контент төшерергә өлгердек, – ди Ислам. Проектта эшләгәндә, аңа аралашучанлыгы, яңалыкларга ачык булуы, процесс белән чын-чынлап мавыкканлыгы ярдәм итә. – Видеопроектларыбыз аеруча ошый. Экранда үз эшеңнең нәтиҗәсен күрү бик рухландыра, алга таба да һөнәри яктан үсәргә этәргеч бирә. Минем тормышым тагын да кызыклырак, үзенчәлеклерәк булып эверелде. Аңлашыла да, чөнки мин рухы һәм омтылышлары бербөтен булган көчле команданың өлеше хәзер.

ЯСАЛМА ФӘҺЕМНӘН – МИЛЛИ ГАЛӘМНӘРГӘ

2026 елда проект яңа технологик һәм концептуаль дәрәҗәгә чыгарга җыена. Иң кыю инновацияләрнең берсе – җитештерү процессына ясалма фәһемне кертү. Команда инде ЯФ кулланып ясалган серияләр белән эшли. Шуның белән беррәттән, ул проектны физик яктан киңрәк җәелдерү процессына да зур игътибар бирә. Планнарында Алабуга шәһәрендә узачак уктан ату турниры гына түгел, ә Казанда узарга тиешле киң колачлы анимация

фестивале дә. Ул илдәге иң алдынгы креатив студияләрне берләштерүне күздә тота.

– Без бөтен дөнья күләмендә милли традицияләребезне сыйфатлы балалар продукты аша белүләрен телибез. Ә андый продуктны иң югары дәрәҗәдәге профессионаллар тудырырга тиеш, әлбәттә. ТР Мәдәният министрлыгы ярдәме белән җирле креатив индустрияләрне үстерү буенча инициативабыз кысаларында хәзер «Әкиятләр йорты» концепциясен тормышка ашырабыз. Ул биредә, Татарстанның үзендә, югары сыйфатлы анимация тудыручы белгечләр эзерли торган креатив үзәк булачак, – ди Радик Абдрахманов.

Бу стратегиянең гаять мөһим бер өлеше – «Туган Батыр» сериясендәге тәүге китапларны өр-яңа дизайн белән эшләп чыгару. Коллекция тулаем иң югары бизәлеш белән верстка стандартларына туры килә торган булырга тиеш. Контентны үстерү барышында безнең тагын бер зур игътибар биргән юнәлешебез – проектны реаль икътисади секторга рәсми лицензия аша кертеп эшләтеп җибәрү, тулы бер экосистема булдыру. «Туган Батыр» югары сыйфатлы продукция линейкасы эзерләү өчен нигез булачак, дигән сүз бу: балалар косметикасыннан алып уен тупланмалары, милли ризыкка кадәр.

ЛЕГЕНДА ШУШЫНДА БАШЛАНА

Проектның күңел ачуга юнәлтелгән компоненты да яңа дәрәҗәгә чыга: гыйнвар аенда «Туган авылым» милли комплексы территориясендә «Туган VIP» дип аталган яңа үзәк ачылачак. Бу – виртуаль чынбарлыкка гаилә белән сәяхәт итә торган урын. Үзәкнең пространствосы Туган Батыр дөньясы стилистикасында бизәлгән булачак: диварларда – китаплардан иллюстрацияләр, ә киләчәктә әкият персонажлары махсус VR-уен каһарманнарына әвереләчәк. Технологик аттракционнардан кала, мәйданчыкта балалар өчен активлык зоналары да каралган. Перспективада комплексның экосистемасы тематик квестлар һәм иҗади остаханәләр хисабына киңәячәк: биредә «Туган Батыр» әкияте персонажы – алтын куллы Гөлчәчәк хуҗабикә булачак.

– Болар һәммәсе дә проектны тулы канлы милли брендка әверелдерә. Әлеге бренд, нәниләрне Көнбатыштан кергән продуктлардан азат итеп, милли контент һәм товарлар белән тәэмин итеп, балачактан үсеп өлгергәнчегә кадәр тәрбияли алачак. Безнең үз каһарманнарыбыз вакыты җитте. Шулай булгач, Туган Батыр миллионлаган балалар өчен уңыш һәм милли традицияләргә тугрылык символына әйләнсен өчен кулдан килгәннең барысын да эшләячәкбез, – ди Радик Абдрахманов.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Туган Батыр» анимацион сериалы премьерасында.

КАЗ КАНАТЫ КАУРЫЙ-КАУРЫЙ...

Төрле халыкларда каз турында әкият-риваятьләр һәм җыр-такмаклар бик күп, алар безгә барыбызга да балачактан мәгълүм. Шарль Перро һәм Вильгельм Гауф әкиятләрендәге казларны да хәтерлибез. Ә менә шундый «каз әкиятләре»нең заманчасы белән декабрьдә Казанның «Туган авылым» комплексында таныштык.

Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый берләшмәсе «Каз өмәсе» бөтенроссия традицион фестивален үткәрде.

Фестиваль бишенче мәртәбә уздырылды, анда Татарстанның 26 шәһәре һәм районыннан, илнең 10 төбәгеннән килгән кунаклар катнашты. Бәйрәм бай ярминкә һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы белән тәмамланды, аннан соң Г. Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында Бөтендөнья татар конгрессының Татарстандагы җирле оешмалары җитәкчеләренең киңәйтелгән утырышы узды. Сөйләшәсе сүзләр күп, уртаклашасы тәҗрибә дә бар. Фестивальнең максатлары игелекле – татар халкының рухи һәм мәдәни кыйммәтләрен саклау, үстерү, борынгы йола бәйрәмнәрен яңарту, шәхси хуҗалыкларда кошчылык традицияләрен торгызуны пропагандалау.

Фото: Александр Ефремов

БАКЫР ТӨСЕНДӘГЕ ТЫЛСЫМ

Гата Шамский

Мойдодырның борынына чиртү, Шүрәле баласын табып алу, Шүрәле-әткәсен кытыклап көлдерү. Әле тагын «Хәзинәләр атавы»ндагы бер аяклы Сильвер белән аралашу, Крокодил Гена компаниясенә эләгү, Су анасына соклану һәм барысыннан да Яңа ел теләкләре кабул итеп алу… Ә боларның барысы өчен дә – өч көн һәм өч төн.

Чиста куллар – иң мөһиме шул. Яңа елда кулларыгыз гына түгел, уйларыгыз да, хисләрегез дә, гамәлләрегез һәм намусыгыз да чиста булсын!

Фото: Айдар Мөшәрәпов

Мондый экияти биремне сезнең хәбәрчегез Яңа ел алдыннан алды. Командировка акчалары урынына, гадәттәгечә, «хәерле юл!» дигәнне генә ишетте. Әмма бик җитди итеп шуны киртләп куйдылар: экият каһарманнары белән фотога төшәргә онытма! Ә яшәгән урыннарын картада билгеләп куй: кемнең дә булса кабат шушы юлны кабатлыйсы килсә, белеп барсын да эзләп тапсын… Нәрсә, баш тартырга, дисеңме? Юк, һич ярамый! Юлга!

МОЙДОДЫРЛАР НӘСЕЛЕ

Мойдодыр белән йөзгә-йөз Гаврилов урамында очрашабыз – бер супермаркетка керә торган парковкада. Эшләпә урынына – бераз яньчелгәнрәк таз, кашлар урынына – идән щёткасы, куллары сөлгедән үрелгән. Һәм инде фирма билгесе – борыны – бакыр кран… Бернинди дә шик калмый: бу – Мойдодыр! Аның игътибарны шунда ук җәлеп итә торган кыяфәтенә карыйм да бер уйны куып җибәрә алмый торам: тукта әле, безнең бит моңа кадәр дә кайдадыр очрашкан бар…

Әһә, исемә төште! Мәскәүдә, Сокольники паркында! Чынлап та дип, җавап кайтара миңа Мойдодыр. Мәскәүнеке – оригинал, ә Казанныкы җирле вариант икән. Ә менә Бөек Новгородта тагын да ераграк киткәннәр: Мойдодырга хатын да табып биргәннәр. Мойдодыриханы ясап куйганнар! Янәшәләрендә – нәни балалары – Мойдодырёнок та бар…

Казанда чисталык сагында торучы гаилә башлыгы инде борынын ышкудан туеп беткәндер: ул лампочка шикелле ялтырап тора. Ышкып карарга киңәш бирделәр миңа да, янәсе, уңыш китерә…

Ярар соң, уңыш бер дә комачау итмәс ул. Борынын ышкып караганнан соң, Мойдо-

дырга «Татарстан» журналы укучылары өчен Яңа ел теләкләре җиткерүен үтенәм. Бакыр йөзе шунда ук яктырып китә чисталык саксчысының:

– Чиста куллар – иң мөһиме шул. Яңа елда кулларыгыз гына түгел, уйларыгыз да, хисләрегез дә, гамәлләрегез һәм намусыгыз да чиста булсын!

«ПИАСТРА, ПИАСТРА, ПИАСТРАЛАР!»

Окорок кушаматлы бер аяклы пират Джон Сильверны безнең Алабугага нинди җилләр китереп ташлагандыр, анысы шул җилнең үзенә генә мәгълүм, күрәсең. Бу явыз затны мин иске шәһәрнең музей ишегалдында әле җәй көне үк күреп алган идем. Капитан Флин дигән попугае да утыра иңендә. Хәтерлисезме, аның берөзлексез: «Пиастра, пиастра, пиастралар...» – дип такмаклап утыруын? Бу икәү кирпеч дивар янына чүмәшкәннәр дә, мәкерле елмаеп, һичшиксез, ниндидер ният корып маташалар.

Пиратлар гомер-гомергә булмаган гади генә провинциаль калада бу инглизнең пәйда булуын яхшыга юраргамы, кем белгән... Һәрхәлдә, аның монда Яңа ел яки Раштуа бүләкләре тарату өчен килмәгәнлеге көн кебек ачык. Хәер, хафага төшәргә ашыкмыйк. Бәхеткә, янәшәдә генә «Хәзинәләр атавы»ның чып-чын геройлары – капитан Смолетти белән доктор Ливси да бар булып чыкты. Димәк ки, бер аяклы Сильверга мәкер кылырга ул кадәр үк күп форсат калмый. Дөресен генә әйткәндә, ул Сильвер сәеррәк тә әле. Стивенсон китабындагы пиратның сул аягында шыксыз агач булса, мондагы Сильверның уң аягы – агач. Хәер, екияттә мондый гына сәер хәлләр булгалый инде, бәйләнеп тормыйк...

Кызык, безнең укучыларга бер аяклы Джо нәрсә теләр иде икән? Менә болай дияр иде, мөгаен:

– Яңа елда хәзинәләр эзләргә кузгаласыз икән, тукталып калмагыз. Әмма 25 процентын дәүләт казнасына кайтарырга да онытмагыз, шунсыз булмый. Алар белән көрәшү хәтта минем дә хәлемнән килми...

–Яңа елда хәзинәләр эзләргә кузгаласыз икән, тукталып калмагыз. Әмма 25 процентын дәүләт казнасына кайтарырга да онытмагыз, шунсыз булмый. Алар белән көрәшү хәтта минем дә хәлемнән килми...



–«Көч булышмаган урында акыл булышыр...»

«КЕТИ-КЕТИ УЙНЫЙКМЫ?»

Салкын тәкәббер кыяфәт, каршы сөйләшкәнне өнәмәгән университет профессорларын хәтерләткән йөз... Кабан күле буендагы Шүрәле үзе болай Габдулла Тукай сурәтләгән образ шикелле үк куркытмый. Югыйсә бөек шагыйрь әкиятен укып, аңардан чынлап та шүрләп төшәргә мөмкинсең. Күрәсең, Кырлай Шүрәләләре Казанныкына караганда кырысрак, усалрак булгандыр... Казанныкын да матур дип әйтә алмыйм, билгеле, әмма бөтенләй кот очып: «Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу? Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!» – диеп тә булмый. Тукай язганча, «маңлаенда урта бармак буйлыгы мөгезе» бар-барын, тик ул явыз көч билгесе булып күренеп тормый, килбәтен дә бозмый Кабан буе Шүрәләсенең. Киресенчә, аның үзенә күрә бер ыру билгесе кебегрәк тәэсир калдыра... Татар урманыннан чыккан Мефистофель диярсең!

Хәер, һәркемнең үз Шүрәлесе бугай ул. Сынчы Асия Миңнуллина аны менә шушындый итеп күргән. Ә Түбән Камадагы Тукай паркында бөтенләй башка Шүрәле тора. Әллә алар ягы-ягы белән аерыла инде шунда? Түбән Каманыкы артык мут картлачны хәтерләтә, әле җитмәсә, шыксыз койрыгы да бар... Казанда «Туган авылым» комплексындагысы – озын бармаклы, Көнчыгыш әкиятеннән чыккандай кысыграк күзле...

Шагыйрь сурәтләгән образга иң якыны Әлмәттәге Шүрәле, ахрысы, – аның бармаклары, Тукай әйткәнчә, «төз түгел... ботак-тармак кеби», үзләре ярты гәүдәсенә чаклы җиткән. Колаклары да алагаем дәү, ә мөгезен инде әйткән дә юк... Ул чынлап та очраган кешенең котын ботына төшерер иде, мөгаен. Әгәр гәүдәгә дә зуррак булса... Ник дисәң, Питердан килгән сынчы Павел Игнатьев бала Шүрәләне ясаган. «Бу кап-кара урман» экспозициясендә Шүрәле баласы велосипедның багаж кәрҗинендә утыра, ә рульдә – татар халкының күренекле әкиятен тудырган шагыйрь үзе.

Шулай да, Кабан буе Шүрәләсенә әйләнеп кайтыйк әле. Ни генә дисәң дә, ул халыкта иң билгелесе. Аның мөгезен ышкысаң, шулай ук уңыш килә, ди. Моны гидлар һәр туристка сөйли. Бездә әкиятләргә ышанырга яраталар. Кояшта ялтырап торган мөгез дә шуны раслый. Ә инде Шүрәле утырган таштагы сүзләргә килсәк, аларны «урман сарыгы»ның безгә теләге дип кабул итәргә дә була:

– «Көч булышмаган урында акыл булышыр...»

«МОГҖИЗА КӨТӘҺӘРКЕМ ДӘ...»

Без балачакта карап үскән мультфильм геройлары да Алабугада табылды бит әле. Бу – Крокодил Гена белән Чебурашка. Алар балалар паркында эскәмиягә кунаклаганнар да тыныч кына җыруларын сузып утыралар: «Медленно минуты уплывают вдаль, встречи с ними ты уже не жди...».

Чебурашканың дөньядагы иң дәү һәм шаккаткыч колакларын сыпырганнан соң, җир йөзендәге иң куркыныч булмаган крокодилны кочып алып, мин паркның исеме дә Эдуард Успенский каһарманы исеме белән аталганын күрдем – «Чебурашка». Тик менә бу композициянең авторын гына белеп булмады.

Хәер, Алабугадагы Чебурашка һәм Крокодил Гена бердәнбер түгел икән. Ерак түгел генә – Зәйдә дә – Гена һәм Чебурашка бар икән. Аларны җирле рәссам һәм сынчы Фазыл Шиһапов ясап куйган.

Ярар, бу ике дусның Яңа ел теләкләре нинди икән? Сорап карыйк әле. Менә нәрсә ди алар:

– «И хотя нам прошлое немного жаль, лучшее, конечно, впереди...»





СУ АНАСЫНЫҢ АЛТЫН ТАРАГЫ

Су анасы белән очрашуны махсус азакка калдырдым. Игорь Башмаков атлы гаҗәеп талантлы сынчы тудырган әкият героинясын эзләп азапланырга кирәкми. Ул Казанның һәм Татарстанның үзәгендә утыра – мәркәзебезнең Бауман урамында. Ак кар каплап киткән мәйдан, әйтерсең, ак комлы яр буе.

Су анасының холык-фигыле, бу сынга караганда, шактый кырыска охшаган. Әмма ул Тукай сурәтләгәнчә үк куркыныч һәм иләмсез тоелмый. Бу Су анасы, билгеле, артык хисчән ханымга охшамаган. Әмма кырыслык бит әле явызлык дигән сүз түгел.

Ә менә бакыр гүзәлкәйнең аяк очында яткан тарак – нәкъ Тукай әкиятендәгечә. Шул бит инде малайны ымсындыра... Димәк, Су анасы да – Тукаебызныкы. Кая әле, бу кырыс су гүзәленнән Яңа ел теләкләрен белешеп карыйк, ни дияр икән? Җавап бирерме? Шунда ук кистереп салды Су анасы:

– Яшәгез, эшләгез, гел алдынгы булыгыз! Үзегез эшләп тапканны алыгыз, кешенекенә тимәгез! Шунда гына чын-чынлап бәхетле булырсыз!

ТРның атказанган артисткасы Татьяна Сорокина Королева ролен башкара.

КУРЧАК ТЕАТРЫ МОГҖИЗАСЫ

Евгения Чеснокова

«Гер-р-да, сезнең Кай – ул безнең Пр-р-ынц, дип уйлыйм», – ди Карга «Әкият» Татар дәүләт академия курчак театры сәхнәсендә куелган «Снежная королева» спектаклендә. Һәм шунда ук аңлап аласың: бу бит сарай даирәсендәге ханым – телендә француз авазларының чагылышы да шуннандыр... Һәм менә шул ук спектакльдә кыю Атаманша башкисәрләр төркеме белән дә җитәкчелек итә: «Яле, тиз генә табышны китерегез!» Һәм шунда ук күз алдыңа үткен, үтә дә таныш базар апасы образы килеп баса...

Фото: Евгения Чеснокова, «Әкият» курчак театры архивыннан

Әлеге ике рольне дә спектакльдә бер актриса – Татьяна Сорокина башкара. Ул төрле образлар иҗат итәргә ярата, һәм курчак театрында утыз елдан ар-

«Көлсылу» әкиятендә Татьяна Сорокина Үги ана ролен башкара.

тык эшләвенә карамастан, нәкъ бала чактагыдай әкиятләргә һәм могҗизаларга ышана.

ӘКИЯТИ ҺӘМ ОЧРАКЛЫ ТҮГЕЛ

– Театр училищесының курчаклар бүлегендә укый башлаганда, кинәт шуны аңладым: мин җиденче сыйныфка кадәр диярлек курчак уйнарга ярατканмын бит, – дип искә төшерә Татьяна Сорокина. – Миңа курчакларны җанландыру ошый, алар бит синең тавыш ярдәмендә «тереләләр».

Әлбәттә, башка бик күп кызлар кебек, ул да драма актрисасы булу турында хыяллана. Ләкин укырга кергәндә аның типажындагы кызларны драма бүлегенә алып өлгергән булалар. Татьяна курчак театры актрисасы булырга карар кыла. «Әлеге карарыма беркайчан да үкенмәдем!» – ди актриса.

Татьяна сүзләренә караганда, курчак театрында эшләү хәтта катлаулырак та әле. Без күнеккән классик актёр ым, мимиканы куллана ала. Ә менә курчак театрында тамашачы гадәттә артистның йөзен күрми, ләкин аның тавышы тәэсирендә курчакның йөзе ничек «үзгәргәнен» күрә, гәрчә чынлыкта андый үзгәреш булмый бит! Бу могҗиза түгелмени?

– Курчак белән бер булып китү бик мөһим, тулы бер образ тусын өчен, синең тавышың туры килергә тиеш, – дип аңлата актриса. – Шуңа күрә син башта бик озаклап курчакка карап торасың, аның холкы турында уйланасың, аның ниндидер үзенчәлекләрен күз алдына китерергә тырышасың. Миңа бер спектакльдә берничә образ белән эшләү дә ошый. «Дюймовочка»да, мәсәлән, мин Дюймовочканың әнисен, күсене, баканы, карлыгачны уйныйм... Менә кайда ачарга була талантларыңны!

ӘКИЯТИ ҺӘМ ЯРДӘМЧЕЛ

Театрга, әлбәттә, төрле бала килә. Замана балалары әкияткә ышанамы соң?.. Ышана, дип саный Татьяна Сорокина. Чөнки алар спектакльне шулкадәр бирелеп карыйлар! Менә, мәсәлән, шул ук «Снежная королева». Яңа куелышта спектакль башында сәхнәгә өч метрлы курчаклар – Снежная королева белән Тролль чыгуга, залда чәрелдәшә башлыйлар. Балалар барыбер курка... Ә инде Герда Кечкенә башкисәр кызга дусты булырга тәкъдим иткәч, балалар залдан: «Кирәкми, аның белән дуслашма!» – дип кычкыра башлыйлар. Димәк, алар башкисәрнең яхшы була алуына ышанып җитмиләр... Ә кайчак киресенчә – дуслык ту-

рында әйтүгә, кул чаба башлыйлар. Монда инде курчак йөртүченең кечкенә тамашачыны ничек һәм нинди дулкынга көйли алуына бәйле...

Шулай ук курчак театры дөньясында тапкырлык та таләп ителә, чөнки кайчак сәхнәдә көтелмәгән хәлләргә юлыгырга мөмкинсең. Мәсәлән, «Көлсылу»да Үги ана курчагын тоткан актриса сәхнәгә башына рококо эпохасы модасы буенча биек парик киеп чыга. Һәм бервакыт, дип искә төшерә Татьяна, әлеге парик канделябрга эләгә. Сюжет буенча канделябр өскә күтәрелергә тиеш. Һәм аның артыннан парик та өскә күтәрелә. Әмма актриса югалып калмый. «Ах, нәрсә инде бу!» – дип такмаклый башлый ул, әйтерсең лә, сюжет буенча бу шулай булырга да тиеш иде. Һәм тамашачылар әлеге хәл чыннан да шулай булырга тиеш дип кабул итте. Менә шундый тапкырлык могҗизасы.

ӘКИЯТИ ҺӘМ РОМАНТИК

Татьяна – характерлы геройларны уйнаучы актриса. Бала чагында ул, әлбәттә, Көлсылу турында әкиятне ярата, төп героиняны кызгана. Ә менә «Көлсылу» әкиятендә явыз Үги ананы уйный...

Моның өчен ул артык борчылмый. Характерлы геройларны уйнау күңеллерәк, диапазоны киңрәк. Ә принцка килгәндә, ул аны чын тормышта очрата.

«Бала чагымда мин Гринның «Алые паруса» китабын бик ярата идем, – дип сөйли Татьяна. – Тагын Валентина Осееваның «Динка» повесте ошый иде, аның буенча эле «Найди меня, Лёня!» дип аталган фильм да төшерделәр. Әлбәттә, мин дә үземнең принцымны очратырга хыялландым. Һәм, беләсезме, очраттым да! Ул минем ирем. Грей да, Лёня да түгел, ә Сергей. Һәм ул минем өчен чын могҗизалар ясый. Күптән түгел генә салкыннар вакытында машинам кабынмады, ишеген ача алмадым, ә эш өчен кирәкле барлык реквизитлар анда калды. Һәм бу вакытта мине коткарырга, машинамны ачарга кем килде дисезме? Әлбәттә, яраткан ирем! Әлеге маҗараның могҗизалы рәвештә тәмамлануына бер шигем дә юк иде».

Алар ике ул тәрбияләп үстерәләр, әлбәттә, малайлар әниләренең иң тугры, даими тамашачылары була. Хәзер инде алар зурлар, курчак театрына йөрмиләр.

«Оныклар көтәм, алар мин уйнаган спектакльләрдә залда утырырлар, дип ышанам», – дип елмая Татьяна.

«Әкият» театрында оештырылган Чыршы бәйрәмендә Татьяна Сорокина башкаруындагы Убырлы карчык бөтенләй усал герой түгел кебек.



ӘКИЯТИ ҺӘМ ҮГЕТ-НӘСИХӘТЛЕ

«Мин әкиятләрдән туймыйм, театрыбызда кайнап торган тормыш ошый, монда гел нәрсәдер булып тора, – дип сөйли Татьяна. – Бездә, театрның беренче катында, «Оперение» театр студиясе дә эшли, мин анда йөрүче балаларны әкият уйнарга өйрәтәм».

«Оперение» студиясенә биш яшьлек сабыйлар да, унберенчедә укучылар да йөри. Студияне тәмамлаган балалар арасында Мәскәү һәм Петербург вузларының актёрлык бүлекләренә укырга керүчеләр дә бар. Кемдер драма актёры булачак, ләкин, Татьяна Сорокина ышануынча, араларында һичшиксез үз курчак театрларын оештыручылар да табылачак.

Студиядә балалар барысын да үз куллары белән ясарга өйрәнә, шул исәптән курчакларны да. Хәзер, мәсәлән, дип сөйли Татьяна, бер бик талантлы малай Киплингның «Рики-Тики-Тави» әкияте буенча куела торган яңа спектакль өчен курчаклар ясый.

Менә аның балалар белән куела торган иң яраткан спектакльләренең берсе – «Бременские музыканты»да катнашучылар составы бер генә мәртәбә алышынмаган. Һәм, Татьяна сөйләвенчә, һәр очракта бер үк материал нигезендә яңа спектакль тугандай була.

«Бөтенләй башка, өр-яңа тамаша туа, – дип елмая ул. – Һәм минем өчен һәрвакыт могҗиза да тугандай була. Гомумән мин һәрвакыт балаларга болай дим: бөтен нәрсәдә могҗиза күрергә өйрәнегез. Мин үзем, мәсәлән, күрәм. Яңа ярган яфрак, шытып чыккан үлән дә минем өчен һәрвакыт могҗиза. Яфракның ярган мәлен күрергә, эләктереп алырга телим, әмма ул һәрвакыт могҗизадай кинәт кенә була. Яисә яңгыр вакытында кинәт кенә кояш чыга – бу да могҗиза! Гаҗәпләнүдән туктамаска кирәк: күк йөзенә, йолдызларга, болытларга карап туймаска, һәр мизгелгә шатланырга! Һәм һәр көн кечкенә генә булса да могҗиза алып килсен!»

«Серая шейка» спектаклендә катнашучылар. Үрдәк әнисе ролендә – Татьяна Сорокина (өске рәттә сулдан икенче).

Габдулла Тукайның бала чагына багышланган «Волшебные сны Апуша» спектаклендә Йорт иясе ролендә.

ИЯЛӘР ГАЛӘМЕНДӘ

Сафа Гәрәев

Бу галәмдә барысы да әкияттәге кебек. Миһербанлы, кайчак сагышлы, әмма һәрвакыт көтелмәгәнчә. Су анасы явыз Убыр түгел, ә суга аның сафлыгын кайтаручы тылсымлы зат. Шүрәле – Урман патшалыгын тупас рәвештә якынлашып килә торган шәһәрдән сакларга тырышучы, ул бераз сагышлы романтикны хәтерләтә. Ә Өй иясе – гаилә учагын саклый торган зирәк карт...

Бу геройлар безгә кечкенәдән Тукай әкиятләре аша таныш кебек. Әллә барысы да түгелме? Рәссам Әхсән Фәтхетдинов уйлап тапкан әкият галәмендә кешеләрне кытыклап үтерүче, яисә авыл балаларын куркытып котын алучы бернинди дә явыз затлар юк. Иҗатчы кулы белән җанланган әкият затлары исә бөтенләй башка. Күңелгә якын һәм сагышлы. Ник алай соң? Яисә дөнья үзгәрдеме?

Фотолар «Әхсән Фәтхетдинов. Нәкыш. Агачны уеп ясау. Агач сыннар» китабыннан, idemvmuzei.ru

УРМАН ИЯСЕНЕҢ САГЫШЫ

Онытыла барган моңсу Шүрәле, кайчандыр урман патшалыгының бер өлеше булган агачларның төпләренә карап, тальян гармун тартып, моңланып утыра. Иҗатчы шулай язып та куя – «Шүрәле моңлана». Сүзләр агач төпләренә юри тупасрак итеп уелган кебек – гадәттә җилбәзәк үсмерләр генә матур урыннарны шулай бозып йөри.

Тагын бер Шүрәле. Монысы, ишекне ачып, авыл өе бусагасына атлый. Нинди ният белән икән? Әллә үзеннән көлгән Былтыр белән исәп-хисап ясамакчы буламы? Ләкин аның җитди йөзендә бер тамчы да кырыслык юк, күбрәк – борчылу, ахры. Мөгаен, кайчак гамьсез вә ваемсыз, акылсыз тоелган кешеләр өчендер...

Икенче бер Шүрәле айлы кичтә урман авызыннан ачыла торган манзарага шикләнебрәк карап тора. Чөнки агачлар артында – шәһәр, һәм ул урманга якынлашканнан-якынлаша бара...

Шагыйребез «урман сарыгы» дип атаган куркыныч һәм бераз ахмаграк Шүрәле кайда соң? Рәссамның эшләренә карагач, әкиятнең яңа дәвамын күрәбез: безнең балачактан килгән ямьсез һәм килбәтсез Шүрәле үз заманы белән бергә юкка чыккан түгелме? Ул яңа, заманча акыллы һәм һич тә иләмсез түгел кебек. Әмма ни өчендер моңсу. Бәлки, без бүген аңардан түгел, киресенчә ул үзе кешеләрдән, аларның уйламыйча кылган гамәлләреннән курка башлагандыр?

ҖЕН-ПӘРИЛӘР ГАИЛӘСЕ НИЧЕК ПӘЙДА БУЛА

Ни өчен нәкъ менә Шүрәле? «Шүрәле көтмәгәндә пәйда булды, әйтерсең лә ул инде күптәннән аңның ниндидер бер почмагында сагалап торган да билгеле бер гәүдәләнешкә омтылган. Ә куллар, агач кәүсәсендә бизәк формасында яшеренеп яткан Шүрәлене капшап табып, дөньяга алып чыгарды кебек...» – дип яза иҗатчы үзенең язмаларында.

«Кинәт пәйда булу» иҗади ташкынга әверелә. «Күләгәдә», «Шүрәле», «Айлы төндә», «Бусагадагы Шүрәле»... Циклга кергән һәр картинада рәссамның фантазиясе аны яңа шартларга куя, әйтерсең лә Шүрәленең төрле мохиттә үзен ничек тотасын аңларга тели. Урман иясе үзе дә бу картиналарда төрле, әмма беркайчан да усал, хәйләкәр түгел. «Шүрәле» картинасында герой кулында кош, әйтерсең урман иясе аны әйләнә-тирәдәгеләрдән сакларга омтыла. Агач рамга «Табигатьне кешедән саклый» дигән аңлатма да уеп язылган.

Аңлатма язу – шифрга ачкыч кебек. Әкият циклы иҗатчының тирә-якта бара торган хәлләрдән күңеле кайткач, әче пошкач туа. Яңа шәһәрләр туган якка цивилизация гына алып килми, совет чоры эзлекле рәвештә кешенең индивидуальлеген юкка чыгара, гасырлар буе тупланган рухи кыйммәтләр җуела башлый. Урманнар киселә, елгалар корый, күнегелгән тормыш рәвеше җимерелә, авыллар юкка чыга, гүя алар белән бергә халыкның җаны да үлә кебек.

Борынгы бабаларыбыз рухын саклаган урман иясе, үткәндәге серле персонаж, рәссамга шик-шөбһәләрен кичерергә ярдәм итәр өчен, агачлар куелыгыннан чыккандай тоела. Ул иҗатчы өчен өмет һәм илһам чыганагына әверелә. Һәм иҗатында терелә, тормышта бара торган хәлләрне аңларга ярдәм итә.

«Әлеге авыр елларда Шүрәле, гаиләсе белән яныма килеп, минем белән бергә яшәде, бер өстәлдән ашады, җыелышларда катнашты.

– Тагын җен-пәриләреңне алып барасыңмы? – дип сорыйлар иде миннән «Шүрәле»ләремне күргәзмәгә дип әзерләгәндә.

– Ник һаман Шүрәлеләр генә ясыйсың? Үзең дә Шүрәлегә әйләнеп барасың инде, –



«Шүрәле».

Су анасы.

дип тә әйтәләр. Ә мин үпкәләмим», – ди Әхсән Фәтхетдинов.

Үпкәле һәм талчыккан Шүрәле... Әйтерсең ул иртәгә ничек яшәргә кирәклеген аңлый алмый гаҗизләнә. «Күләгәдә» дип аталган картинада нәкъ шулай күз алдына килеп баса да. Тик бу кем соң: Шүрәлеме, әллә автор үземе?

«ИЯЛӘР» ЯРДӘМГӘ КИЛӘ

Картинадагы әкият әле әкият түгел. Аны гади рамга урнаштыруга, тылсымы юкка чыга кебек. Мөгаен, шуны аңлаган Фәтхетдинов эшләрен уеп ясалган серле персонажлары, символлары булган агач рамга урнаштыра. Рамда да әкият. Аның геройлары синең белән рәхәтләнеп аралаша кебек. «Су анасы»ның рамы – рәссамның чираттагы җәүһәре. «Сафландыра суны, чистарта» дигән язуны күргә, башка әнә шундый уй килә. Бу уйның капма-каршылыгына гаҗәпләнәсең. Су анасын Тукай поэмасы аша беләбез. Без бит аны куркыныч һәм ямьсез итеп күз алдына китерәбез. Ә монда – миһербанлы һәм игелекле, суны саф һәм тере килеш сакларга сәләтле зат. Чын саклаучы.

Саклаучы – тагын бер кодлы сүз. «Кемдер кемнедер һәрвакыт сакларга тиеш. Астына һава керсен өчен, кемдер авыр ташларны күтәрергә тиеш. Кемдер кемнедер уятырга тиеш... Һәм гамьсезрәкләрне уятыр өчен хәтта кычкырырга да тиеш». Рәссам көндәлегендәге язма да – табышмакка ачкыч. Ул «Ияләр» дип аталган тагын бер циклның барлыкка килүен аңлата.

«Күкне зәңгәрли. Үзе җирне сагына» – дип уеп язылган агач рамга. Моңга тулган тагын бер эше – «Ташланган авыл ияләре». «Төн ияләре», «Бичура», «Абзар иясе» һ.б....

Болар барысы да «Ияләр» циклына кергән искиткеч талантлы эшләр, аларның һәркайсы үз мәгънәсенә ия. Һәм кешеләргә охшаган затлар – рәссам фантазиясе тудырган әкият геройлары гына түгел, алар – безнең заманга борынгы мәҗүсилектән кайткан саклаучылар.

ӨМЕТ

Рәссамның эш дәфтәрендә шундый бер язу сакланган: «Татар халык авыз иҗатына күз салсак, безне чолгап алган һәрнәрсәнең үз иясе, үз саклаучысы һәм үз хуҗасы бар, – дип яза Фәтхетдинов. – «Абзар иясе» атларны ярата. «Бичура» мунчада яши, ул бик мәрхәмәтле. «Өй иясе» төннәрен йокламый... «Ярымтык» йортсызларны, мохтаҗларны кызгана... «Моң иясе» өзелеп-өзелеп гармунда уйный, моңын кая куярга белми газаплана... «Зират иясе» мәчетләр аударылудан, иске китаплар яндырылудан, ата-баба каберләренә хөрмәт бетүдән интегә... «Сагышлы» җир йөзендәге бөтен кайгы-хәсрәтне үз йөрәге аша уздыра. «Җир иясе» үткән заманнар кыйпылчыклары арасында утыра, үзе дога кыла. Аның күзләре авыртудан үткенәя...»

Менә шундый бераз моңсу әкият... Ләкин иҗатчы, татар мифологиясе персонажларына мөрәҗәгать итеп, төшенкелек биләп алган көнелләрдә («Ияләр» циклы болганчык 90 нчы елларда язылган – **ред. иск.**) өмет чаткысы кабыза кебек. Безгә кайткан ияләр мәдәни, әхлакый кыйммәтләрне, милли үзаңны җимерелүдән саклый алачак. Шуңа күрә дә рәссам таланты белән иҗат ителгән ияләр дә яхшы күңелле.

«Татар мифологиясендәге традицион рухлардан аермалы буларак, минем ияләр һәрәкәттә түгел, алар күзәтүчән һәм аларга бары тик уңай сыйфатлар гына хас. Алар җәза бирүчеләр түгел... һәм җәмгыять үзен үзе яңартыр, торгызыр дигән мәңгелек көтү халәтендә», – дип яза рәссам. Моның һичшиксез шулай булачагына Фәтхетдинов иң авыр чорларда да ышана. Һәм киләчәк буыннарга көндәлеген калдыра. Андагы язмаларга яхшы әкияткә ышангандай ышанасың. Менә ул көндәлектән өзек:

«XXI гасыр элек җимерелгәннәрне төзекләндерергә тотыныр, дип уйлыйм. Җирне, һава һәм суны, шәһәр һәм авылларны, җәнлек һәм кош-кортны, тау һәм чокырларны, күл һәм елгаларны, юл һәм күперләрне, урам һәм тыкрыкларны, агач һәм бакчаларны, урман һәм кырларны – моны бик озак дәвам итеп була – ремонтларга кирәк.

Ләкин иң авыры – кешенең күңелен ремонтлау».

P. S. Иҗатчының иң яхшы эшләрен Түбән Камадагы Әхсән Фәтхетдинов музеенда (Яр буе урамы, Красный Ключ бистәсе) күрергә була.

«Өй иясе».

«Абзар иясе».

КАЗАН АГРО 2026

Агросәнәгать комплексы казанышларының махсуслаштырылган авыл хуҗалыгы күргәзмәсе

11-13 февраль 2026, «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә комплексы

300+ катнашучы

12 000+ профессионал

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Дөньяда иң шәп урын **кайда**

Казанның киләчәге **кайда** тәрбияләнә

Сәнгатьне **ничек** саклап калырга

Апас

Фото: Александр Ефремов. Иллюстрация: Оксана Кузнецова

АПАС РАЙОНЫНА АКЧА КЕРТҮ ОТЫШЛЫ!

Татьяна Вафина

Апаска без шактый еш барабыз. Барган саен ул безне сокландыра: район көннән-көн матурлана, төзекләнә, уңайлыракка әйләнә бара. Әмма иң мөһиме – инновацияләр кертелә.
Зур булмаган авыл хуҗалыгы районының ни рәвешле республикада иң алдынгыларның берсенә әверелүе турында Апас муниципаль районы башлыгы Айрат Җиһаншин белән сөйләшәбез.

ҮТӘП КЕНӘ КАЛМЫЙБЫЗ, ҮСӘБЕЗ ДӘ

– Дәүләт Советына Юлламасына Татарстан Рәисе болай дигән иде: «Иң мөһим өстенлекле юнәлешләрнең берсе – азык-төлек куркынычсызлыгы». Айрат Габделхакович, район республика авыл хуҗалыгы җитештерүенә нинди өлеш кертә?

– Апас районы республика азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүгә шактый зур өлеш кертә. Авыл хуҗалыгы – безнең икътисадның һәм социаль тотрыклылыкның нигезе. 2025 елда хуҗалык итүнең барлык категорияләрендә авыл хуҗалыгы продукциясенең гомуми күләме – 6,2 миллиард сум дәрәҗәсендә.

Районда үсемлекчелеккә дә, терлекчелек тармагына да зур игътибар бирелә. Мәсәлән, быел бөртеклеләрнең тулай җыемы 141 мең тоннаны тәшкил итте, шикәр чөгендере 237 мең тонна игелде. Терлекчелек тә үсештә: 2025 елның 9 аенда 14,2 мең тонна сөт һәм 1,6 мең тонна ит җитештерелде, бу узган елгы күрсәткечләрдән ике тапкырга югарырак.

Фермер һәм шәхси хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирәбез. Аларда 5 мең баштан артыграк мөгезле эре терлек һәм 7 мең башка якын сарык һәм кәҗә асрала. Дәүләт ярдәме, мәсәлән, «Агростартап» һәм кооперативларны үстерү программалары нәтиҗәсендә районда заманча эшкәртү цехлары ачыла, ресурсларны саклый торган технологияләр кертелә. Быел гына да безнең аграрийлар техниканы яңартуга 420 миллион сумнан артык акча салдылар.

Шул рәвешле, район, планда каралганнарны үтәп кенә калмыйча, авыл хуҗалыгын тотрыклы үстерү өчен шартлар да тудыра.

СӨТ ТӘ, КОШ-КОРТ ТА, ИНДУСТРИАЛЬ ПАРК ТА

– Районда нинди перспективалы инвестицион проектлар эшли, кайсыларын тормышка ашыру планлаштырыла?

– Районның инвестицияләр сәясәте заманча җитештерүләр һәм яңа эш урыннары ачуга йөз тота. Бүген бездә берничә зур проект тормышка ашырыла.

Әйтик, сөт комбинаты. Аңа бүген үк 2,6 миллиард сумлык инвестиция кертелгән. 2026 елда тагын 900 миллион сум акча салыныр, дип ниятләнелә. Предприятие сыр һәм коры сөт җитештерә, җыелма керем 1,65 миллиард сумнан артып китте.

Сөт комплексын төзү («Табар» авыл хуҗалыгы предприятиесе» ҖЧҖ) – 400 баш МЭТ асрауга исәпләнгән яңа проект ул. Аның проект куәте елына 4380 тонна сөт җитештерүне күздә тота. Төзелешне тәмамлау һәм объектны эшләтеп җибәрү 2026 ел ахырына планлаштырыла.

Тагын бер киң колачлы проект – «Яратель-Апас» («Ак Барс» ХК) кош фабрикасы. Бу эшкә 11,3 млрд сум акча кертү күздә тотыла. Фабрика елына 655 млн данә йомырка җитештерәчәк. Чебиләр өчен цех инде төзелгән, анда 606 мең баш кош кайтартылган. Проект 300 эш урыны ача.

«Апас» индустриаль паркы – 39,7 гектар мәйданга исәпләнгән стратегик проект. 7,7 млрд акча салырга әзер инвесторлар инде ачыкланган. Паркта логистика шәп итеп уйланылган, ул тимер юлга да, федераль трассага да тоташа, шулай ук инженерлык инфраструктурасы да шактый куәтле. Проектны эшләтеп җибәрү 2027–2032 елларга планлаштырыла, ул 889дан артык эш урыны ачарга мөмкинлек бирәчәк.

2025 елда район буенча төп капиталга барлыгы 5 млрд сумга якын инвестиция кертелде. Эшебездә ярдәм күрсәткәннәре өчен без партнёрларыбызга һәм республика җитәкчелегенә рәхмәтле.

АВЫЛ ТАЯНЫЧЫ ҺӘМ РАЙОН ГОРУРЛЫГЫ

– Бүген авыл фермерлар кулында, алар – зур таяныч. Сез кемнәрне районның горурлыгы дип атый аласыз?

– Районыбызның горурлыгы – ул, һичшиксез, Вилдановлар гаиләсе. Әлеге гаилә буыннар арасындагы элемтә һәм авыл хуҗалыгына заманча караш үрнәге булып тора. Фаил һәм Фазыл Вилдановлар гомерләрен җиргә багышлаган кешеләр. Алар үз улларында да хезмәткә хөрмәт кенә түгел, тормышның мәгънәсен һәм яшәү шатлыгын туган җирдә тоярга өйрәткәннәр. Балалары – Инзил белән Данил да шәһәргә китмәскә, туган авылларында калып, гаилә эшен дәвам итәргә карар кылдылар. 2020 елда алар, «Агростартап» дәүләт программасы мөмкинлекләреннән файдаланып, үсеш өчен акчаларга ия булдылар. Бу аларга техника, терлек сатып алырга, яңа фермалар төзергә булышты.

Шунысы да мөһим: яшь буын ирешкәннәрдә тукталып калмый. Алар, ит җитештерү тармагына сөтчелекне дә кушып, үз хуҗалыкларын дөрес итеп оештырдылар. Сөтчелек тармагы, зур тырышлык таләп итсә дә, тотрыклы керем кертә. Дәүләт программаларына таянып, алар башта - Киров өлкәсеннән, аннары Венгриядән нәселле таналар кайтарттылар. Бу аларның сыйфатның югары дәрәҗәсенә омтылулары турында сөйли. Өлкән Вилдановлар шулай ук, яшьләр үрнәгенә ияреп, сыер абзарларын яңарттылар. Әлеге гаилә – хезмәт, инициатива һәм дәүләт ярдәменең аерым хуҗалыкны гына түгел, тулы бер районны үстерергә булышуына ачык мисал.

2011 елдан бирле эшли торган «Әхмәдиева Н.И.» крестьян-фермерлык хуҗалыгы да район авыл хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш кертә. Әлеге хуҗалык, 78 гектар җирдә эшләп, яшелчәчелек тармагында алдынгылыкны бирми. Алар нигездә бәрәңге һәм башлы суган үстерү белән шөгыльләнә. Әлеге төр яшелчәләр

– Апаста экскурсияне мин туган якны өйрәнү музееннан башлар идем, чөнки анда бай төбәк тарихы турында материаллар саклана.

–Музейда мамонт скелеты реконструкциясе, борынгы хайван калдыклары һәм башка археологик табылдыкларны күрергә мөмкин, алар төбәгебезнең тирән тамырларын аңларга булыша.

Район китапханәсе – төрле яшьтәге кешеләрне үзенә тарту үзәге.

10 ар гектарда үстерелә, ә калган мәйданны башка яшелчә культуралары һәм яшел тәмләткечләр алып тора. Продукцияне ел әйләнәсендә үстерү өчен фермерлар заманча теплицалар тота: 1200 м² мәйдандагысы җылытыла, ә гомуми мәйданы 500 м² булган ике теплица җәйге санала. Экологик яктан чиста продукциягә ихтыяҗ зур. Алардан район халкы сатып ала, ярминкә көннәрендә Казанны тәэмин итәләр. Хуҗалыкта даими рәвештә 8 кеше эшли, аларның хезмәте территориядә азыктөлек куркынычсызлыгына, мәшгульлеккә зур өлеш кертә.

МАТУРЛЫК ТОЙГЫСЫ

– Апас үзәген алмагач аллеясе бизи, ә җирле музей бинасы – чын архитектура җәүһәре... Шәп зәвык, матурлыкны шулай нечкә тоемлау – апаслыларга бу каян килгән? Әллә геннарданмы?

– Чыннан да, Апас халкына зәвык та, матурлыкны тоя белү дә хас, бу, мөгаен, тарихи мирас, мәдәни мохит һәм үз тирәңне матурлауга омтылудан киләдер. Әйе, тәртипкә, гармониягә тартылу, шуңа омтылыш буыннан буынга бирелә, әмма бу дөрес җавапның бер өлеше генә. Безнең бабайлар һәрвакыт үз көнкүрешен күңел җылысын кушып җайларга, рәтләргә тырышкан. Алар матур йортлар төзегән, бакча үстергән, өйләрен бизәгән. Бу традиция бүген дә яши.

Апас үзәгендәге алмагач аллеясе ял итү урыны гына түгел. Ул – хәтер һәм дәвамчанлык символы да. Шул рәвешле, мондагы матурлык тирән мәгънәгә ия, ул буыннар элемтәсен дә гәүдәләндерә. Сез архитектура җәүһәре дип атаган туган якны өйрәнү музее шулай ук эстетик зәвык тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Монда район халкы, кунаклар тарихка күз ташлый, уникаль экспонатлар белән таныша ала. Һәм әлеге төбәкнең табигате, тарихы һәм мәдәнияте үзара ничек бәйләнүенә төшенә.

Моннан тыш, без мәдәни инициативаларны күтәреп алабыз, бәйрәмнәр, тирә-якны төзекләндерү буенча бәйгеләр оештырабыз, туган якны өйрәнүгә яшьләрне дә җәлеп итәбез. Болар барысы да матурлыкны саклап калырга гына түгел, аны баетырга, төрлеләндерергә ярдәм итә. Апастагы матурлык – уртак хезмәт, традицияләргә хөрмәт һәм туган ягыңны тагын да гүзәлрәк итәргә тырышу нәтиҗәсе ул.

КУНАКЛАР ӨЧЕН ЭКСКУРСИЯ

– Әгәр район кунаклары өчен экскурсия оештырырга туры килсә, сез аларга беренче чиратта кайсы урыннарны тәкъдим итәр идегез? Нинди риваять, легенда сөйләр идегез?

– Апаста экскурсияне мин туган якны өйрәнү музееннан башлар идем, чөнки анда бай төбәк тарихы турында материаллар саклана. Музейда мамонт скелеты реконструкциясе, борынгы хайван калдыклары һәм башка археологик табылдыклар белән танышырга мөмкин, алар төбәгебезнең тирән тамырларын аңларга булыша.

Алга таба кунакларны Апасның үзәк аллеясенә алып барыр идем. Анда атаклы якташларыбызның бюстлары, районның күренекле кешеләре хөрмәтенә стелалар куелган. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга багышланган мемориаль комплекс аерым урын алып тора. Бу – мәңгелек хәтер, якташларыбызның батырлыгы белән горурлану урыны.

Табигать сөючеләрне, риваятьләргә мөкиббән кешеләрне Кыз тавына алып барырга була. Әлеге тау турындагы легенда Алтын Урда чорына барып тоташа. Җанибәк хан кызы Күзенурны Дәвеш авылы тирәсендә яшереп үстерәләр. Хан үзенең кызы барлыгы турында ишеткәч, аны сарайга китерергә боера, ләкин соңрак кыз үлем җәзасына хөкем ителә. Хан хезмәтчесе Әмәт, кызны коткарырга теләп, аңа качарга булыша. Алар үз бәхетләрен туган җирләрендә таба. Әмма хан яугирләре аларны таба һәм үтерә. Кызны тау башында җирлиләр, шуннан бирле ул Кыз тавы дип атала. Әлеге риваять мәхәббәт, тугрылык һәм иреккә омтылу кебек мәңгелек кыйммәтләр турында сөйли.

Шулай ук кунаклар районның бүгенге тормышы турында да белергә тиеш. Бездәге спорт объектлары, «Гран Тау» кебек уникаль табигать һәйкәлләре һәм, әлбәттә, бик матур кешеләр Апас районының үзенчәлеген тәшкил итә.

ТӨРЛЕ ЯШЬТӘГЕЛӘРНЕ ТАРТУ ҮЗӘГЕ

– Авыл кешесенең буш вакыты юк диярлек. Шулай да, алар ялларын ничек үткәрә? Моның өчен нинди шартлар тудырылган?

– Җирдә хезмәт итүнең фидакарьлек, зур тырышлык таләп итүен яхшы аңлыйбыз. Әмма кеше эшләргә генә түгел, ял итәргә, үсәргә һәм рәхәтләнеп аралашырга да тиеш. Шуңа күрә ял өчен заманча, һәркем файдалана, төрле кызыксынуларга җавап бирә алырлык шартлар тудыру – төп бурычларыбызның берсе.

Бүген район халкы буш вакытын актив һәм зәвыклы итеп үткәрә алсын өчен тулы бер инфраструктура булдырылган. Моңа нинди дидер объектлар гына түгел, ә төрле яшьтәге кешеләрне тартып торучы үзәкләр дә керә.

Спорт сөючеләр өчен бездә заманча җиһазлар һәм инвентарь урнаштырылган җиде зур спорт объекты эшли – «Апас» универсаль залы, «Дельфин» йөзү бассейны, «Алтын алка» боз сарае, «Гран Тау» ябык футбол манежы, «Максат» теннис үзәге, «Апас-Арена» ачык стадионы, чаңгы базасы. Районда футбол, волейбол уйнарга яисә тренажерларда шө-

Үзәк аллеядә атаклы якташларыбызның бюстлары, районның күренекле кешеләре хөрмәтенә стелалар куелган.



КҮЗ САЛ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

– Спорт сөючеләр өчен бездә заманча җиһазлар һәм инвентарь урнаштырылган җиде зур спорт объекты эшли.

гыйльләнергә мөмкин булган урам спорт мәйданчыклары да төзелде.

Без спорт белән шөгыльләнеп кенә калмыйбыз, җиңүләргә дә ирешәбез. Районның волейбол командасы – авыл районнары арасында республика чемпионы, яшь футболчылар кубоклар өчен ярышларда җиңәләр, ә картинг-берләшмә республика узышларындагы уңышлары белән сөендерә. Быел без автомобиль һәм квадроцикллар ярышларын үзебездә кабул иттек. Россиянең сигез төбәгеннән килделәр. Бу вакыйга район өчен чын бәйрәмгә әверелде.

Мәдәният һәм сәнгать сөючеләр өчен районда 55 авыл клубы һәм район мәдәният йорты эшли. Алар гореф-гадәтләребезне саклый һәм җанландыра торган урынга әверелә. «Ике моң» фестивале инде 19 ел районның визит карточкасы булып тора. Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан «Җиңү салюты» дигән зур фестиваль уздырдык. Ул барлык җирлекләрнең иҗат коллективларын берләштерде. Җыелган акча махсус хәрби операциядә катнашучы якташларыбызга ярдәмгә китте. Җәмгыятькә файда күрсәтеп ял итү – безнең мөһим принцип.

Гаилә ялын оештыруга, яшьләр тормышына аерым игътибар бирәбез. «Сәләт» балалар иҗат үзәгенә һәм яшьләр үзәгенә яратып йөриләр. Заманча җиһазландырылган ике фәнни мәктәп клубы эшли. Беренчеләр хәрәкәте инде 1600 гә якын баланы берләштерә, шул исәптән мәктәпкәчә яшьтәгеләрне дә. Җәен «Апаста рәхәт» проекты уңышлы тормышка ашырыла – мәдәният йортлары базасында махсус лагерьлар ачыла. Анда балалар уен һәм иҗат аша татар халык традицияләре мохитенә эләгә.

Рухи ялны оештыру, белем бирү турында да онытмыйбыз. Районда балалар өчен «Хаҗәр» рухи-әхлакый үзәге эшли. Үзәктә туган телгә һәм гореф-гадәтләргә игътибар бирелә. Хәйрия фонды булышлыгы белән малайлар өчен яңа үзәк ачыла.

Шуны да билгеләп үтәм: безнеңчә ял – җәмгыятькә файдалы булу мөмкинлеге дә ул. Районда 56 волонтёрлык үзәге актив эшли. Үзәккә 563 волонтёр йөри, алар махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм яңа территорияләрдә яшәүчеләр ярдәм әзерли, кием-салым тегә, посылкалар җыя. Бу эшләр халыкны берләштерә, зур уртак чарада катнашу хисен тоярга булыша.

Шул рәвешле районда яшәүче һәркем, үз эшендә мәшгуль булуына карамастан, күңеленә хуш килгән шөгыль таба ала. Без һәр кеше сәламәтлеген ныгытырлык, талантларын ачарлык, яңалыкларны үзләштерерлек, үзәк паркта гаиләсе белән ял итәрлек яисә үз белемен, күнекмәләрен үсеп килүче буынга тапшыра алырлык мохит булдырырга омтылабыз. Ял арзан да, сыйфатлы да, эчтәлекле дә булырга тиеш - нәкъ менә шул юнәлештә эшлибез.



ӘКИЯТНЕ ЧЫНБАРЛЫККА ӘЙЛӘНДЕРӘ ТОРГАН ЛИЦЕЙ

КАЗАН ИНЖЕНЕРЛЫК ӘКИЯТЕ ГЕРОЙЛАРЫ ЮБИЛЕЙ АЛДЫННАН НИНДИ ҮРЛӘРГӘ ОМТЫЛА ҺӘМ НӘРСӘ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНА?

Ксения Сёмина

«Алиса в стране чудес» әкиятен язган Льюис Кэрролл һәм «Волшебник Изумрудного города» повестеның авторы Александр Волков – профессиональ математиклар, «Чародеи» Яңа ел фильмы сценариеның автордашы Борис Стругацкий – астроном, ә 2020 елларның иң шау-шулы фантастик әсәрләренең берсе «Задача трёх тел» романын иҗат иткән Лю Цысиньнең ИТ-энергетик икәне сезгә мәгълүмме? Фантастика китаплары авторлары арасында программистлар исә санап бетергесез. Болар барысы да иң зур тылсымның «физика» һәм «лирика» кисешкән урында тууына дәлил булып тора.

Казан шәһәре Совет районының Лицей - инженерлык үзәге дә – моңа бер дигән дәлил. Аңа гыйнварда 10 ел тула. Әлеге вакыт эчендә биредә инженерлык белеме бирүнең уникаль системасын булдырганнар – Smart Kids балалар бакчасында төгәл дисциплиналарны өйрәтүдән башлап ILS башлангыч мәктәбендә тел мохитенә чумдыруга, ә аннары урта гомуми белем бирү мәктәбендә укучыларны үз фәнни-техник проектларын уңышлы яклатуга кадәр.

Моннан 8 ел элек «Инженерлар республикасы» проектын оештыруда катнашып, мәгариф оешмасы үзенең уңышлы тәҗрибәсен төбәккә тараткан. Хәзер проект кысаларында Татарстан районнарындагы ун мәктәптә меңнән артык бала инженерлык белеме ала. Лицей республиканың иң яхшы мәктәпләреннән санала. Аны тәмамлаучылар Россиядәге һәм чит илләрдәге иң яхшы югары уку йортларына керә. Педагоглар профильле конкурсларда җиңә, даими эзләнә һәм, шәкертләрен гел кызыксындыру өчен, үзләре дә гел яңалыкка омтыла. «Татарстан» журналының тылсымлы гыйнвар санында лицейга нигез салучылар һәм аның җитәкчеләре фольклор геройларының, суперсәләтләрнең, үзеңә ышануның менә инде 10 ел инженерлык могҗизасын ничек тормышка ашырырга булышулары турында сөйли.

Фото: Лицей — инженерлык үзәге архивыннан. РЕКЛАМА

КИЛӘЧӘК МӘКТӘБЕН ХЫЯЛГА ЫШАНУ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ТУДЫРА

Казанның Лицей – инженерлык үзәге дәрәҗәсендәге мәктәпне булдыру һәм аның белән идарә итү өчен чыннан да суперсәләтлеләр кирәк. Әмма алар килеп чыгышлары буенча тулысынча җирнеке: бу – социаль, мәгариф, технологик трендларны күреп, файдалана белү тәҗрибәсе. **Директор Венера Хәйретдинова** җитәкчелегендә лицейда ясалма фәһемнән һәм цифрлы игезәкләрдән алып мәгълүмати куркынычсызлыкка кадәр иң актуаль юнәлешләр кертелә. Әмма Венера Кәшфи кызы шәхесне – педагог, укучы, ата-ананы технологияләрдән һәм мәгарифтәге казанышлардан өстен күрә. Биш йөздән артык бала укый торган лицей системасында уңайлы мохит булдырылган. Ата-аналар мәктәпкә баласын ышанып тапшыра, ә укытучылар, белем бирүдән тыш, укучыларга эмоциональ яктан да ярдәм итеп тора.

– Бүген дөнья барыбыздан да үзгәрешләргә әзер булуны таләп итә, ә алар шулкадәр тиз бара, шуңа күрә безнең төп бурыч – балаларны укырга, мәгълүматтан дөрес файдалана белергә өйрәтү. Шул ук вакытта аларга төп кешелек кыйммәтләрен – дуслаша белү, өлкәннәрне хөрмәт итү, аңлы һәм намуслы булу кебек нәрсәләрне сеңдерү дә мөһим. Без уңышның күпкырлы булуын аңлыйбыз, безнең һәр шәкертебезнең үз биеклеге бар, һәм укытучының осталыгы аңа шул биеклекне яуларга ярдәм итүдән гыйбарәт. Әлбәттә, без билгеләр куябыз, әмма барыннан да элек – үз хезмәтебезгә: әгәр материал үзләштерелмәгән икән, димәк, без әле баланың йөрәгенә һәм аңына дөрес юл таба алмаганбыз, – ди Венера Кәшфи кызы.

Лицейның ун еллык юлы зур команданың уртак җиңүләре тарихына әйләнгән. Бу җиңүләрнең нигезендә ихлас тырышлык һәрвакыт матур нәтиҗәгә китерә дигән ышану ята.

– Миңа юл башында башкалардан аерылып тормаучы, ләкин хәлиткеч мизгелдә үзендә теләсә нинди авырлыкны җиңәрлек көч таба алучы геройлар ошый. **Андерсенның «Кыргый аккошлар» әкиятендәге Элиза** кебек: ул хәтта үзенә учак янаганда да кычытканнан күлмәк үрүен дәвам итә, үз максатына тугры калып, туганнарын коткару өчен тырыша, – ди Венера Хәйретдинова. – Мин ышанам: көчле омтылыш, зур тырышлык булганда, теләсә кайсы теләккә һичшиксез ирешеп була. «Тылсымчылар мәктәбендә» без нәкъ менә шундый: үзебезгә һәм укучыларыбызга ышанабыз, алда нинди генә кыенлыклар тормасын, нәтиҗә булсын дип тырышабыз, һәм балаларның безне беркайчан да уңайсыз хәлгә куймаячагын беләбез.

СТАНДАРТЛАР КЫСАСЫНДА, ӨМЕТЛӘР АРЪЯГЫНДА

Лицейның мәгариф рейтингларында югары торуына шул исәптән белем бирү нәтиҗәләрен өзлексез мониторинглау аркасында да ирешелә. **Укыту эшләре буенча директор урынбасары Лилия Хәмитова**, уку процессының федераль стандартларга туры килүен тәэмин итеп, әлеге юнәлешне көйли. Президент указларын һәм Бала хокуклары турындагы конвенцияне дә кертеп, фундаменталь хокукый базага, педагогика, психология һәм хезмәт законнарын белүгә таянып, Лилия Флүн кызы хезмәттәшләре белән бергә укытучылар үсеше һәм һәр укучының казанышлары өчен иң яхшы шартлар тудыра.

– Безнең эш – ата-аналарның ихтыяҗларын өйрәнүне, кадрлар сайлауны һәм тышкы аттестацияне алып баруны берләштерү. Бала уңышка ирешсен дисәң, укытучының барлык процессларда төп катнашучы булырга тиешлеген танырга кирәк. Без шул юлдан барабыз, аның дөреслеген нәтиҗәләр дә раслый: ел саен чыгарылыш сыйныф укучыларының яртысыннан артыгы беренче һәм икенче дәрәҗәдәге алтын медальләр ала. Лицей укучыларының йөз проценты Казан, Мәскәү һәм Санкт-Петербург университетлары белән илнең әйдәп баручы башка югары уку йортларына укырга керә. Без халыкара конференцияләрдә һәм фәнни басмаларда актив тәҗрибә уртаклашабыз, – ди Лилия Хәмитова.

Лилия Флүн кызы амбициоз бурычлар белән тулы бер еллык лицей тормышы циклын Раштуа классикасы белән чагыштыра:

– Минем өчен төп кышкы әкиятләрнең берсе – **«Щелкунчик».** Төп героиня үсә-үсә, сынаулар аша могҗизага ирешә. Лицейда да шулай ук: һәр уку елы колачлы максат һәм бурычлар белән башлана. Әмма финалга барлык мәсьәләләр хәл ителә, бурычлар үтәлә, һәм бу мизгелдә без нииндидер тылсымлы, дәртлегә әйләнәбез, яңа стартка әзер булабыз. Бәлки, безнең төп көчебез әнә шул процесста яңару һәм илһам табу сәләтендәдер дә.

ҺӘРКЕМНЕ ИШЕТҮ СӘНГАТЕ

Укучыларның дәүләт имтиханнарында тотрыклы югары баллары һәм фәнни конференцияләрдә җиңүләре – күп очракта системалы эш нәтиҗәсе. **Укыту эшләре буенча директор урынбасары Альбина Фәйзрахманова** әлеге процесс белән төп юнәлешләрне – йомгаклау аттестациясен, тикшеренү эшчәнлеген һәм педагогларның квалификациясен күтәрүне көйләп идарә итә. Мәгариф өлкәсендә законнар базасының даими яңартылуы, белем бирүнең һәм белемнәрне контрольдә тотуның яңа методлары, белем бирү киңлеген цифрлаштыру нәтиҗәсендә укытучыларга йөкләнешнең артуы, педагогларның квалификациясен күтәрүгә ихтыяҗ көчәю – болар барысы да һөнәрне катлаулы, әмма бер үк вакытта кызыклы һәм кирәкле итә.

– Белгеч укыту методикасы, педагогик психология һәм административ хокук өлкәсендә компетентлы булырга тиеш. Моннан тыш, **коммуникатив күнекмәләрнең** дә әһәмияте зур, – ди Альбина Раушис кызы.

ЛИНГВИСТИКА ВЕРТИКАЛЕ БУЕНЧА – ДӨНЬЯКҮЛӘМ ТАНЫЛУГА

Лицейда чит телләр «лингво + техно» белем бирү моделенә кертелгән. Монда филология юнәлеше техник иҗат белән тыгыз бәйләнгән. **Югары квалификацияле инглиз теле укытучысы Екатерина Гаврилова** лингвистика вертикаленең барлык этапларында да-Smart Kids балалар бакчасында, ILS (Intellectual Linguistic school XXI C.+) башлангыч мәктәбендә һәм лицейның үзендә – куратор булып тора.

– Без телләр, аерым алганда, инглиз теле, укучы өчен белем алуда һәм тормышта табигый ярдәмче булырга тиеш, дибез. Белем бирү балалар бакчасында башлана, башлангыч мәктәптә шул тел вәкиле белән дәресләр, тьюторлар белән аралашу, инглиз телендә театр, World around us* предметы өстәлә. Урта мәктәптә аны Science** алыштыра. Нәтиҗәдә, аннан соңгы этапта укучылар, лингвистиканы өстәмә белем белән берләштереп, җитди предметара проектлар әзерли, – ди Екатерина Михайловна. – Мәсәлән, Әскәр Биктаһиров җиденче сыйныфта үз хезмәтен традицион тәрәзә йөзлекләренә багышлады. Ул агач архитектура тарихын өйрәнде, CorelDrawда проектлаштыруны һәм компьютерлы станокларда эшләүне үзләштерде, ә йомгаклау тикшеренүен инглиз телендә тәкъдим итте. Мондый хезмәтләр милли мирасыбызны халыкара дәрәҗәдә популярлаштырырга мөмкинлек бирә. Әлеге проектлар белән безнең балалар төбәк һәм халыкара конференцияләрдә, бәйгеләрдә уңышлы чыгыш ясый.

Екатерина Михайловна тел өйрәнү сыйфатын һәр этапта тикшереп тора. Шуңа күрә дә өлкән сыйныф укучылары ТДИ һәм БДИны курыкмыйча тапшыра, еш кына инглиз телен үз теләкләре буенча өстәмә имтихан итеп сайлый.

– Әкият геройларыннан миңа **«Кунг-фу панда»дан По исемле панда** бик ошый. Ул үз дигәненә үҗәтлеге нәтиҗәсендә ирешә торган игелекле һәм ихлас персонаж. Лицейда да мин шундый ук нәтиҗәгә юнәлгәнлекне күрәм. Венера Кәшфи кызы, безнең директор, педагогларның һөнәри үсеше һәм осталыгы чынбарлыкка әйләнерлек шартлар тудыра, – ди педагог. – Укытучы буларак, төп бүләгем – безнең бакчада телләр өйрәнә башлаган баланың вакыт узу белән үз техник идеяләрен дөнья җәмәгатьчелеге алдында якларга әзер булган ышанычлы яшь тикшеренүчегә әверелүен күрү.

* World around us – әйләнә-тирә дөнья (ингл.)
** Science – фән (ингл.)



МОГҖИЗАЛАР ҺӘМ ЗУР АЧЫШЛАР КЫРЫ

Мәктәпкәчә балачак – шәхеснең нигезе салына торган уникаль этап. Smart Kids балалар бакчасында белем бирү процессы баланың танып белүгә табигый омтылышын үстерүгә көйләнгән. Биредә **мөдир Елена Баранова** җитәкчелегендә педагогика STEM-белем белән бергә бара: өч яшьтән башлап балалар уеннан һәм экспериментлардан конструкцияләүгә һәм модельләштерүгә күчә бара. Мондый караш баланы хәзерге дөньяга әзерли, җитәкчедән идарә итү күнекмәләрен генә түгел, остазлыкны да таләп итә.

– Безнең бурыч – укытуны кызыклы һәм тормышчан итү. Без, лицейның инженерлык юнәлешен нәниләр өчен җайлаштырып, тикшеренү форматларын һәм проект эшчәнлеген кертәбез. Тәрбиячеләр командасы, балалар белән бергә киләчәкне булдыру өчен, яңа технологияләрне үзләштереп, даими үсә, – ди Елена Геннадьевна. – Без лицей экосистемасының бер өлеше булып торабыз, гомуми стратегиябез 3.0не гамәлгә ашыруда катнашабыз, инженерлык белеменең дәвамчанлыгы принцибына таянабыз. Бу җәһәттән лицей минем өчен чын «могҗизалар кыры»на – 3D-принтерлардан алып роботларга һәм дроннарга кадәр технологияләр хәзинәләре урнашкан урынга әйләнде. Бу – педагоглар биргән белемне укучылар уникаль проектларга әйләндерә торган киңлек.

Елена Геннадьевна лицей тормышында төрле әкият сюжетларының чагылышын күрә:

– Җитәкченең осталыгы катлаулы ситуацияләрдән чыгу юлын табуда һәм үз образын мәрхәмәтле әкият сөйләүчедән алып тәвәккәл лидерга кадәр үзгәртә белүендә күренә. **Василиса Премудрая** – нәкъ менә шундый персонаж, күпкырлы, нык характерлы. Миңа аның оптимизмы һәм, кыенлыкларга карамастан, алга бару кыюлыгы ошый. Ә минем яраткан әкиятем ерак-ерак патшалыктагы Вовка турында – максатка ирешү өчен барысына да үзеңә өйрәнергә һәм үсәргә кирәк, – ди Елена Баранова. – Минем фикердәшләрем арасында эшлисем килә иде. Лицейда нәкъ шулай, мин үземнең зур эштә катнашуымны тоям. Венера Кәшфи кызы ярдәме белән мин үзебезнең «технологияләр мәгарәсе»ндә уздырылган һәр көннең бердәнбер һәм кабатланмас булуын аңлыйм, бу энергияне хезмәттәшләремә дә бирергә тырышам.

БУЛАЧАК ИНЖЕНЕРЛАР ТЕЛЕНДӘ

Цифрлы технологияләр һәм интерактивлык бүген мәктәпкәчә белем бирүдә беренче планга чыга. **Методист, югары категорияле укытучы-логопед Наталья Стрелкова** Smart Kids балалар бакчасы программасына инновацион белем бирү технологияләрен, баланың табигый үсешенә комачауламыйча, аны тулыландырырлык итеп кертергә булыша.

– Нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтә, чиксез фантазиягә ия булып, бала тикшеренүче һәм конструктор юлына баса. Күпер моделен җыйганда, балалар – логиканы, ә оча торган йорт уйлап табып, креативлыкны үстерә. Без балага иҗат итү һәм инициатива күрсәтү кызыклы булырлык мохит тудырабыз. Балалар бакчасында проект эшчәнлеге максатлар куярга һәм ниятләгәнне ахырына кадәр җиткерергә өйрәтә, – ди Наталья Евгеньевна.

Аңа **Марья-искусница** образы якын: әкият герое үз сәнгате белән гармония тудырган кебек, мөгаллим дә тәрбияләнүчеләрнең саф сөйләме һәм дикциясен булдыру өчен тырышып эшли, аларга үз көчләренә ышаныч өсти. Дөрес сөйләм үзеңнең беренче техник ачышларыңны тәкъдим итү коралына әйләнә.

– Без сабыйларга инженерлыкка әзерлек фикерләве һәм экологик грамоталылык векторын салабыз. Безнең «Батарейканы тапшыр, керпене коткар» акциясе балаларны җаваплылыкка өйрәтә, ә мини-роботлардан файдалану чүп-чарны сортларга аеру алгоритмнарын үзләштерергә ярдәм итә. Хәзер без үзебезнең илдә җитештерелгән «Фанкластик» 3D-конструкторы методик комплексын актив кулланабыз. Бу системалы эш: өч яшьлекләр детальләр белән таныша, ә алты яшьтә инде балалар ноутбукта виртуаль модельләштерүгә күчә, – дип сөйли Наталья Стрелкова. «Фанкластик» белән эшләү вак моториканы гына түгел, лексиканы да үстерә: балалар «яссылык», «кисем», «квадрат» кебек терминнар белән эш итә. – Мин үз эшемне һәр балага потенциалын ачуда ярдәм итү мөмкинлеге өчен яратам, дәресләрне зур киләчәккә беренче адымнарга әйләндерәм. Үз һөнәремнең асылын шунда күрәм.

УҢЫШ ИКЪТИСАДЫ

Бюджет белән нәтиҗәле идарә итү һәм инновацион финанс инструментларын гамәлгә кертү лицейга уникаль җиһазлар һәм алдынгы белем бирү технологияләрен сатып алу мөмкинлеген бирә. **Алсу Габдуллина җитәкчелегендәге финанс-икътисад бүлеге** заманча укыту өчен ныклы база булдыра. Законнарны яхшы белгәнгә, бүлек ташламалардан һәм ачык сатып алулардан нәтиҗәле файдалана, ә янга калдырылган акчаларны үсешкә юнәлтә.

– Финанслар белем сыйфатын яхшыртуга эшләргә тиеш. Без барлык закон яңалыкларын кулланырга омтылабыз: мәсәлән, беренчеләрдән булып электрон документ әйләнешенә күчтек, ата-аналарга салым чигерүләре алуны җиңеләйттек, – ди Алсу Бикбулат кызы. – Үзебезнең нәтиҗәле хуҗалык итү тәҗрибәбезне даими рәвештә хезмәттәшләребезгә дә җиткерәбез, чөнки мәгарифтә ресурслар белән дөрес идарә итә белү бүгенге көндә искиткеч мөһим булып тора.

Мондый җентекле эш аеруча сизгерлек һәм детальләргә игътибар таләп итә. Алсу Бикбулат кызына **халык риваятьләрендәге оста һәм зирәк хуҗабикә образы** якын, ул үзенең армый-талмый эшләве һәм кайгыртуы белән туган төбәгенең муллыгын тәэмин итә. Алсу Габдуллина саннардан балалар өчен реаль мөмкинлекләр тукымасын да шундый ук саклык һәм осталык белән тукып бара.

– Югары уку йортын алыштырырга була, ә мәктәп еллары кабатланмый, һәм лицейда һәр баланың үзен табуы мөһим. Инженер булмаса да, ул биредән көндәшлеккә сәләтле, уңышлы һәм бәхетле булып чыгарга тиеш, – ди Алсу Бикбулат кызы. – Безнең хезмәтебез балаларда укудан канәгатьлек һәм иминлек хисе, гомерлеккә бәхетле хатирәләр тудырсын иде. Мин үз эшемне һәм үзебезнең лицейны чын күңелдән яратам: көн саен бирегә шатланып киләм һәм һәркемгә шундый ук хисләр телим.



ОСТАЗЛЫК + УРТАК ИДАРӘ = ЛИДЕРЛЫК

Лицей белем бирүне генә түгел, ә карар кабул итәргә һәм аның өчен җаваплы булырга сәләтле шәхес, лидер тәрбияләүне дә максат итеп куя. **Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Дарья Николаева** моның өчен уртак идарәдән файдалана, административ бурычларны балалар үсеше өчен терәккә әйләндерә. Ул норматив планлаштыру, психологлар һәм сыйныф җитәкчеләрен координацияләү, профилактика эше, мәктәпнең вакыйгалар каркасын булдыру һ.б. өчен җаваплы. Бу күпкырлы эшчәнлектә традицияләрне зумерлар буыны трендлары белән тоташтыручы зирәк остаз булып калу мөһим.

– Мәктәпнең укучылар советында без балалар белән бертигез дәрәҗәдә идеяләр уйлап табабыз. Лицей укучылары мөстәкыйль рәвештә социаль челтәрләр алып бара, редактор функцияләрен башкара һәм контент булдыра. Минем роль – хуплауда: идеяләрнең ни дәрәҗәдә урынлы һәм форматка туры килүен әйтү. Без цифрлы квизлар, үзләренә кызыклы форматта чаралар оештырганда да укучыларның мөстәкыйльлеген хуплыйбыз. Мәсәлән, коворкингта карбыз белән сыйлана-сыйлана бөтен чиреккә план төзүне сизми дә калабыз, – дип сөйли Дарья Александровна.

Партнёрлык принцибын лицей укучыларының гаиләләре дә хуплый. Ата-аналар попечительләр советына керә, балалар проектларында экспертлар һәм хәтта фәнни җитәкчеләр булып та чыгыш ясый. Ә «Әтием сөйли» рубрикасы кысаларында әтиләр, медицина яки экология буенча үз тәҗрибәләре белән уртаклашып, укучыларга киләчәктә белем алу юнәлешен сайларга ярдәм итә.

– Вакыйгаларга бай мондый мохиттә чыннан да чын тылсымга ия буласы килә, – ди Дарья Александровна. – Мин, балаларның хәленә тиз арада төшенер өчен, **телепатиягә** ия булуымны теләр идем. Бу балага кайсы вакытта ярдәм кирәклеген, ә кайчан аңа киңәш тә җитәсен ялгышмый аңлау мөмкинлеген бирер иде.

КҮП БУРЫЧЛЫ РЕЖИМДА АЛЫШТЫРГЫСЫЗ БЕЛГЕЧ

Янгынга каршы, террорчылыкка каршы, юл иминлеген тәэмин итү, балалар бакчасы, башлангыч мәктәп, лицей биналарының һәм уку җиһазларының эшләвен тикшереп тору, лицейның өч автобусын һәм автомобильләрен төзек тоту, административ-хуҗалык эше мәсьәләләре буенча документлар әйләнешен контрольдә тоту – боларның барысын да **административ-хуҗалык эшләре буенча директор урынбасары Рифат Әсәдуллин** җиренә җиткереп башкара. Көн саен ул микроскоплардан алып лицей транспортындагы ГЛОНАСС системаларына кадәр уку йортындагы бөтен экосистема эшчәнлеген оештыра. Рифат әфәндене барыннан да бигрәк җитәкчелек итүне гамәли осталык белән берләштерә белүе өчен югары бәялиләр: ул теләсә нинди техник мәсьәләне хәл итүгә шәхсән керешергә әзер.

– Минем максатым – уку өчен имин һәм уңайлы мохит тудыру. Тәртип инвентарь, транспорт һәм документацияне даими контрольдә тотканга күрә саклана ул. Мин шулай ук балаларда мәктәпкә сак караш тәрбияләүне мөһим дип саныйм, чөнки тәртип аны саклаган җирдә генә саклана бит, – ди Рифат Әсәдуллин. – Еш кына минем эш көнем **маймыллар гаиләсе турындагы мультфильмдагы** әни маҗараларына охшаган. Тәртипне күзәтергә өлгерергә, балалар «экспериментларының» нәтиҗәләрен вакытында төзәтергә һәм эш процессына ышанычлы тыл тәэмин итәргә кирәк. Монда техник белем, шулай ук балаларны һәм үз эшеңне ихлас ярату мөһим. Мин үзебезнең зур лицей гаиләсенең бер вәкиле булуыма бик шатмын.

ИМИНЛЕК – УЛ ПРОФЕССИЯ

Дөрес туклануны оештыру, белем бирү йөкләнешен күзәтеп бару, оператив медицина ярдәме күрсәтү – әлеге һәм башка көндәлек бурычларны хәл итеп, контроль-күзәтчелек органнары, сәламәтлек саклау оешмалары һәм сак предприятиеләре белән хезмәттәшлек итеп, **балалар сәламәтлеген саклау буенча директор урынбасары Асия Ярмушева** лицейда һәр укучының сәламәтлеге һәм иминлеге җитди күз уңында булган тыныч мохит тудыра.

– Вакыт яңа таләпләр куя, һәм соңгы биш елда санитария законнары шактый яңарды. Без, укучыларга куркынычсыз мохит тудырып, оператив рәвештә заманча стандартларны кертәбез, – ди Асия Габделәхәт кызы. – Бу эштә кирәкле сыйфатлар – мәрхәмәтлелек, кыюлык, максатчанлык – минем яраткан әкият героем **Иван Царевичта** да бар. Ә максатларга ирешүдә системалылык лицейның хокукый документларын эшләгәндә һәм дәүләтнең катгый таләпләрен үтәгәндә бик мөһим.

Биредәге күп кенә хезмәткәрләрнеке кебек үк, Асия Габделәхәт кызы өчен дә лицей һөнәри планнар гына түгел, шәхси хыяллар да тормышка аша торган урынга әйләнгән.

– Венера Кәшфи кызына сәяхәт итү мөмкинлеге ачкан өчен чын күңелдән рәхмәтлемен. Бу һөнәри казанышларга илһамландыра! Теләсә нинди югарылыктагы интеллектуаль үрләрне яуларга әзер, сәламәт, уңышка йөз тотучы буын тәрбияләүгә өлеш кертүемә шатмын, – ди Асия Ярмушева.

ШАТЛЫК ТӘМЕ СЕҢГӘН ТӘНӘФЕСЛӘР

Зур интеллектуаль җиңүләр һәм катлаулы инженерлык проектлары кайнар иртәнге аш яки тәмле шулпа кебек гади әйберләрдән башка мөмкин түгел. **Ашханә мөдире Розалия Борисова** өчен төп принциплар – сыйфат һәм кайгыртучанлык. 2025 елдан лицей «ирекле сайлау» инновацион системасына күчкән: һәр укучы, берничә төр гарнир һәм кайнар ризык арасыннан сайлап, ланч җыя ала. Мондый алым балаларда туклану культурасын формалаштыра һәм һәркемгә күңеленә хуш килгән ризык табарга мөмкинлек бирә. Ә азык-төлекне җентекләп тикшереп алудан башлап ата-аналар комитеты тарафыннан даими дегустацияләр үткәрүгә кадәр катгый контроль файда һәм иминлекне гарантияли.

– Минем өчен һәр баланың ашаудан чын ләззәт алуы мөһим. Туклану кәефкә һәм укудагы уңышларга тәэсир итә, шуңа күрә без өйдәгечә тәмле итеп пешерергә тырышабыз. Азык-төлек департаменты һәм Роспотребнадзор белән тыгыз элемтәдә эшлибез, барлык регламентларны үтибез. Әмма шул ук эшебезне күңел биреп, яратып башкарабыз! – ди Розалия Борисова.

Розалия Альберт кызы өчен лицей югары квалификацияле ашчының һөнәри тәҗрибәсен педагог булу турындагы балачак хыялы белән берләштергән урынга әйләнгән.

– Балачакта һәм яшьлектә мин тәрбияче булырга бик теләгән идем, тик ашчы һөнәренә тукталдым. Зур рестораннарда еллар буе эшләгәннән соң, барыбер мәгариф учреждениесенә килдем. Безнең лицей – **хыяллар иң тылсымлы рәвештә тормышка аша торган җир** ул, – ди Розалия Альберт кызы. – Җитәкчелек ярдәме нигезендә хезмәттәшләребез белән дөнья күрә алдык, Германия, Төркия, Азәрбайҗанда булдык. Бу сәяхәтләр эшләргә көч бирә! Ә балаларның энергиясе, елмаюы, рәхмәте – безне тырышып эшләргә рухландыра торган көндәлек могҗиза ул.

HR-ПЕДАГОГИКА ТЫЛСЫМЫ

Мәгарифтә кадрлар белән эшләү еш кына регламентлаштырылган эчпошыргыч процесс буларак кабул ителә. Лицейда исә ул эмпатия һәм җылылык белән тулы. **Кадрлар буенча белгеч Гүзәл Чернова** хезмәткәрләрне эшкә алу, эштән җибәрү һәм күчерүне көйли, аларның шәхси эшләрен алып бара, дәүләт ведомстволары белән хезмәттәшлек итә, электрон хезмәт кенәгәләре, архив белешмәләре һәм катлаулы хисаплар белән идарә итә, шул ук вакытта һәр кәгазь артында

кешенең язмышы, стажы һәм булачак пенсиясе торуын бер генә секундка да онытмый. Гүзәл Ансар кызы, укытучыларның казанышларын тану иерархиясен мәктәп дәрәҗәсеннән алып министрлык бүләкләренә кадәр җентекләп теркәп, бүләкләү системасына аерым игътибар бирә.

– Мин үз эшемне һәм коллективыбызны чын күңелдән яратам. Кадрлар эшендә бераз психолог булу мөһим: кешеләр төрле кәеф белән килә, һәм мин аларны һәрвакыт елмаеп һәм аңларга әзер булып каршы алырга тырышам. Миңа кешенең кабинетымнан канәгать булып һәм проблемасы хәл ителеп чыгуы мөһим, – ди Гүзәл Ансар кызы. Лицейда аны һәр кешедә шәфкать һәм игелек күрә белүе өчен югары бәялиләр:

– Минем тормыш фәлсәфәм гади: яхшылыкка һәм ихласлыкка ышанам. Әгәр дә **тылсымлы таягым** булса, мин һәр кешене бәхетле һәм сәламәт итәр идем. Мәрхәмәтле әкияттәге кебек, һаман да әлеге кешелеклелек осталыгына өйрәнәм әле. Лицей минем өчен – һәркайсыбыз үзара хөрмәт итешә торган урын, һәм мин бу гармониянең озак еллар саклануы өчен җан атып эшләргә әзермен.

ӘКИЯТ ЯЛГАН БУЛСА ДА, БЕЛЕМ БИРӘ

Бүген остаз роле – әйдәп баручы лидер роле, ул реаль вакыт режимында технологик бурычларны хәл итә һәм аларны укучылар иҗаты өчен материалга әйләндерә. **Лицейның өстәмә белем бирү педагогы Александр Кузин**, балаларны үз үрнәге һәм актив позициясе белән катлаулы техник мәсьәләләрне хәл итәргә рухландырып, югары максатлар куя.

– Замана таләпләре зирәк һәм мәгълүматлы булырга өнди. Лицей миңа үземнең мөгаллимлек сыйфатларымны тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр бирде, һәм минем максатым – укучыларда кызыксыну уяту, аларга идеяләр дөньясында юл табарга ярдәм итү, – ди Александр Андреевич. – «Әкият» контекстында миңа **Иван Царевич** якын. Ул төрле геройлардан өйрәнә, сынауларны җиңә, бу аны тәвәккәл һәм белемгә омтылучан яшь укучыларга үрнәк итә. Бу герой хакыйкатьне эзләүдә үсеш, кыюлык һәм тырышлык символы булып тора, шулай ук зур казанышларга ирешү юлында остазлыкның мөһимлеген күрсәтә.

ӘЙБЕРЛӘР ИНТЕРНЕТЫНА КЕРҮ НОКТАСЫ

Әйберләр интернеты (IoT) өлкәсендәге идеяләр эшләүче прототиплар формасын алган чын инженерлык хабы – лицейда **КИТТУ-КАИ һәм PhD Пуатье Университеты (Франция) доценты, техник фәннәр докторы Евгений Денисов** җитәкләгән юнәлешне шулай тасвирларга мөмкин. Галимнең академик тәҗрибәсе проектлы якын килү белән берлектә укучыларга мәктәп программасы кысаларыннан бик еракка китәрлек мөмкинлекләр ача. Лицей укучылары, югары катлаулылыктагы бурычларны тормышка ашырып, югары уку йортлары студентлары белән тигез дәрәҗәдә көндәшлек итәргә тиеш.

– Лицейда эшләү фәнни эшчәнлегемне тулыландыра. Мин лицей укучыларын ел саен «Профессионаллар» милли чемпионатында «Әйберләр интернеты» компетенциясендә катнашырга әзерлим. Анда безнең укучылар илнең иң көчле командалары белән ярыша. Хәзер без балаларның интеллектуаль милеген яклауга һәм иң яхшы проектларны коммерцияле гамәлгә ашыруга күчәбез. Бу башлангычларның уңышына өстәмә белем бирү бүлегенең даими ярдәме һәм лицей җитәкчелегенең игътибары белән ирешелә, – ди Евгений Сергеевич.

Галимнең һөнәри юлы һәм технологик компетенцияләр узышы бөтен куәткә эшләүне таләп итә, һәм вакыт мондa иң кыйммәтле активка әверелә.

– Инженерлык проектлары белән эшләгәндә **вакытны туктата алу сәләте** бик файдалы булыр иде. Бу лабораторияләрдә тагын да күбрәк вакыт үткәрергә мөмкинлек бирер иде, – ди Евгений Денисов. – Әмма без хәзер дә уйланылган график һәм цифрлы инструментлар ярдәмендә эшнең югары темпын саклый алабыз. Яшь талантлар белән аралашуның һәр минуты нәтиҗәгә эшли.



КИЛӘЧӘК «СКРЕТЧ»ТА ЯЗЫЛА

Scratchтагы* беренче алгоритмнардан алып Unityда** уеннар булдыруга һәм профессиональ модельләштерүгә кадәр юл ерак түгел, тик моның өчен предметларны тәрбияләнүчеләренең әзлекләлеге, белем сыйфаты һәм проект эшчәнлеге үзе өчен мөһим булган тәҗрибәле, кызыксынучан остаз өйрәтергә тиеш. Лицейның **өстәмә белем бирү педагогы Алексей Капитонов** җитәкчелегендә балаларның цифрлы мохитне үзләштерүе нәкъ менә шул рәвешле ИТ-эшләүче компетенциясен алу мөмкинлеген бирә.

– Без бүгенге искиткеч заманда матур киләчәгебезне төзибез. Лицейда эшләү актуаль белемнәрне укучыларга тапшырырга һәм бергәләп инновацияләр булдырырга мөмкинлек бирә. Минем бурыч – балаларны мөстәкыйльлеккә әзерләү, аларда инженерлык фикерләвен үстерү, вакыт агымыннан алда барырга өйрәтү, – ди педагог.

Алексей Валерьевич өчен лицей һөнәри хыяллар гына түгел, **иң яшерен хыяллар да** тормышка аша торган киңлеккә әйләнгән.

– Лицей инициативасы белән оештырылган «Инженерлар республикасы» республика проекты педагогы сыйфатында мин Биектау районы мәктәпләренә укытырга йөри башладым, һәм шунда булачак кәләшемне очраттым, – дип сөенеп сөйли Алексей Капитонов. – Без бәхетле гаилә кордык, балабызга бер яшь тулды. Лицей миңа үз һөнәремдә уңыш казану һәм гаилә кору мөмкинлеге бирде, минем өчен чын көч урынына әйләнде.

* Scratch (Скретч) – тулаусез визуаль-блоклы программалаштыру мохите.
** Unity (Юнити) – эшләү-эшкәртү мохите.

Лицей тарихында һәр ел – яңартылган бурычлар, яңа кешеләр һәм яңа мәгънәләр белән яңа сәхифә ул. Мондый алга китеш иң мөһимен – үз эшенә гашыйк булган профессиональ команданы саклап кала белгәндә генә мөмкин. Һәм бу – лицейның тагын бер могҗизасы. Монда һәркемнең үз траекториясе бар. Укытучыларда – беренче педагогик тәҗрибәдән алып һөнәри танылуга кадәр, балаларда – инженерларча фикер йөртүдә беренче адымнардан алып җитлеккән проект һәм тикшеренү нәтиҗәләренә, җитди һөнәр сайлауга кадәр. Һәм хәзер, юбилей елында, бу траекторияләр йомгак ясауны таләп итми. Әкияттә иң кызыгы – аның яңа бүлеге бит.

Роман Рәмиз улы Фәтхетдинов, Казан шәһәре Совет районының администрация башлыгы:

Кадерле дуслар, хөрмәтле укытучылар, лицей укучылары белән ата-аналар!

Лицей – инженерлык үзәге коллективын чын күңелдән юбилее белән тәбрик итәм!

Ун ел эчендә сезнең лицей соклангыч юл узды, шәһәрдәге иң зур ихтыяҗ тудырган, һичкемнең теленнән төшми торган уку йортына әверелде. Сез кабатланмас белем бирү мохите тудыра алдыгыз, биредә мәктәпкә кадәрге әзерлек белән телләрне тирәнтен өйрәнү, гамәли-ориентацияле якын килү, белемнәрне чын проектларда сынап карау мөмкинлеге гармонияле рәвештә ярашып үсә.

Сезнең төп көчегез – һәр баланы укыту, тәрбияләүгә чын тормыш максаты итеп карый белүдә. Фәнни тикшеренү күнекмәләре белән ачышларга омтылу барлык укучыларда да уяна алырдай мохит тудыру – гаҗәеп казаныш. Биредә балалар бакчасындагы беренче адымнардан башлап, чыгарылыш сыйныфына кадәр – барысы да киләчәктә бала бәхетле тормыш төзи алырлык итеп тәрбияләүгә юнәлтелгән.

Сезнең лицей белем генә биреп калмый, тормышта кулланырлык төп компетенцияләргә дә өйрәтә. Сез балаларны уйларга, тормыш һәм хезмәт шартларына дөрес яраклашырга, бүгенге югары тизлектә үзгәреп торган дөньяда үсеш траекториясен үзенә зыян китермичә үзгәртергә өйрәтәсез. Монда гаиләләрнең үз балаларын бер-бер артлы укытырга китерүе аңлашыла да: сезне психологик уңайлылык атмосферасы, үзара хөрмәт яшәгән мохит һәм талантлы мөгаллим белән белемгә сусаган укучы очрашкан мизгелне билгели торган иҗади очкын кабынган урын булганга сайлыйлар.

Юбилеегыз белән котлап, укытучылар коллективына чын күңелдән зирәклеге, белемле һәм тормышка әзерлекле укучылар, уйлый белүче гражданнар тәрбияләү осталыгы өчен рәхмәт әйтәм. Сез һәр көн илебезнең киләчәгенә ныклы нигез саласыз.

Лицейның киләчәктә дә заманга ачык һәм илһамландыра торган урын булып калуын телим. Үсеш, иминлек, сөенеч китерә торган иҗади эшчәнлек насыйп булсын сезнең дус һәм тату коллективка! Ныклы сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс энергия, яңа җиңүләр – мөгаллимнәргә дә, укучыларга да!

Илсур Гәрәй улы Һадиуллин,
ТР мәгариф һәм фән министры:

Кадерле дуслар!

Казан шәһәренең Совет районында урнашкан Лицей – инженерлык үзәге быел 10 яшьлек олы юбилеен билгеләп уза. Шушы кыска, әмма гаҗәеп бай тарихлы вакыт аралыгында алар сокландыргыч уңышларга ирешә алды.

Биредә без инновацияләр белән традицияләрнең ничек яраша алуын күрәбез, үсешкә омтылышның балаларыбыз хакына берләшүгә хезмәт итүе белән очрашабыз.

Зур горурлык белән әлеге белем бирү концепциясенең уңышлы булуына басым ясыйм: нәкъ менә сезнең лицейда укучылар дөньяны танып белү юнәлешендә тәүге адымнарын ясый. Сез аларга балалар бакчасыннан алып чыгарылыш сыйныфына кадәр инженерларча фикер йөртү сәләтен, лингвистик комптенецияләрне сеңдерәсез.

Сезнең уку йорты ирешкән казанышлар тәэсирләндерә. Россия Вордскиллс юниорлар хәрәкәте белем бирү оешмаларының ТОП-100 исемлегенә керү, «Әйберләр интернеты – юниорлар» махсуслашкан компетенцияләр үзәге статусына ия булу, «Пилотсыз авиация системалары» федераль проекты кысаларындагы «Дроннар мәктәбе» лабораториясе» проектындагы уңышлар... Болар барысы да укытучылар коллективының искиткеч югары квалификациягә ия икәнлеген раслап тора.

Бигрәк тә «Инженерлар республикасы» проекты үзенең киң колачы белән җәлеп итә. Ул хәзер инде 10 муниципаль районны һәм 71 сыйныфта белем алучы меңнән артык укучыны үз эченә ала. Сез чын мәгънәсендә бер-берсенә иңдәш яңа буынны тәрбияләп үстерәсез, киләчәктә бу буын илебезнең элитасына әвереләчәк.

Лицей укучыларының халыкара олимпиадаларда җиңү яулавын күреп торабыз, бу сөендерә. Алар шулай ук мәртәбәле проектларда, конференцияләрдә катнаша: «Большие вызовы», «Сириус» сменаларыннан алып робот техникасы буенча халыкара бәйгеләргә кадәр.

Аерым рәхмәт сүзләрен лицейның директоры Венера Кәшфи кызы Хәйретдиновага җиткерәм. Аның уку-укыту процессын алдан күреп кора белүе, югары һөнәрмәндлеге, уртак хыялга ирешү максатында үз тирәсендә фикердәшләр туплый белүе, мөгаллимлеккә гомерлек тугрылыгы белем бирү оешмасын алдынгы рәтләргә чыгарды. Сезнең инициатива һәм кыю карарларыгыз лицейны чын инженерлык үзәгенә әверелдерде. Бу үзәк хәзерге көндә республикабыз, илебез мәгариф җәмәгатьчелеге өчен үрнәк булып тора.

Бөтен педагоглар коллективына баш иеп рәхмәт белдерәм – бу үз эшенең чын энтузиастлары командасы. Сезнең көн саен ару-талуны белми эшләвегез, хезмәтегезгә иҗади якын килә белүегез, камиллеккә ирешү өчен көчегезне кызганмавыгыз кабатланмас мохитнең нигезе булып тора да инде. Биредә һәрбер бала талантларын ача һәм үсеш кичерә ала.

Педагогларга алга таба да һөнәри үсеш телим, ә укучыларга – яңа ачышлар белән гаҗәеп җиңүләр! Әти-әниләргә исә – балаларының уңышларына куану шатлыгы!

Ирек Асаф улы Ризванов,
Казан шәһәре башкарма комитетының Мәгариф идарәсе җитәкчесе:

Лицей – инженерлык үзәге – чын мәгънәсендә киләчәк турында уйлый торган мәктәп. Биредә катлаулы бурычлардан курыкмыйлар, кыю рәвештә яңа юнәлешләргә юл сабалар, эзлекле рәвештә баланы инженер профессиясенә кертеп җибәрер өчен сукмак салалар – тәүге кызыксынуларыннан башлап инде мәктәпне тәмамлаганда кабул итәчәк карарына кадәр.

Лицейда һәр балага шәхес итеп, бик сак карыйлар. Аны инженерлар – технологияне яхшы белүчеләр мохитенә өндәп, киләчәктә булачак уку йортлары һәм һөнәрен куллана алырдай эш урыннары белән тыгыз элемтә булдыралар. Бу исәп-хисап өчен генә укыта торган урын түгел, юк, бу – тере мохит. Аның нәтиҗәләре – шуның күрсәткече: мотивациясе көчле, уйларга сәләтле, командада эшли белә торган балалар чыга бу уку йортыннан.

Лицей укучыларының күрсәткечләре – олимпиадалардагы җиңүләр, фәнни конференцияләрдә катнашулар, уңышлы проектлар. Болар барысы да үзләре турында сөйләп бирә. Әлеге казанышларның аргы ягында көчле педагоглар һәм белгечләр командасының җитди эшчәнлеге тора. Һәм бу команда өчен мәктәп ул эш урыны гына түгел, ә Венера Кәшфи кызының уңышлы җитәкчелегенә таянып, үзләрен үк үстерү мохите дә.

Лицей коллективын, укучыларны һәм аны тәмамлап чыгучыларны ихлас күңелдән котлыйм! 10 еллык хезмәт – нәтиҗәләр ясау, педагогларга ирешкән уңышлары, һөнәрләренә тугрылыклары өчен рәхмәт белдерү өчен бик уңайлы форсат. Һәм, әлбәттә, тагын да кыюрак, ышанычлырак итеп киләчәккә барырга теләк теләү өчен дә.

Лицейга алга таба да зур уңышлар, яңа үсеш баскычлары, куәтле белем бирү инициативалары, талантлы укучылар һәм колачлы казанышлар насыйп булсын!

КАЗАН ЛИЦЕЙ – ИНЖЕНЕРЛЫК ҮЗӘГЕНӘ 10 ЯШЬ ЮБИЛЕЙ БЕЛӘН!

Алсу Ринат кызы Әхмәтшина,
КФУның Идарә итү, икътисад
һәм финанслар институты директоры:

Хөрмәтле Венера Кәшфиевна, лицей укучылары, педагоглары һәм Казан шәһәренең Совет районы «Лицей – инженерлык үзәге» МАББУ коллективы! Лицейның фәнни җитәкчеләре исеменнән уку йортыбызны кадерле юбилее – 10 яшьлеге белән котларга рөхсәт итегез!

2016 елда Казанда Татарстан Республикасындагы беренче белем бирү кластерына нигез салынды. Ул үз эченә Smart Kids (3–6 яшьлек балалар өчен) балалар бакчасын, Intellectual Linguistic School башлангыч лингвистик мәктәбен (7–11 яшьлек балалар өчен) һәм инженерлар лицеен (11–18 яшьлек балалар өчен) алды. Белем бирү концепциясе укучылар өчен ике юнәлешне эзлекле алып бара – инженерлык һәм лингвистик юнәлешләрне. Инженерлык һәм лингвистик компетенцияләрне формалаштыру балалар бакчасыннан башлана, дәвам итә һәм инженерлар лицеенда формалашып бетә.

10 ел эчендә бу концепция үзенең чыннан да уңышлы булуын раслады. Бүгенге көндә лицей теләсә нинди конкурентлык сынавына җавап бирә алырдай белем бирү мәйданы булып тора. Биредә укыган балалар табигать фәннәре юнәлешендә дә, социаль фәннәр өлкәсендә дә иң югары сыйфатлы белем ала.

Лицей үсеше стратегиясе түбәндәге принциплар аша тормышка ашырыла:

1. Инженерлык кысаларында белем бирү концепциясен бердәй белем бирү процессы нигезендә өзмичә алып бару: Балалар бакчасы – Башлангыч лингвистик мәктәп – Инженерлык лицее – Университет – Предприятиеләр.

2. Профильгә кадәрле һәм профильле белем бирү кысаларында тел ягыннан һәм технологик белемнәр ягыннан укытуны тирәнәйтү, университетлар профессорлары белән мөгаллимнәрен җәлеп итү.

3. Профильле уку йортлары белән челтәр рәвешендәге тулы бер бәйләнеш булдыру (А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты (КИТТУ-КАИ), «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесенең Идарә итү, икътисад һәм финанслар институты, «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» Федераль тикшеренү үзәге» Федераль дәүләт бюджет фән учреждениесе, Мәскәү шәһәренең «Югары икътисад мәктәбе» Илкүләм тикшеренү университеты, «2.0 Казан талантлар ачык университеты АКБО, Казан Федераль (Идел буе) университетының Югары бизнес мәктәбе.

4. Профильле оешмалар һәм Россия предприятиеләре («Казан авиапредприятиесе» АҖ, «Speak English» Балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү үзәге» Өстәмә белем бирү АКБО, «Танкодром» Балалар иҗаты үзәге һ.б.) белән үзара элемтәләр челтәре булдыру.

Лицей җитәкчелеге тарафыннан заманча белем бирү инфраструктурасына нигез салу буенча зур эш эшләнде. Лицей саллы матди-техник базага ия, монда технологик профильле кабинетлар – хакспейслар да, техник лабораторияләр дә бар, шул исәптән – радио монтажлау, прототиплау кабинетлары. Аларда акыллы электроника белән робототехника эшләнә, кабинетлар 3D-принтерлар, лазерлы кисү җайланмалары, фрезер станоклары, Ben Maker яңа буыны өйрәнү кораллары белән җиһазланган.

«Лицей – инженерлык үзәге» МАББУ базасында 2024 елның гыйнвар аенда «Мәктәп дроннары» лабораториясе» проекты старт алды. Ул «Пилотсыз авиация системалары» федераль проектлары кысаларында нигезләнде. Проект балаларга өстәмә белем бирү юнәлешендә тормышка ашырыла, шулай ук очучысы булмаган авиация системалары (ОБАС) җитештерү, гамәлгә кую (эксплуатация) өлкәсендә белгечләрне системада өзеклексез әзерләү өчен юнәлтелгән. Әлеге проект «Россия Федерациясенең 2030 елга һәм перспективада 2035 елга кадәрле пилотсыз авиация үсеше стратегиясе» күрсәткечләре нигезендә тормышка ашырыла.

Лицейның алтын фонды – аның укучылары. Алар база дисциплиналарында ничек тиешле дәрәҗәдә белемле булса, гаять киң колачлы soft-компетенцияләр өлкәсендә дә шулкадәр дәрәҗәдә алга карап тәрбияләнә. Чит телләрне яхшы беләләр, проект менеджментын үзләштерәләр, ясалма фәһем компетенцияләре һәм иҗатны да колачлыйлар.

Лицейда өстәмә белем бирү системасы бик югары дәрәҗәдә куелган.

«Лицей – инженерлык үзәге» МАББУ укучылары халыкара, россиякүләм, төбәкара һәм республика олимпиадалары, конференцияләре, профильле вакыйгаларында даими катнашып килә. Һәм, әлбәттә, җиңүләр яулый, призлар ала.

2025/2026 уку елында лицей укытучылары бик җитди конференцияләр һәм вакыйгаларның җиңүчеләре, призерлары булды. Аларның кыска гына исемлеге дә инженерлык фәне һәм практикасының югары позицияләренә лаеклы алмаш киләчәген раслап тора, бу алдагы перспективаны да чагылдыра:

- MAKEX роботтотехника халыкара бәйгесенең PREMAKEX сайлап алу этабындагы «Барлык системаларны эшләтеп җибәрү» Starter компетенциясе;
- «Планета дежурные» халыкара космик сменасы;
- «Профессионаллар» милли чемпионаты;
- «Киләчәк инженерлары – Радист» һәм «IT – киләчәк инженериясе» электроника, программалау, робототехника өлкәсендә фәнни тикшеренү эшләре буенча бәйгеләр;
- «Электрон нанодөнья» урта һөнәри белем бирү буенча мәктәп укучылары һәм студентлар олимпиадасы;
- «Гамәли электродинамика, фотоника һәм тере системалар – 2025» яшь галимнәр, аспирантлар һәм студентларның XII Халыкара фәнни-техник конференциясе;
- «Хезмәт (технология)» халыкара мәктәп укучылары олимпиадасының «Мәгълүмати хәвефсезлек» юнәлеше;
- «Большие вызовы» фәнни-технологик проектлар буенча бөтенроссия бәйгесе.

Лицей берничә ел дәвамында «Сириус»ның профильле сменалары һәм белем бирү вакыйгаларында катнаша. Бу елның «Большие вызовы» фәнни-технологик проектлар буенча бөтенроссия бәйгесе финалына уку йортының биш укучысы чыкты, өчесе үз юнәлешләрендә җиңү яулады. Билгеле, болар барысы да лицейда укыту концепциянең дөрес корылган булуын, заманча югары компетенцияле кадрлар әзерләүнең перспективасын раслап тора.

Лицей – инженерлык үзәге ресурс үзәк буларак инде сигез ел дәвамында тормышка ашырып килгән җитди инициативаны да билгеләп узмый калып булмый. Бу – «Инженерлар республикасы» белем бирү проекты. Проект 2018 елның 1 сентябрендә старт алды, ул Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм фәнни тикшеренү техник университеты, Яшьләр инновацион иҗаты үзәге (ЯИИҮ-КАИ), Speak English инглиз теле мәктәбе канаты астында тормышка ашырыла. «Инженерлар республикасы» белем бирү проекты кысаларында, үзара элемтә челтәренә кушылып, республиканың 10 муниципаль районы эшли. Болар – Балтач, Лаеш, Биектау, Кукмара, Чистай, Алабуга, Түбән Кама, Арча, Әгерҗе, Казан шәһәре.

Проект кысаларында укучылар нигез белем белән беррәттән өстәмә белем дә ала, аларның индивидуаль уку-укыту программасы траекториясе эшләнә. Бүгенге көндә проектта 15 белем бирү учреждениесе катнаша, 76 сыйныфтан – 1221 укучы проектның өлеше.

Хәзерге вакытта лицей өстенлекле булган юнәлешләр буенча РФ төбәкләре һәм чит илләрдәге һөнәри үзәкләр белән элемтәләрне ныгыту ягыннан зур эш алып бара. Бу төбәкләр белән илләрнең икътисады сәнәгать җитештерүе, инженерлык инновацияләре белән тыгыз бәйләнгән, алар белән тәҗрибә уртаклашу, идеяләр алмашу гаять мөһим өлкә булып тора.

Бирелгә алып барган эшчәнлекнең нәтиҗәләре безгә алга ышаныч белән карарга мөмкинлек бирә. Илебез икътисады, дәүләт белән идарә итү системасы өлкәсенә югары дәрәҗәдә белем алган, яхшы әзерлекле кадрлар киләчәк, дип ышанабыз. Алар безнең киләчәк җәмгыятен тагын да үстерәчәк һәм алларында торган һәммә җаваплы бурычларны да сынатмыйча тиешле дәрәҗәдә үти алачак.

Мәктәп укучылар үзидарәсендә катнашучылар ТР Дәүләт Советында.

СӘНГАТЬ ЮГАЛЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ!

Руфия Фазылова

Редакциябезгә бик күптәннән рәссамнар килгәне юк иде. Әлеге кимчелекне төзәттек: бүген бездә үзенчәлекле, мәртәбәле кунак – Равил Сәйяр улы Айдаров.
Ул Татарстанның атказанган архитекторы, танылган рәссам да.
Равил Сәйяровичның бабасы Ситдыйк Айдаров – татар театрының чишмә башында торган артистларның берсе. Шулай ук татар опера җырчысы буларак та беләбез. Әбисе Галия Кайбицкая – ТАССРның беренче халык артисткасы. Әтисе Сәйяр Айдаров исә танылган архитектор, гомере буе Казаныбызның тарихи йөзен саклап калу өчен үзеннән зур өлеш керткән шәхес. Равил Сәйярович гаҗәеп кызыклы кеше: төрле җирләрдә хезмәт куйган, бик күп илләрдә сәяхәттә булган.

– Равил Сәйярович, Айдаровлар нәселе татар мәдәниятендә тирән эз калдырган. Сез исә – әлеге нәселнең лаеклы дәвамчысы. Бу сезнең өчен җаваплылыкмы? Бабагыз Ситдыйк Айдаров турында сездә нинди истәлекләр яши?

– Нәселебез турында әйткән җылы фикерләрегез өчен рәхмәт, чынлап та, мондый нәсел дәвамчысы булу – зур җаваплылык. Кызганыч, бабам Ситдыйк Айдаровны белмим, чөнки ул бик яшьли – кырык ике яшендә вафат булган. Заманының популяр артисты, җырчысы. Ә әбием Галия Кайбицкаяны яхшы беләм. Ул Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшевләр белән аралашкан кеше. Галия әбиемнең икенче никахы да була, ул ТАССРның халык артисты Ильяс Әүхәдиев белән гаилә кора. Ул гаиләдә ике балалары да туа.

– Әтиегез Сәйяр Айдаров турында да ишетәсе килә. Нинди авыр елларда

Фото: Александр Ефремов, гаилә архивыннан.

да Мәскәү архитектура институтын тәмамлаган. Сезгә этиегезнең нинди сыйфатлары күчкән?

– Иҗат өлкәсендә нәрсәгәдер ирешкәнмен икән, барысы өчен дә этигә рәхмәтлемен. Этинең сүзе безнең өчен закон булды. Гаиләдә аның абруе бик зур иде. Әмма аның беркайчан да тавыш күтәргәнен, начар сүз әйткәнен хәтерләмим. Безнең гаиләдә бер-беребезгә карата чын мәгънәсендә хөрмәт яшәде. Монда мин әнинең ролен дә ассызыклыйсым килә. Әни иҗат итәр өчен этигә бөтен шартларны тудырды, аны көндәлек вак-төяк эшләрдән азат итте. Эти фәкать үз эше белән яшәде: башта – кандидатлык, аннан докторлык диссертациясен язды һәм яклады. 1994 елда Казанда аның проекты буенча төзелгән «Рамазан» мәчете ачылды. Эти үз һөнәренә җаны-тәне белән бирелгән чын профессионал иде. Ул Казанның милли йөзе булуын теләде, шул юнәлештә хезмәт куйды. Студент булгач, мине дә күп кенә эшләренә җәлеп итте. Мин аны чын мәгънәсендә укытучым дип тә саныйм.

– Сез мәктәп белән параллель рәвештә сәнгать мәктәбен дә тәмамлагансыз. Монда этиегезнең өлеше зур булдымы? Әллә инде сәнгать мәктәбендә уку үз хыялыгыз, максатыгыз идеме?

– Ә мин башка юлны күрмәдем дә, чөнки үземне белгәннән бирле өйдә карандаш белән кәгазь иде. Шуның өчен дә сәнгать мәктәбендә укуым бик табигый булгандыр.

Эти турында сөйләгәндә, әниемне дә күләгәдә калдыра алмыйм. Әни – батыр да, уңган да, белемле дә ханым. Нинди авыр заманнарда да ул безне ачка интектермәде. Акча булу – бер хәл, ризыкны таба белергә дә кирәк иде бит. Өстәлгә бер килограмм ит алып кайту өчен ничә җиргә барырга кирәк. Һәм бу эшләр нәкъ менә әни җилкәсендә булды. Шөкер, әниебез бүген дә исәнсау, күптән түгел 97 яшен тутырды. Йөгереп йөри әле, шуңа ихластан сөенәбез. Тумышы белән ул Әтнә районыннан. Югары белемле физик, күп еллар Казан дәүләт медицина университетында хезмәт куйды. Эшендә бик хөрмәт иттеләр.

– Равил Сәйярович, сез архитектор да, рәссам да. Үзегезгә кайсы өлкә якынрак кебек?

– Архитектор булып шактый эшләр эшләдем: Яңа Савин районындагы базарны без булдырдык, башка объектлар да бар. Ләкин тормыш алга бара, безгә алмашка яшьләр килә. Бу табигый һәм моңа гаҗәпләнәсе түгел. Егерме ел элек Казан дәүләт архитектура институтына эшкә килдем. Бирегә мин студентларга рәсем сәнгатен өйрәтәм. Һәм параллель рәвештә картиналар ясыйм. Шулай булгач, бүген үземне рәссам дип әйтә алам.

– Чынлап та, сез Казан дәүләт архитектура университеты профессоры. Яшьләр белән, заман белән бергә атларга авыр түгелме?

– Заман үзгәргән саен кыйммәтләр дә үзгәрә. Бүген ясалма фәһем рәсем дә ясый ала, текст та яза. Тик моның белән килешә алмыйм. Билгеле вакыйгаларга кадәр, безнең сту-

Җәмәгате Галина Николевна белән.

дентлар чит илгә стажировкага йөрде. Ә анда аларның талантына, әзерлегенә шаккаталар иде. Рәсемне скелет ясаудан башлыйлар: аннан соң гына әгъзалар, киемнәр барлыкка килә. Безнең студентлар менә шуларның барысын да эшли белә иде. Ә бүген студентларга моны белмәсәләр дә ярый башлады, чөнки компьютер бар. Әлбәттә, бу мине борчый. Сәнгать югалырга тиеш түгел! Бу бит бөтен дөньяда шул хәл! Шөкер, әле безнең студентлар рәсем буенча уздырылган дәрәҗәле конкурсларда беренче урыннарны яулый. Казан дәүләт архитектура университетының базасы ныклы, коллектив көчле. Нәтиҗәдә, студентларыбыз да начар түгел. Тик вазгыять роботлашуга бара икән, безнең студентларга да кагылыр, дип уйлыйм. Дөресен генә әйткәндә, ул көннәрне күрәсем килми...

– Казанның агач йортларын сезнең кебек күп ясаган рәссамнар тагын юк кебек... Ул сурәтләрдәге йортларның күбесе инде башкалабызда юк та. Бу сезне борчыймы?

– Бер яктан борчый, әлбәттә. Казанда сүтеләсе йортлар калмады да бугай инде. Икенче яктан... Бер очрак турында сөйлим әле. Элек без Вахитов районында, «Мир» кинотеатры янында яшәдек. Заманында әтигә шундагы бер йортның беренче катында өч бүлмәле фатир бирделәр. Ә каршыда ике катлы агач йортлар бар иде. Шул йортларның берсендә сыйныфташым яшәде, этисе университет доценты иде аның. Менә шул зыялы гаиләнең нинди шартларда яшәгәнен күрсәгез! Кыш көне стеналары ап-ак бәс була иде, бәдрәфләре – урамда... Мин Вахитов районының баш архитекторы булып эшләгәндә, ул йортларны сүттеләр. Сыйныфташымның гаиләсенә Николай Ершов урамыннан яңа йорттан өч бүлмәле фатир бирделәр, әти-әнисе аерым фатирга күченде. Һәм аларның ничек сөенгәннәрен күрсәгез! Шуңа да бу йортларны сүтү халык өчен начар дип әйтү дөреслеккә бик үк туры килми. Әгәр ул агач йортларны төзекләндерә башласаң, яңасын салуга караганда кыйммәткәрәк чыга. Аннары, нәрсә генә эшләтсәң дә, ул агач йортларны заманча тораклар кебек итә алмыйсың, чөнки андый мөмкинлекләр юк. Әлбәттә, тарихи бина буларак аерым йортларны саклап калырга кирәк иде, дип саныйм. Тик инде эшлисе эшләнде.

– Сез әле авыл, районнар буенча йөреп йортлар ясаган рәссам да. Әйтергә кирәк, картиналарыгызның җаны бар, авыл рухын тоя беләсез. Моңа Арчада тууыгыз да сәбәпче түгелме?

– Бардыр инде. Тик хикмәт икенчерәк, дип уйлыйм. Авыл йортларына багышланган берничә китабым бар: җәмәгатем Галина Николаевна белән Актаныш, Саба, Биектау, Әтнә районнары буенча йөреп чыктык. Андагы йортларны фотога төшереп, соңрак аларга карап рәсем ясадым. Милләте буенча рус булса да, җәмәгатем татарларның милли бизәкләрен, культурасын бик яхшы белә. Фән докторы, танылган архитектор. Без аның белән тандемда эшләдек, нәтиҗәдә, сез әйткән «авыл рухын бирә торган картиналар» туды.

Төрле җирләрдә йөздән артык күргәзмә эшләдем. Һәм күпләр минем картинадагы детальләрне аерып әйтә. Чынлап та, мин бик төгәл кеше: йорт икән, тәрәзә йөзлекләрен ничек бар, шулай бирү яклымын. Алайса хәзер, югары сәнгать дип, буяу катнашмасы чәпәп кую модага китте. Имеш, бу фәлән әйберне аңлата, аңа тирән мәгънә салынган... Рәссамның сәләте юк дигәнне аңлата бу, шул гына!

– 2016, 2023 нче елларда сез Тукай премиясенә дәгъва кылдыгыз. Әмма бу мәртәбәле исемне әлегә сезгә бирмәделәр. Тукай премиясенә янә кандидатурагызны куярга уйламыйсызмы? Бер карасаң, язучылар да бишәр тапкырдан соң гына ала бу исемне...

Гаилә бергә җыелганда.



Кабан күле буендагы йорт.



– Юк, башка андый ният тә, чама да юк. Югыйсә, икесендә дә икенче турга узган идем. Тукай премиясенә дәгъва кылу өчен күп көч куярга кирәк: эшләгән эшеңне күрсәтергә күпме документ җыярга, күргәзмәләр эшләргә, чыгышлар ясарга... Яңадан бу эшләр артыннан йөрисем килми. Хәзер сәламәтлек тә икенче, өч ел элек инсульт кичердем. Әлегә исәнлекне кайгыртырга кирәк.

Тукай премиясе бик бәхәсле әйбер: язучылар ул фәкать әдәбият кешеләренә бирелергә тиеш, дигән караштa тора. Югыйсә рәссамнар, композиторлар да халыкка хезмәт итә, аның зәвыгын күтәрү өчен эшли. Тагын бер күзәтүем: Тукай премиясен бүген конкрет хезмәт өчен түгел, ә кирәк булганга, инде ул фәлән яшькә җитте бит, алып калсын, дип бирә башладылар. Әлбәттә, мине бу гаҗәпләндерә.

– Равил Сәйярович, сезнең музей-йортыгыз барлыгын беләбез. Коллекциягездә ниләр бар? Аның үзенчәлеге нәрсәдә?

– Яшел Үзән районының Ильинский авылында йортыбыз бар. Җәй буе шунда яшибез. Кышын исә яллларга барабыз. Менә шул йортта музей булдырдым. Ул нигездә элеккеге хуҗалардан калган йорт бар иде. Шуны сүткәндә, иске көнкүреш әйберләре чыкты. Аларны ташларга кул бармады. Шуннан башланды инде... Бизәкле ишек тоткалары, самоварлар, тегү машинасы һ.б. Арада аеруча кадерле, тарихи әйберләр бар.

– Улыгыз Руслан да сезнең эздән киткән. Бу сезнең өчен сөенечме?

– Сөенеч. Ләкин оныклар безнең юлдан китмәде. Улымның беренче никахыннан улы бар, зур инде. Ул да иҗат өлкәсендә кайный – музыка яза, шуның белән тормыш алып бара. Икенче хатынынннан кыз бала туды. Ул да студент инде, дизайн өлкәсендә эшли. Шулай ук үзен үзе тәэмин итә, дәрәҗәле журналлар белән хезмәттәшлек алып бара. Ике оныгым белән дә бик горурланам. Улым бүген гаиләсе белән Мәскәү янында яши, зур гына йорт салып чыкты. Матур гына тормыш алып баралар. Безнең өчен зур сөенеч.

– Равил Сәйярович, сезне күпләргә үрнәк итеп куярга мөмкин: картиналарыгызның электрон галереясы бар. Һәм ул бик җайлы, зәвыклы эшләнгән. Сезгә бу эштә берәр кеше ярдәм итәме?

– Улым ярдәм итә, аңа рәхмәт. Мин инде хәзер сайтлар алып барырлык яшьтә түгелмен. Без бит икенче заман кешеләре. Сайтымны тулыландырырга җәмәгатем Галина да булыша, ул менә заманнан арттан калмый. (Көлә – **авт.**)

– Күптән түгел 75 яшегезне тутырдыгыз? Яшь барганы сизеләме?

– Әйткәнемчә, инсульт кичердем. Аңа кадәр үземне кырык яшькә хис итә идем. Хәзер сакланырга тырышам: авыр әйберләр бик күтәрмим.

Бер әйбергә сөенәм: әле ярый эшем бар. Яшьләр арасында йөргәч, барыбер картлык турында уйламыйсың, үзеңне тонуста тотасың.

Гел иҗатта мин: картиналар язам, күргәзмәләрдә катнашам. Туклануга килгәндә, аерым диета тотмыйм. Җае чыкканда физик күнегүләр ясыйм, озак итеп паркларда йөрим. Машина йөртәм, тик эшкә җәяү барам, сәламәтлек өчен файда булсын, дим. Кыскасы, тулыканлы тормыш белән яшим, дип әйтә алам. Т

Казан күренешләре.

мәңгелек кыйммәтләр /

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

София Гобәйдуллина илһамны **каян** алган

Чыгътай татар тарихында **нинди** эз калдырган

Беренче татар китапханәсе **кайчан** ачылган

Полиглотлар **кайсы** авылда яши

СОФИЯ ИСЕМЛЕ ГАЛӘМ

Владимир Матылицкий

София Гобәйдуллина туган шәһәренә триумф белән 2001 елда әйләнеп кайтты. Ул чакта атаклы Валерий Гергиев, симфоник оркестр, хор һәм Мариин театры солистлары белән Казанны шаккатырды ул. Мәркәзебез консерваториясенең Зур концертлар залында Гобәйдуллинаның катлаулы, кабатланмас дини-фәлсәфи карашларын чагылдырган күренекле әсәре – «Страсти по Иоанну» ораториясе яңгырады.

ФӘКЫЙРЬЛЕК БЕЛӘН НАМУСЛЫЛЫК

30 нчы еллар азагында әниләре Ирек мәйданы буйлап апасы белән икесен музыкаль мәктәпкә алып барганда, Соня үзенең булачак триумфы бинасы урынында бәләкәй генә сквер булуын хәтерләгәндер...

Аның балачак еллары узган Казан 30 нчы еллар азагы – 40 нчы еллар уртасына карый. Ул без хәзер белгән шәһәрдән аерылып тора, билгеле: опера театры урынында – сквер, Ленинга һәйкәл әле куелмаган, Хөкүмәт йорты урынында – боегып кына утыра торган ике катлы Пишмаш заводы йорты. Казансуга төшә торган сукмакта – 2–3

Зур концертлар залы.

Фото: автор, tatmitropolia.ru, Айдар Мөшәрәпов, hram-klad.narod.ru алынды. Архив фотолары – С. Гобәйдуллина исем. Заманча музыка үзәгеннән

С. Гобәйдуллина исем. Заманча музыка үзәге.

катлы агач йортлар. Алар яшәгән Тельман, 29 адресы буенча урнашкан коммуналка да әллә ни ис китәрлек түгел. Гобәйдуллиннар аның 3 нче катындагы 3 бүлмәдә яши.

Фәкыйрьлек белән әхлак, намуслылык – бу төшенчәләр бәләкәй кызның аңына әнә шул сабый чагында ук бик ныклап кереп урнаша. Ул моны соңрак әтисе язмышы белән бәйле ваемлый һәм аңлата да – зур хөрмәткә лаеклы кеше, үз эшенең яхшы белгече булуына карамастан, геодезист, җирне өйрәнүче белгеч Әсгать Гобәйдуллин партиягә керергә ашыкмый. Репрессияләр котырынган чорда кемнәрнеңдер язмышын хәл итүдә катнашырга теләми ул. Һәм бу позициясе өчен көнкүрештәге фәкыйрьлек белән түләргә туры килә. Ләкин рухи як пакь кала.

Нәкъ менә «намуслылык белән фәкыйрьлек» кебек төшенчәләре өчен әтисенә гомере буе рәхмәтле була София Гобәйдуллина. Тирә-ягы уңайлырак, күркәмрәк булса, аның карашы, өмет эзләп, Күккә төбәлмәгән булыр иде. «Рухлары белән фәкыйрьләр бәхетле, чөнки Күк Патшалыгы аларныкы булыр» дигән изге китап сүзләрен Соня, Галәм пышылдавына колак салып, эмпирик рәвештә кабул итә. Йолдызлы Казан күген әле ул чакта биек йортлар каплап тормый. «Минем әйләнә-тирәмдә шулкадәр фәкыйрьлек хөкем сөрә, илһамланыр бернәрсә дә юк, ахрысы шуңа да минем бөтен фантазиям Күккә юнәлде», – дияччәк ул соңрак.

Әтисе Югары Осланда җәйге ялга арендага алып торган агач авыл йортында 4 яшьлек Сания тәүге мәртәбә Коткаручы тәресен күрә... һәм аны «танып ала». Әмма бу феномен турындагы сорауларны эти-әнисе артык куертып торырга юл куймыйлар, өйне дә алыштыралар.

БОРЫНГЫ РОЯЛЬ

Апасы Ида белән алар еш кына күршедәге яшүсмер Пашка уйнаган гармунга бииләр. Пашка акылга җиңелрәк була, әмма күңеле саф, чиста, үзе беркатлы... Ул уйнаганда, бөтен бала-чага аның артыннан ияреп йөри. Ишегалды «концертлары»ның берсендә Гобәйдуллиннарның кызларын күрше йортта яшәүче Екатерина Леонтьева күреп, дөресрәге, ишетеп ала. Ә ул – Казанның атаклы 1 нче музыка мәктәбе укытучысы. Гобәйдуллиннарга кереп, ике кызны да музыка мәктәбенә тыңларга алып килергә киңәш итә. Мәктәп директоры Рувим Поляковка кызлар бик ошый, тик Соня гына кечкенә – әле аңа биш кенә яшь. Үзен алмауларын бәләкәй Соня зур фаҗига буларак кабул итә... Директорның чалбарына ябышып, үкереп елап җибәрә. Тиз арада педсовет җыялар һәм «биш яшьлек баланы искәрмә буларак укырга алырга» дигән карар кабул итәләр.

Боратынский йорты. Биредә 30–40 нчы елларда – 1 нче музыка мәктәбе, Бөек Ватан сугышы елларында Казан музыка училищесы урнашкан була.

Шуннан соң Гобәйдуллиннар өендә «Слесарь» рояле пәйда була. Аны гаилә башлыгы акцияләргә алыштырып алып кайта (нәп чоры икәнен онытмыйк). Инструментның арзанлыгын да, аны җирле оста Слесарев кына ясавын да истә тотарга кирәк: кызларга кыйммәтле чит ил рояленең «җанын алырга» бирмәсләр иде. «Ачык рояль минем өчен театрга, храмга тиң иде, – дип искә ала композитор. – Ида апам рояль каршына утыра да клавишаларга бармаклары белән орына, педальгә баса, ә мин кылларда импровизация ясарга керешәм... Бу аһәңнәр дөньясын ачу тылсымы иде!»

Соня өйдәге инструментта искиткеч авазлар чыгара, аларны «матур итеп» чиратлаштырырга тырыша һәм 6 яшендә үк мәктәптә бирелгән пьесаларның «үзе чыгарып караганнардан кайтышрак, фәкыйрьрәк» икәнен абайлап ала. Ул туктаусыз импровизацияләр ясый, ялгыз калганда, ярымкараңгыда аның өстенә каяндыр Югарыдан аһәңнәр тулы ташкын ишелә дә ишелә...

КАРАҢГЫДАН – ЯКТЫЛЫККА...

Рояль каршында утыру вакытын алар Ида белән бертигез бүләләр. Минутлап, сәгатьләп. Әмма шулай берсендә, Ида «лимиттан тыш» утыргач, Соня, ярсып, кубарылып, апасын инструменттан читкә этеп җибәрә. Соңыннан, инде олыгайгач, бу гамәле өчен үкенеп, София Әсгатовна болай ди: «Бу явызлык иде. Минем эчемдә иблис утырганга шулай килеп чыкты».

Сания рояльдә уйнап утыра.

Соняны караңгылык һәм ялгызлык әсәрендерә. Ул каяндыр үзенә инүче аһәңнәрне тоясеңдерә, эңгердә, караңгыда уйнарга ярата... 13 яшендә, шундый медитацияләрнең берсе вакытында, Соня һушын җуеп егыла. Ә аннары, аңына килгәч, тулы прострациягә бирелә: табиблар берничә ай дәвамында баланы кире үз халәтенә кайтарыр өчен көрәшә. Эти-әнисенең рөхсәтен алып, күрше хатыны храмга бара һәм Соня өчен Изге Ана образы каршында дога укып кайта, Сорокоустка заказ бирә.



Арча зиратында Ярославль Могҗиза кылучылары чиркәве – Казанда сугыш чорында эшләгән бердәнбер гыйбадәтханә.

Музыка училищесы, Жуковский ур., 4 нче йорт.

Соня терелеп, тернәкләнеп китә. Аны, әйтерсең, алыштырып куялар: интроверт баладан чып-чын экстравертка әверелә. Урам уеннарында актив катнаша, мәктәп чараларын калдырмый, концертларда чыгыш ясый. Спорт гимнастикасы буенча яшүсмерләр разряды ала. Соңгы елларында, бу вакытны искә алып, София Әсгатовна: «Караңгылык мине әле бик озак ымсындырып торды, әмма мин аңлы рәвештә яктылыкка таба бардым», – ди.

Музыка белән шөгыльләнүдән кала, башлангыч мәктәптә алган башка белем аны әллә ни алгысытмый. Классташлары искә алуы буенча, аларның аралашу урыны ишегалды була. Анда алар качышлы да уйный, куышлы да, «ватык телефон» да. Кышын якындагы таудан һәм Тельман урамыннан Космодемьянскаяга төшә торган калкулыктан чана шуалар. Космодемьянская урамындагы 15 нче йортның киң баскычында сугыш хәлләре, соңгы яңалыклар турында гәпләшәләр.

Ике ел эчендә Соня ике мәктәптә укый, әмма икесе дә сугыш башлануга госпитальгә әверелә. Укытучылары Александра Янонис балаларны үзенең өендә укыта башлый. Шунда, дәресләр алып барган арада, бәрәңге калдыклары белән аларның тамакларын да туйдыра: «Цингадан витамин сезгә», – дия торган була. Балалар госпитальгә йөриләр, хатлар язалар, аларны солдатларның туганнарына җибәрәләр. Яралыларга китаплар укыйлар, концертлар куялар. Соня ул концертларда шигырь сөйли.

Элеккеге Хатын-кызлар рухани мәктәбе, бүген – һөнәри белем бирү үзәге. Бирегә 1939 елда Сания Гобәйдуллина 83 нче мәктәпнең 1 нче классына укырга килә.

«БАРЫСЫН ДА ТЫҢЛА, ТИК БЕРКЕМ СҮЗЕНӘ ДӘ ИЯРМӘ...»

1945 елда, Җиңү язында, Соня музыка мәктәбен тәмамлый. Ул Алексей Бормусовның гармония дәресләрен үлеп ярата торган була. Аннан соң Казан музыка училищесында фортепиано классында Мария Пятницкаяда белем ала. Петербург мәктәбе традицияләре тарафдары булган бу мөгаллимә училищеда 1904 елдан ук эшли. Ул Соняның «музыкаль әнкәсен» – Леонтьеваны да тәрбияләгән шәхес.

Сугыш вакытында училище бинасын Казанга эвакуацияләнгән И. Павлов исемендәге фәнни институт били, ә училищены музыка мәктәбе үзенә сыендырып тора. Монда Мәскәү, Ленинград, Киев консерваторияләре студентлары укый. Еш кына күренекле артистлар чыгыш ясый. Араларында Елена һәм Михаил Гнесиннар да була.

Училище студенты чагында Соня шәһәр концертларында бик теләп уйный, Ильяс Әүхәдиев дирижёрлык иткән оркестр белән бергә чыгыш ясый. Кызның тәүге әсәрләреннән берсе – полька – 1947 елның 28 декабрендә Казанның балалар музыка мәктәпләренең 15 еллыгы уңаеннан оештырылган концертта башкарыла.

Консерваториядә композицияне аңа факультатив рәвештә Альберт Леман белән Нәҗип Җиһанов укыта. Пианист буларак әзерлекне Леопольд Лукомский бирә. Соня гомере буена ул биргән киңәшне хәтерендә нык тота: «Барысын да тыңла, тик беркем сүзенә дә иярмә».

Дәүләт комиссиясе каршында Сания Гобәйдуллина Ференц Листның «Пляска смерти» композициясен уйный. Аңа башкаручы буларак гаҗәеп карьера ясаячагы турында әйтәләр, зур киләчәк юрыйлар. Ләкин кыз уйнарга түгел, ә әсәрләр язарга карар кыла. Укытучысы сүзенә таянып, «үз йөрәген тыңлый».

София Гобәйдуллинаның табигатен Альфред Шнитке дөрес итеп тасвирлап бирә: «Ул аңлашылмый. Шуңа да ул – могҗиза. Аңа тиңнәр юк».

Касаткин урамындагы 24 нче мәктәп, хәзер – ТР Финанслар министрлыгы.



КАЗАНСКИЙ ГОРОДСКОЙ ОТДЕЛ ПО ДЕЛАМ ИСКУССТВ

XV
1932—1947

ПРОГРАММА КОНЦЕРТА,
посвященного 15-летию
ДЕТСКИХ МУЗЫКАЛЬНЫХ ШКОЛ
ГОР. КАЗАНИ

28 декабря 1947 года

НАЧАЛО В 12 ЧАСОВ ДНЯ

27. Смолина Нина
28. Соловьев Константин
29. Тарасова Лия
30. Туктамышева Диляра
31. Фатхуллин Рафаил
32. Фоминых Вадим
33. Хайруллин Рузалет
34. Хасанов Алия
35. Хворова Наталия
36. Черманова Ирина
37. Чикурин Рудольф

Класс ансамбля преподавателя Р. С. Гермин, у рояля Губайдуллина Ида.

Лукомский. За мотыльками
Жиганов. Стрекоза
Исп. уч. IV кл. Ахмедова Людмила. Класс Засл. деятеля искусств ТАССР преподавателя В. Н. Фрейман.

Григ. Колыбельная
Исп. уч. III кл. Аухадеев Ирик. Класс заслуж. деятеля искусств ТАССР преподавателя И. В. Аухадеева, у рояля Юсупова Роза.

Чайковский. Мазурка
Исп. уч. VI кл. Дягаш Лилиана. Класс преподавателя А. В. Чернышевой.

Давыдов. Романс без слов
Исп. уч. IV кл. Гаврилов Гегмин. Класс преподавателя Н. А. Сегаль, у рояля Фирсова Людмила.

Чайковский. Подснежник
Исп. уч. VI кл. Алапаева Инга. Класс Заслуж. деятеля искусств ТАССР и Засл. учителя РСФСР профессора М. А. Пятницкой.

Бах. Концерт для скрипки и квартета.
Исп. уч. IV кл. Ахметов Марат,
I скрипка—Абсалямов Альфред.
Альт — Абдрашитов Раиф
II скрипка—Гареев Энгельс. Виолончель— Богородов Эрнст. Класс преподавателя Н. В. Брауде.

Раков. Прелюдия из классической сюиты
Губайдуллина Сания. Полька
Исп. уч. VII кл. Губаева Зумара. Класс преподавателя Е. В. Болдыревой.

Сания Гобәйдуллина полька авторы буларак күрсәтелгән программа.

1954 ел алдыннан, Мехчылар мәдәният йортындагы балда Сания үзенең булачак ирен очрата. Ул КДУның геофагын яңа тәмамлаган Марк Ляндо була. София Гобәйдуллинаның бердәнбер кызының әтисе дә ул. Марк Ляндо искиткеч талантлы кызга рухы белән бик тә тәңгәл була.

ГАЛӘМ КЫЛЛАРЫ СИМФОНИЯСЕ

София Гобәйдуллина биографиясенең төп өлеше инде Казаннан соңгы елларга караса да, туган шәһәре күгендәге йолдызлар, галәм сәламен җиткереп, аңа гомере буена юлдаш була.

«Мин – православиене кыйблам итеп сайлаган дини кеше, – ди София Әсгатовна. – Динне бик анык, туры мәгънәсендә кабул итәм – ул безнең Күкләр белән өзелгән җепләрне ялгау».

1971 елда Мәскәүдә ул православие динен кабул итә. Казан консерваториясендәге остазы Марина Юдинаның сүзләре кыз өчен бик зур мәгънәгә әверелә: «Ходайга илтә торган бердәнбер юл – сәнгать аша». Алар кызның дөньяга карашларын формалаштыруга зур йогынты ясый.

Композиторлардан Иоганн Себастьян Бах София өчен «беренче номер»га әверелә. Аны София Гобәйдуллина: «Яшәешемнең башлангычыннан алып – өстәл китабым», – дип атый.

«Һәр дәвер аерым бер аһәңи ситуацияне тудыра, без шул авазлар арасында яшибез һәм, алар белән яңгырашка кереп, җавап бирергә дә тиешбез», – ди София Гобәйдуллина композитор бурычы турында. «Интуитив агымны көчәйтергә кирәк, аны интеллектуаль агым каплап китәргә тиеш түгел», – дип, кат-кат кабатлый. Соңгысының бүгенге чорда өстенлек алып, артык көчәйгәнен ассызыклый.

«Сәнгатьнең мәгънәсе дини мәгънә белән керешеп китә, – дип ышана композитор. – Дин ул – безнең табигый рухи яшәешебез, сәнгать – рухи активлыгыбыз, Безне Тудыручының яратуына җавабыбыз, Аның белән тоташуыбыз». Ул сәнгатьне дә «горизонталь», ягъни матди, күңел ачуга юнәлтелгән төр белән «вертикаль»гә – җитди, дөньяны үзгәртә торган юнәлешләргә бүлеп карый. Әмма «вертикаль» дигәнен бүген күрәләтә торып каядыр читкә этәрергә тырышалар, ди. Тик нәкъ шунысы: интуициягә корылганы, аң төпкелләрен актара торганы гына кешелекне коткарачак, дип ышана. Акыл гына түгел, йөрәк һәм тирән төпкелләр тудырган «вертикаль сәнгать» яклы композитор. Аның фикеренчә, матди булмаган дөньялыкның чикләренә чыгар өчен, безгә нәкъ менә шул «вертикаль» кирәк.

Прагматиклар, материалистлар дөньяны харап итәчәк, дип ачына ул. Алар дини тоемлауның беркатлылыгы турында тәкрарлыйлар, ләкин, юк, барысы да – киресенчә. Нәкъ менә прагматиклар коточкыч беркатлы, һәм алар үз гамәлләренең нәрсә белән тәгәлләнәчәген белми...

«Россиядә хәзерге көндә прагматиклар эш йөртә (2011 елда әйтелә – **авт.**), ә интеллигенция, рухи үсешкә йөз тоткан бер төркем зыялы, коточкыч кысрыкланган шартларда көн итәргә мәҗбүр. Россиядә байлык белән фәкыйрьлек арасында аерма искиткеч. Фәкыйрьләр белән мескеннәр – галимнәр, укытучылар, табиблар... Бу бик җанны яралый торган күренеш. Россия бу аерманы тигезли, дөресли алыр, дип ышанасы килә», – ди София Гобәйдуллина.

Менә шушы урында әтисе аша сеңдерелгән «фәкыйрьлек һәм намуслылык» хакыйкатенә ишарә тоемлана. Ни кызганыч, аның биографлары әтисе белән корган әңгәмәләре турында композитор исән чакта сорашып калмаганнар. Югыйсә София Әсгатовна бу хакта ара-тирә искә алгалый. Ул әңгәмәләрнең темасы музыка белән җир төзелешенә кагылмаганга охшаган. Дөньяви һәм совет кешесе буларак, Әсгать Гобәйдуллин, һичшиксез, әле үзе бала чагында ук атадан улга күчә торган рухи, әхлакый кануннарны сеңдергән булгандыр. Без Гобәйдуллиннарның руханилар нәселеннән булуын да истән чыгармаска тиеш.

Ярты гасыр дәвамында әңгәмә коручылар София Гобәйдуллинаны каршылыклы сораулар белән күмүен дәвам итте. Ул сорауларга шаккатыргыч җаваплар алырга теләп тә ымсындылар. Гыйсъянчы итеп тә күрсәтергә теләделәр аны, авангардист итеп тә, диссидент, советка каршы кеше, постмодернист, либерал-пацифист итеп тә... Әмма юкка! Ул могҗиза булып кала бирүен дәвам итә. Дөньяны бары үзенә генә аңлаешлы һәм гармонияле система аша кабул итүче философ булып. Әлеге авазларда без Казан күге йолдызларының гүләвен, иске рояль кайтавазын, Галәмнең безгә эндәшкәнен ишетә алабыз.

Сания Гобәйдуллина рояль каршында. 1948 ел.

Кремль диварлары янында.

БИЛГЕЛЕ БИЛГЕСЕЗ ЧЫГЪТАЙ

Айдар Шәйхин



Бу шәхесне онытылганнар сафына кертәсе килми. Соңгы ун елда, һәрхәлдә, аның әдәби мирасын барлаучылар, үзен яд итүчеләр артты. Бәхеткә, җыентыклары да нәшер ителә башлады. XX гасыр башының әдәби тормышы, мәгариф һәм фән тарихы турында хезмәтләр язганда аның исеме элек тә телгә алынмыйча калмады. Әмма аның киңкырлы һәм бәяләве катлаулы булган эшчәнлеген бик искә алырга теләмәүчеләр дә юк түгел. Галиәсгар Гафуров-Чыгътай – тарихыбызның үзенчәлекле шәхесләреннән.

ГАЛИНЕҢ БАЛА ЧАГЫ

Язучы, журналист һәм педагог Галиәсгар Гафуров 1867 елның 16 сентябрендә Казан губернасының Чистай өязенә кергән Чәтрән авылында туа. Бу авыл хәзерге Аксубай районына карый һәм Яңа Ибрай дип атала.

Галиәсгарның бабасы Әхмәтҗанны халык «мулла» дип йөрткән, әмма Чыгътайның хатирәләренә таянсаң, ул рәсми дини вазифа биләмәгән. Шул ук истәлекләргә ышансаң, Гафуровлар гаиләсе – Мөгыйнь белән Фатыйма үстергән күп балалы ишле йорт – беркайчан да байлык-тазалык белән аерылып тормаган. Галиәсгар кат-кат «10 ревизия буенча атасына 1 гектар» җир бирелгәнен, ул җирнең дә, тора-бара ярлыланып, бик аз уңыш китерә торган кишәрлеккә әйләнгәнен ассызыклый.

Ә бит аларның нәселе авылга нигез салучылар белән бәйле булган. Заманында авылның бер өлеше, христиан динен кабул итеп, аннары исламга кайткан, бер өлеше исламнан чыкмыйча калган. Галиәсгарләр дин алыштырмаган тармакка караган. Ә бу нәселнең башында Исмәгыйль Чаадаев дигән кеше торган. Рус дворяннары нәселе белән дә бәйле дип саналган бу шәхес. Шуның хөрмәтенә Галиәсгар соңрак үзенең тәхәллүсен Чыгътай, яки Чагатай дип ала.

Галиәсгар әүвәл туган авылы Чәтрәндә, соңрак Көек авылындагы мәдрәсәдә укый. Кечкенәдән укуга хирыслыгы көчле булганга, бу аның өчен ярлылыктан котылу, үсеп, «кеше булу» мөмкинлеге дип күзаллана. Үзе ул бу хакта болай язган: «Чәтрәннән я мәдрәсәгә, я урыс баена хезмәтчелеккә, яисә, күз йомып, эш эзләп кенә китәләр».

1883 елдан сигез ел Чистайның атаклы Закир ишан мәдрәсәсендә белем ала. 1891 елдан шулай ук сигез ел буена үзе дә якынтирә авылларда, мәсәлән, Кизләү мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә. Шушы еллар арасында ул Костромага барып яшәп алырга да, Казанда Владимир Изусимов дигән егеттән рус телен өйрәнергә дә өлгерә. Ахыр чиктә, рус теленнән имтихан тапшырып, дини гыйлемен дә раслап, указлы мулла булырга юл ачыла. Бер-ике ел Түнтәр авылында яши һәм Нәҗип хәзрәт мәдрәсәсендә эшли. Биредә аның белән кызык үзгәрешләр була. Бердән, ул Түнтәрдә легендар Ишми хәзрәт белән яшь Нәҗип мулланың конфликтына шаһит була. Икенчедән, рәхәтләнеп мәдрәсә китапханәсеннән файдалана һәм... «монда Галинең исламнан алган гакыйдәләре бер-бер артлы җимерелеп бетеп, бары Ибн Рөшднең пантеизмы гына вакытлыча торып кала».

Фотолар: ТР Милли музее фондларыннан

«ИСАБӘТ» ҺӘМ ЧЫГЪТАЙ ТӘҮБӘСЕ

Яңгыр ява сибәләп,
Төймә-төймә төймәләп.
Чыгътай мулла үкреп җылый,
«Тәүбә, тәүбә, тәүбә»ләп.

«Авыл җырлары», Г.Тукай

1899 елда Галиәсгар Гафуров Бозаулык шәһәренә (хәзерге Оренбург өлкәсе, Бузулук шәһәре) чакыру ала һәм анда муллалык итә, мәчет янында мәктәп ачып, ир һәм кыз балаларны укытырга керешә. Тиз арада бу мәдрәсәнең даны тарала: «Башкорт илләреннән, Ык буеннан, Ыргыз буеннан Бозаулыкка укырга бала китерәләр».

1910 ел башында Чыгътайның данын бөтен татар дөньясына таратткан вакыйга була. Казанның Иван Харитонов типографиясендә аның «Мөхәммәд галәйһиссәлам тугрысында Исабәт» («исабәт» – дөреслеккә ирешү – **авт.**) исемле китабы басыла. Бу китапта ул Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлын тасвирлаган хәбәрләрнең ни дәрәҗәдә төгәл, дөрес булуы турында фикер йөртә. Кайбер мәсьәләләрне шик астына куюы, пәйгамбәр биографиясен Европадагы Шәрык белеме күзлегеннән чыгып анализлавы аркасында, бик тиз арада матбугатта шау-шу куба. Беренчеләрдән булып алдынгы карашлы Буби мәдрәсәсе мөгаллимнәре хат яза. Гомер булмаган хәл: җәдитләр дә, кадимнәр дә, берләшеп, Чыгътайны тәнкыйтьли башлыйлар.

Әллә җәмгыятьтә купкан гауга шулкадәр көчле булган, әллә Чыгътайның тиресе җитәрлек дәрәҗәдә калын булмаган, ләкин мөфти указлы мулла Гафуровны Уфага җавап бирергә чакырганда, «Йолдыз» газетасында тәүбә мәкаләсе чыгарга өлгерә. Анда Чыгътай хаталарын таный һәм китапның башка кисәкләрен язмаска вәгъдә бирә, тиражның да калган өлешен үзем сатып алып бетереп юк итәчәкмен, ди. Уфада казыйларга һәм мөфтигә дә бу хакта әйтә, нәтиҗәдә, аңа бернинди дә җәза бирелми. Әмма аның бу рәвешле артка чигенүе «Исабәт»не кызыксынып кабул итүчеләрнең җен ачуын чыгара. Моңарчы Чыгътайның әсәрләрен һәм мәкаләләрен хуплап каршы алган Тукайның (ә бит нәкъ менә Тукай Чыгътайның «Тутам» повестен Казанда «Гасыр» нәшриятында бастыруны сөйләшә) сатирик «Мәҗрух указ» шигыре нәкъ шушы вакыйгага багышланган:

Тизүк мәҗрух указымны күтәрдем,
Дәваларга Өфе якка юнәлдем.
Тагын терлер микән мискин указым –
Дәвасына фидадыр күп һәм азым!

«Исабәт» гаугасы чыккач, Чыгътай күпмедер вакытка Санкт-Петербургка китеп ала. Бозаулыкта ул-бу булмасын дип курка ул. Питерда Садри Максудиларда, Гатаулла һәм Сафа Баязитовларда кунакта булырга, алар белән дә «Исабәт» турында сөйләшергә өлгерә. Садри Максуди аңа: «Татар теле белән мондый әче сурәттә «Исабәт»тә булган фикерләрне әйтү мөмкин булуына ышанмый идем», – ди. Чыгътай өчен бу югары бәя була, әлбәттә.

Янәдән үз мәхәлләсенә кайткач, халык аны гаҗәпләнеп каршы ала: «миссионерлар сүзен кабатлаучы» Галиәсгар мулланың төс-кыяфәте үзгәрмәгән, русча киенми, чукынмаган, шул ук кеше икән. Хәлбуки аңа, указын саклап калса да, Бозаулыкта иркенләп эшләргә мөмкин булмый инде. Бер яктан, шәһәр хакимияте аннан канәгать: метрика кенәгәләре, рәсми документ эшләре төгәл бара. Әмма тәнкыйтьчеләр дә, Чыгътай үзе дә, муллалыктан җибәрүне сорап, кат-кат гаризалар язалар.

КАЗАНДА ҺӘМ УФАДА

Гафуровларга Бозаулыктан китеп, берникадәр вакыт авыл хуҗалыгы белән көн күрергә туры килә. Чебенле авылында Галиәсгарның хатынына калган җирне алып, иген чәчәләр, шулай итеп авырайган тормыш шартларын яхшырталар.

Әмма Казаннан чакыру килгәч, Галиәсгар, гаиләсен төяп, татар мәркәзенә күченеп китә. Биредә ул «Кояш» газетасы редакциясендә эшли. Хезмәттәшләре – мөхәррир Зәкәрия Садретдинов, газетаның төп идеологы Фатих Әмирхан, журналист Ибраһим Биккуловлар. Редакция «Амур» кунакханәсендә, Печән базары каршында урнашкан. Димәк, Чыгътай бөтен татар Казанының кап уртасында эшли, көн саен төрледән-төрле йөзләрне күрә. Аны танучылар арасында «Исабәт» тарихын искә төшереп мыскыллап көлүчеләр дә, ихластан сокланучылар да була. Әмма «Кояш»та эш җиңел бармый. Гафуровның инде тиресе калынайган, үз сүзен әйтә белә. Вакыт-вакыт Фатих Әмирхан белән бәхәсләре дә кубып ала, бер-берсен зәһәр итеп тәнкыйтьләгән язмалары газета битләрендә дә чыга.

ЧЫГЪТАЙ ДИГӘН ӘДИП

1901 елда Чыгътай «Үрмәкүч» романын бастырырга ниятли. Әмма цензура бу текстны уздырмый. Аның сакланган кульязмасын уку бәхетенә ирешкән галимнәр күп түгел. Бу әсәр тиешле бәя бирүне һәм басылып чыгуны һаман да көтеп ята.

1902 елда «Тутам» повестеның беренче кисәге Оренбургта басыла. Аны бастырыр өчен Галиәсгар хәйлә кора: цензура комитетына текстны җибәргәндә, авторны күрсәтми. Икенче кисәге 1906 елда «Әл-гасрел-җәдид» журналында басыла. Шунысы кызыклы: бу юлы да ул үз исемен күрсәтми, «Галимә» псевдонимын куллана. 1908 елда исә «Бәянелхак» газетасының типография-

ЧЫГЪТАЙНЫҢ ДИСТӘЛӘГӘН РЕЦЕНЗИЯСЕ, ЖУРНАЛЛАРДА ЧЫККАН МӘКАЛӘЛӘРЕ КАЛГАН. АЛАР ДА ТИЕШЕНЧӘ ӨЙРӘНҮНЕ ТАЛӘП ИТӘ.

сендә ике кисәкне берләштергән китап булып чыга.

«Тутам, яхуд Яшь гомрем» повесте мәгърифәтчелек реализмының кызыклы үрнәге дип санала. Әсәрдә кызларны гыйффәтлеккә өндәү өлеше дә бар (башлыча беренче кисәкнең темасы бу). Шул ук вакытта хатын-кызның ир-ат күзеннән яшеренү-яшеренмәү мәсьәләсе дә өйрәнелә. Текстта диалоглар – ике төрле фикердә булган каһарманнарның әңгәмәләре күп. Кайчагында автор үзе бөтенләй югалып, бары дискуссияләрнең протоколы гына теркәлгән кебек тоела. Моның үз өстенлеге бар: укучы да бу фикер алышуга кушыла ала, үзе хуп күргән якны сайлый, өстәмә дәлилләрне чынбарлыктан үзе таба ала. Әсәрдә татар хатын-кызының тормышында булган җитешсезлекләр дә тасвирлана, Казан татарларының көндәлек хәятендә булган әхлаксызлык, әдәпсезлек күренешләре тәнкыйть ителә.

«Тутам» – чиксез дәрәҗәдә кызыклы әсәр. Аның аша Галиәсгар Чыгътайның ике гасыр алышкан дәвердә булган татар тормышын ничек күрүен дә беләбез. Ягъни субъективлык көчле була ала. Әмма, 1930 нчы елларда язылган мемуарлардан аермалы буларак, повесть шул заманда ук иҗат ителгән һәм бастырылган әсәр. Авторга совет күзлегеннән чыгып борынгы заманны тәнкыйтьләргә кирәк түгел. Ул үз замандашлары турында яза. Җиһанда яктыга омтылудан ваз кичеп, мәхәббәтсез, әмма бай тормышка риза булып калган Шәмсебану – Гафуров күрергә мәҗбүр булган чынбарлык, ә хатынының киң фикерле булып үсүенә ярдәм итәргә тырышкан ир һәм аның тормыш иптәше, «актив тормыш позицияле» Галимә – Чыгътай күрергә теләгән үрнәкләр. Шунысы да мөһим: әсәрдә абстракт лозунглар юк, хатын-кыз ирегe мәсьәләсендә дә урталыкка омтылыш күзәтелә. Автор хатын-кызларның иҗтимагый тормыштан бөтенләй ябылып ятуына да каршы, шул ук вакытта Европа хатын-кызларында кебек «чамадан тыш» ирекне дә тәнкыйтьли. «Тутам» – һичшиксез әдәби дискуссияләр кырына кайтарылырга тиешле әсәр. Аны укып, кабат һәм кабат моназаралар кылырга була һәм кирәк тә.

Гафуров татар балалар әдәбиятына да өлеш кертә. 1908 елда Казанның «Шәрекъ» басмаханәсендә «Мәче белән төлке» экияте чыга. 1914 елда «Мәгариф» нәшриятында «Хан Баскак» хикәяте басыла.

«Аң» журналында 1914 елда «Ул» дип исемләнгән дини-психологик хикәясе чыга. 1926 елда «Ачлык корбаннары» исемле драмасы языла. Аның каләме белән язылган шигырьләр, басылмый калган бүтән хикәяләр дә шактый. Мәсәлән, «Суфи тәкъва», «Сабир Ахун», «Яшь абыстай» хикәяләре, «Ике өлештән торган хыялый бер комедия»се Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

1916 елда Чыгътай Уфага, андагы «Тормыш» газетасына эшкә күчә. Инкыйлабны ул бу шәһәрдә каршылый. Мөселман съездларын да, гарасат дәверендә булган мең дә бер төрле дәһшәтле хәлләрне дә күрергә өлгерә. Уфадан китеп, тирә-яктагы төрле авылларда да яшәп ала.

1921 елгы ачлык вакытында исән калуының тарихы бигрәк гыйбрәтле. Бу вакытта ул Сакмар буендагы Бәктәр авылында яши. Авыл халкы, аның гыйлемле икәнен белгәнгә, мулла булып торырга тәкъдим итә. Бушка түгел, билгеле: иген чәчәр өчен авыл җиреннән кишәрлек бирелә, аз-маз ярдәм күрсәтелә. Мемуарларында язылганча, ул, бу вакытта инде чын атеист булуына карамастан, ачлык елы афәтен җиңелрәк уздыру хакына мулла булырга ризалаша: «Мин шушы мулла исеме белән егерме беренче ел куркынычларын корбансыз яисә аз корбан белән генә үткәреп җибәрә алсам, ул исемне күтәрүне бик авырга санамам».

Корбаннар «аз» була. Галиәсгар гаиләсеннән ике бала үлә, үзе бик каты авырып, үлгәннән кала.

«СУГЫШЧАН АЛЛАСЫЗ»

1922 елда Галиәсгар дингә каршы көрәш юлына баса. Ул Уфада узган динсезләр белән диспутлар, бәхәсләрдә җиңелгән дәһриләр турында матбугаттан укып белә. Диниләрнең җиңүенә эче поша. Еллар буена диннәр тарихы, ислам тарихы буенча туплаган белеменең кулланылмавына борчыла.

1924 елның көзендә Гафуров-Чыгътай Мәскәүгә күченә. Ул СССР халыкларының Үзәк нәшриятында эшли башлый. Бер елдан Алласызлар союзының үзәк советы Мәскәүдә татар телендә «Фән һәм дин» исемле айлык журнал чыгара башлый (1932 елдан исеме «Сугышчан алласыз» дип үзгәртелә). Ул 12 ел дәвамында басылып килә, барлыгы 172 саны чыга. Журналның беренче баш мөхәррире – Галиәсгар Гафуров-Чыгътай.

«Фән һәм дин» – дингә каршы көрәшне җәелдерү һәм атеизмны пропагандалау максатыннан чыгарылган фәнни-популяр журнал. Аның битләрендә төрле фәннәр турында мәкаләләр дә, муллалар турында сатира да, дин тарихы, дини идеяләрнең, «мифларның» килеп чыгышын аңлаткан язмалар да дөнья күргән. Чыгътай бу журналда эшләр өчен кирәкле белемгә һәм тәҗрибә ия кеше булган.

Мәскәүдә ул 17 ел яши. Берничә тапкыр Татарстанга, Чәтрән авылына кайтып килә. Туган авылында аның якыннары калмый диярлек. Соңгы тапкыр 1941 елның язында авылына кайта. Сугыш башлангач, Мәскәүгә китү мөмкинлеге калмый.

ИКЕ ИБРАЙ АРАСЫНДА

Галиәсгар картны 1930 нчы еллар ахырында һәм 1941–1942 елларда күреп калган туганнарының истәлекләренә күз салыйк. «Намазларны калдырмыйча укый иде. Үзе белән алып кайткан дини китапларны да озаклап укып утырганы хәтеремдә», – дип сөйләгән Миңлебәян ханым. Рауза апа сөйләгән хатирәләрдә «Саулыгы какшаган бабай, бераз рәтләнгәннән соң, Коръән укый башлады. Хәтеремдә ул Коръәнне бер тапкыр тулысынча укып чыккач, бер як каберлекләргә барып багышлап кайтты, икенче тапкыр укыгачтын, икенче як каберлекләргә барып багышлады».

Бу истәлекләрдә Чыгътайның 1938 елда хаҗ кылуы да әйтелә. Монысы бик шикле тоела: Җиддә шәһәрендә совет консуллыгы ябылганнан соң, Гарәбстан белән рәсми элемтәләр өзелә, легаль рәвештә хаҗ кылу мөмкинлеге бетә. Хәер, Чыгътай кебек кешегә чит илгә чыгарга рөхсәт тә бирелмәс иде. Әмма янәдән Чыгътай бабайның көндәлегенә мөрәҗәгать итик:

«Һәр нәрсәнең үз исеме белән,
чын кыяфәте белән язарга ярамау
тия теңкәгә. Адәм улы үз заманының ирексез колы. Аны ирексез кылалар. 5.11.1941».

Озын гомер яшәгән Галиәсгар картның шундый уйлары да булган. Бәлки, чынлап та соңгы көннәрендә иманга кайткандыр, еллар буе алып барган публицистик эшчәнлегенә карашын үзгәрткәндер.

Хәер, үз фикерендә калса да, Чыгътайның кадере кимеми. Ул, һичшиксез, XX гасыр башы татар тормышында ифрат дәрәҗәдә үзенчәлекле урын биләгән, һәрбер даирәдә каршылыклы мөнәсәбәт уятырга сәләтле булган фикер иясе. Аның дини карашларын кабул итмәү исә әдәби һәм фәнни мирасын инкарь итүгә сәбәп була алмый.

Галиәсгар Мөгыйнь улы 1942 елның 20 августында Иске Ибрай авылында вафат була һәм шунда җирләнә. Чыгътай исемен XXI гасырда яңартуда, аның әдәби-публицистик мирасын кайтаруда укытучы һәм тарихчы, Яңа Ибрайда Туган як музеен җитәкләгән Шәүкәт Кәбировның роле гаять зур. 2013 һәм 2017 елларда Чыгътай әсәрләреннән торган җыентыклар басылды. Туган ягында искә алу чаралары үткәрелде. Ахыр чиктә, Галиәсгар Гафуров-Чыгътай турында аерым бүлек татар





әдәбияты тарихының яңа басмаларында да лаеклы урын алды.

Әмма Чыгътай үз сәгатен көтә әле. Аны акларга да, каралтырга да кирәкми, ул моңа мохтаҗ түгел. Юк, аны укырга һәм фикерләшергә, узган гасыр башындагыча кайнар бәхәсләр куптарырга, юшкын утырган күңелләребезне йомшартырга гына кирәк...

XX ЙӨЗ БАШЫ: КИТАП ҺӘМ МАТБУГАТ

2026 ел замандашларыбызның түгәрәк даталарына да, бөек классикларыбызның юбилейларына да, мәдәни вакыйгаларга да гаять бай. Шуларның кайберләренә тукталып узмыйча һич ярамый. Бу саннан башлап, журнал укучыларына «Мәдәни календарь» сәхифәсе тәкъдим итәбез. Гыйнвар ае календаренда түбәндәге кадерле даталар бар.

«КӨТЕПХАНӘИ ИСЛАМИЯ» АЧЫЛУГА 120 ЕЛ

Күренекле шәхес Әхмәтһади Максуди XX гасыр башында Казанда татар телендә китаплар тупланган китапханә ачу мәсьәләсен Казан шәһәре думасы алдына куя. Оештыру эше кузгала: 590 сум акча бүленә, «Болгар» кунакханәсенең өченче катыннан ике бүлмә бирелә.

Фондка Максуди үзе – 100 китап, ә күренекле нәширләр – бертуган Кәримовлар 488 китап бүләк итәләр. «Сабах», «Мәгариф» матбагаларының, кайбер шәхси затларның бүләк итеп тапшырган китаплары да була. Китап йорты 1906 елның 2 гыйнварында эшли башлый. Аңа «Көтепханәи исламия» дип исем бирәләр. Берничә елдан ул Кәримовлар йортының беренче катына күченә. 10 ел эчендә фондта татарча, төрекчә, гарәпчә һәм фарсыча язылган 3 500дән артык китап җыела.

Китапханәгә «Мөхәммәдия», Күл буе, «Халидия» мәдрәсәләренең шәкертләре, гимназия укучылары йөри. 1913 елдан башлап атнага бер тапкыр (якшәмбе көнне, көндез 12:00 – 16:00 сәгатьләрдә) хатын-кызларга да уку залына керергә рөхсәт ителә.

1915 елда китапханәнең 22 737 кешегә хезмәт күрсәткәне билгеле. Китапларны өйгә алып булмаган, уку залына 150 кеше сыйган.

1919 елда Үзәк мөселман китапханә-музее дип үзгәртелә. 1922 елдан – «Мулланур Вахитов исемендәге Шәрекъ көтепханәсе». Китапханәче Мирхәйдәр Фәйзи тырышлыгы белән Тукай исемендәге балалар бүлеге ачыла. 1929 елда, Казанда китапханә системасы оештырылган чакта, фондлардагы хәзинәнең зур өлешен Казан университетының фәнни китапханәсенә тапшыралар. Бер өлеше Китап пулатына күчерелә.

Калган фонд үзәк шәһәр китапханәсенә бирелә. ТР Милли китапханәсенең татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге Һади Максуди нигезләгән китапханәнең дәвамчысы дип исәпләнә.

Фото: pxhere.com

«ЙОЛДЫЗ» ГАЗЕТАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ САНЫ ЧЫГУГА 120 ЕЛ

Нәшире һәм мөхәррире – Әхмәтһади Максуди. «Йолдыз» Казанда 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр нәшер ителә. Шәһәр өчен ул дөнья күргән икенче газета була, ә татар мәдәнияте өчен – иң озак вакыт чыгып килгән басмаларның берсе. Үз тарихы дәвамында 1900 сан чыгара.

Газета битләрендә Садри Максуди, Зәки Вәлиди, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов һәм башка бик күп авторларның исемнәрен очратырга мөмкин. Эчтәлеге бай һәм төрле була: анда эчке һәм тышкы сәясәт яңалыклары, фәнни-популяр мәкаләләр, китап анонслары, күзәтүләр, театр репертуарлары басыла.

Ләкин «Йолдыз» аеруча татар теле һәм орфографиясе проблемаларына багышланган фикер алышулар нәтиҗәсендә зур популярлык казана. Бу очраклы түгел: газетаның нәшире Әхмәтһади Максуди татар әлифбасын реформалаучы һәм мәшһүр «Беренче укытучы» әлифбасын төзүче шәхес санала.

«ӘЛ-ГАСРЕЛ-ҖӘДИД» («ЯҢА ГАСЫР») ЖУРНАЛЫНЫҢ ЧЫГА БАШЛАВЫНА 120 ЕЛ



Нәшире – Камил Мотыйгый. 1905 елдан әлеге басма баштарак Җаек (Уральск) шәһәрендә татар телендә кулъязма рәвешендә тарала башлый. 1906 елның 15 гыйнварыннан 1907 елның 20 маена кадәр шул ук шәһәрдә басма рәвештә нәшер ителә. Барлыгы 17 саны чыга.

Журналда Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса Бигиев, Гаяз Исхакый һәм башка әдипләр языша, әдәби-нәфис әсәрләргә күп урын бирелә. Аның битләрендә Габдулла Тукайның беренче шигырьләре дөнья күрә, иҗат юлы шушы басмадан башлана.

Журналның матур әдәбият бүлегендә лирик, драма, проза (күбесенчә хикәяләр) әсәрләре басыла. Редакция иң яхшы сәхнә әсәрләренә конкурслар уздыра, авторларга махсус бүләкләр билгели. Шуңа да басманы киң катлам татар укучысы кызыксынып күзәтеп бара, биредә басылган әсәрләрне укып фикер алыша, бәхәсләшә.

Журнал Александр Пушкин, Николай Гоголь, Лев Толстой кебек рус классиклары әсәрләренең тәрҗемәләренә, иҗтимагый-сәяси һәм икътисади характердагы материалларга да урынны мулдан бирә.

1907 елның февралендә Камил Мотыйгый нәширлек һәм мөхәррирлек хокукыннан мәхрүм ителә, журнал чыгымын финанслау аның урынбасары Мортаза Гобәйдуллинга күчә, һәм тиздән ул басманы яба.

«ВАКЫТ» ГАЗЕТАСЫ ЧЫГА БАШЛАУГА 120 ЕЛ

Ул алтын приискалары хуҗалары бертуган Закир (Дәрдемәнд) һәм Шакир Рәмиевләр тарафыннан Оренбургта оештырыла һәм алар хисабына басыла. Газетаның баш мөхәррире – Фатих Кәрими.

Газетаның актив авторлары – Һади Атласи, Зариф Бәшири, Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Җамал Вәлиди, Шәриф Камал, Мәхмүт Галәү, Газиз Гобәйдуллин, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Сүнчәләй, Ризаэтдин Фәхретдин, Зыя Ярмәки һ.б.

Газетаның һәр санында чит илләрдәге һәм Россия күләмендәге яңалыклар, җирле хәбәрләр басылып бара. Гаять зур урын сәяси, иҗтимагый вакыйгаларга бирелә: аеруча Дәүләт думасында мөселман фракциясе депутатлары эшчәнлеге актив яктыртыла. Сәүдә, җир эшкәртү, һөнәрчелек, икътисад, сәнгать, тел, уку-укыту мәсьәләләре, дин, хатын-кызларның җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге роле – боларның барысы турында да «Вакыт»та еллар дәвамында языла. Европа һәм Көнчыгыш илләрендәге алдынгы казанышларны карап-күзәтеп тә, барып үзләштереп тә кайткан бертуган Рәмиевләр милли кадрларны әзерләү, аларны үстерү мәсьәләсен күтәрә.

«Вакыт» газетасының 1906–1907 елларда «Әдәбият капчыгы» шигъри кушымтасы чыгып килә. 1908–1918 елларда редакция тагын бер мәртәбәле, атаклы басманы – «Шура» журналын нәшер итә.

«КИТАП УЛ – САКРАЛЬ ӘЙБЕР...»

Луиза Янсуар



Яңа ел алдыннан Татарстан китап нәшриятында язучы, «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре Ландыш Әбүдарованың «Умарта» китабы дөнья күрде. «Умарта»да авторның соңгы еллар дәвамында вакытлы матбугат битләрендә басылып, үз укучысын тапкан, инде яратып кабул ителеп өлгергән хикәяләре белән повестьлары урын алды. Үтә тормышчан, шул ук вакытта яшәеш сүрүенең күзгә күренми торган нечкә җепләрдән үрелгән булуын исбатлап торган бу иҗат гади булмаган сораулар куя белгән укучыга юнәлтелгән. Китабы басылып чыгуны форсат итеп, Ландышның үзенең яраткан китаплары, авторлары белән кызыксындык.

– Балачак китапларыгыз нинди?

– Без кечкенә чакта китаплар авыл кибетенә кайта иде. Өебездә Ганс Христиан Андерсенның «Әкиятләр», «Корольнең яңа күлмәге» китаплары, Джанни Родари әкиятләре, «Чегән әкиятләре» бар иде. Әни дә, кая барса, шуннан китап сатып ала. Берсендә Владимир Сутеевның «Цыплёнок и утёнок» әсәрен алып кайтты. Һәр бите катыргыдан, рәсемле итеп эшләнгән зур китап иде ул. Русча аңламасам да, шул китапны кочаклап йөргәнем хәтердә. Фатих Кәримнең «Гармунчы аю белән җырчы маймыл» поэмасы йомшак тышлы юка гына аерым китап булып басылган иде. Үзем укый белмәгәч, әни белән ападан укытып, йөдәтеп бетергәнмен. Укыта торгач, яттан сөйли башлаганмын.

– Иң беренче хәтерләгән китабыгыз?

– «Татар халык әкиятләре». Ул рәсемле түгел, вак кына хәрефле калын китап. Апа аны миңа һәр кичне кычкырып укый иде. Шул әкиятләрне укыганда туган образлар, картиналар әле дә күз алдында. Үсә-үсә әкиятләрдәге һәр образның мифик асылына төшенә барам, бары тик оныттыргыч таяк деталенең генезисын гына аңлап җиткерә алганым юк.

– Сезне нинди китап формалаштырды?

– Укыган һәр китаптан үзем өчен нәрсәдер алам. Аерым бер китапны гына атый алмыйм. Хәзерге заманның «баш герой синдромы»н йоктырган буыны «Син – нәрсә ашасаң, шул» дип шәрран яра бит әле, аларга минем җавап шундый: «Ә без – нәрсә укысак, шул».

– Иң тетрәндергән китап?

– Бала чакта Гавриил Троепольскийның «Акбай-Караколак» повесте бик нык тетрәндергән иде. Беренчедән, ул әкият түгел. Икенчедән, анда мин укыган башка

Фото: Ландыш Әбүдарова архивыннан



әсәрләрдәге кебек узган заман тасвирланмаган. Өченчедән, Акбай-Караколак кебек этләр һәр өйдә бар, һәм без, бала-чага, су ташысак та, утын өйсәк тә, хәтта тау шуарга да эт ияртеп йөрибез. Ягъни ул вакыт һәм пространство ягыннан чынбарлыкка нык туры килгән әсәр. Бу да бик мөһим икән.

– Китап уку өчен сезгә аерым бер халәт, көйләнеш кирәкме? Бәлки, урын?

– Элегрәк кирәкми иде. Киресенчә, китапка тотынуга, ул көйләнеш үзеннән-үзе барлыкка килә. Хәзер менә лампалар да көйләнгән, урыны да җылы, вакыт та бар, әмма китапка чынлап торып кереп китү өчен еш кына нидер комачаулый. Нидер дигәнем – гаджетлар, девайсларның баш миенә ясаган тискәре йогынтысы.

– Милли классика һәм заман әдәбиятыннан кемнәрне югары бәялисез?

– Милли классиканы белергә кирәк. Чөнки әдәбият – ул татар менталитетының, аның фикерләү рәвешенең, уеның, моңының көзгедәгедәй чагылышы, бу дөньяда яшәвенең алгоритмы. Прозада Гаяз Исхакый белән Фатих Әмирханның фикер сөрешен янәшә куеп, Шәриф Камал белән Гадел Кутуйны эволюциядә укысаң, 60–80 нче еллар әдәбиятындагы тамырларны барлау ызанын күзәтсәң, милли миф иҗатын барласаң, киләчәктә әдәбиятның нинди эздән барачагын фаразларга була. Шигъриятне шундый ук ноктадан өйрәнү дә татар җанын аңларга ярдәм итә. Заман авторларын, каләмдәшләремне даими күзәтеп барам, «Казан утлары»на кульъязмалар килеп кергәндә, нindидер яңалык булса, сөенәм. Быел шундый әсәр Луиза Янсуарның «Минем чәчем җиде толым» романы булды. Ул авторның прозадагы тәүге күләмле әсәре. Татар прозасында бай эчтәлекле, зәвыклы, укучыны бер башка үстерә торган әсәрләр булсын, дип телим.

– Дөнья әдәбиятын күзәтеп барасызмы?

– Тырышам. Соңгы вакытта «япон чыгышлы Америка язучысы», «һинд чыгышлы Европа язучысы», «төрек чыгышлы алман язучысы» дип сөйлиләр. Безнең заманның көч чыганагы да шунда, дип уйлыйм. Кытай язучысы Мо Яньның Нобель премиясе алган, «галлюциноген реализм» дигән өрянә жанрга нигез салган «Большая грудь, широкий зад» романы көчле тәэсир итте, Уильям Полн Янгның «Хижина» романы да. Америка язучысы Джон Ирвинг әсәрләрен яратам, аңардагы эпик башлангычны, французлардан - Мишель Уэльбекны, аның стиле үзенчәлекле, инглизләрдән - Терри Пратчеттны, ул тудырган дөньялар гаять мавыктыргыч. Төрле жанрларда иҗат итә белүе ягыннан Элизабет Гилберт ошый.

– Әдәбиятның милли йөзебезне, менталитетыбызны саклаучы булуы белән килешәсезме? Ул үзенә чынлап та мондый вазыйфаны алырга тиешме?

– Ничектер шулай килеп чыккан инде: безнең әдәбият гуманитар фәннәрнең вазыйфаларын да үзенә алган. Ул фәлсәфә ролен дә, социология, психология ролен дә үтәп бара. Әдәбият ничек кенә миллилектән качарга тырышмасын, барыбер милли яшәеш фәлсәфәсен үзендә йөртә. Тел – аның төп мәдәни коды.

– Сез бөтенләй кабул итә алмаган авторлар, китаплар бармы?

– Кабул итә алмаган авторлар, китаплар бар. Ләкин алар мин кабул итмәгәнгә карап, язмаска тиеш дигән сүз түгел. Мин аларны укымыйм гына.

– Кәгазь китапмы / электрон форматмы?

– Кәгазь китапка өстенлек бирәм. Соңгы вакытта аудиокитапларны да яратып тыңлыйм.

– Хәзерге вакытта (бәлки, һәрвакыт) өстәл китабыгыз?

– Хәзерге вакыттагы өстәл китабым – Фатих Әмирхан томлыклары.

– «Китап ул – минем өчен...» – бу фразаны ничек тәмамлар идегез?

– Китап – минем өчен сакраль әйбер. Ул ярату да, җаваплылык та, кайгырту да, хезмәт тә, ял да...



«Татарстан» журналы, дистә еллар эчендә республикабызның һәр районында булып, күп авыллар турында язды. Яңа елда да шушы күркәм традицияне дәвам итәбез. Быел без төрле милләт вәкилләре яшәгән авылларга барырга ният кылдык. Россия Президенты Владимир Путин Указы нигезендә 2026 ел «Россия халыклары бердәмлеге елы» дип тә игълан ителде. Һәм без моңа сөендек. Татарстан – күпмилләтле, шул ук вакытта толерантлы төбәк буларак билгеле. Һәм бу яктан без күпләргә үрнәк.

ЧЕПЬЯ – ДУСЛЫК НӘРСӘДӘН БАШЛАНА

Фото: Лилиана Вәлитова

ЧЕПЬЯ

Үзенчәлекле авылларга сәфәребезне Балтач районының Чепья авылыннан башлыйбыз. Биредә биш милләт вәкиле яши һәм алар бер-берсенең телендә иркен аралаша, милли бәйрәм, йолалар да уртак. Дуслык кайдан, нәрсәдән башлана? Чепьяга баргач, бу сорауга җавапны зур кызыксыну белән эзләдек.

Руфия Фазылова

УНҖИДЕ АВЫЛДАН КИЛЕП УКЫЙЛАР

Балтач районында Чепья авылын белмәгән кеше юк. 1938-1958 елларда ул район үзәге булып та торган. Бүген дә ул тирә-күрше авыллар өчен үзәк: Чепья урта мәктәбенә унҗиде авылдан килеп укыйлар. Алты мең кешегә хезмәт күрсәтә торган амбулатория үзәге дә нәкъ менә шушы авылда урнашкан. Хәер, Чепья башка ягы белән дә шаккатыра: монда удмурт, мари, татар, рус, керәшен татарлары, дус-тату булып, гасырлар буе бергә гомер итә. Әле берничә ел элек чегән, украин милләтеннән булган гаиләләр дә яшәгән. Ә иң гаҗәбе – халык бер-берсенең телендә иркен сөйләшә ала, бәйрәм, йолалар да уртак.

Авыл белән танышуыбызны белем йортыннан башладык. 1844 елда эшли башлаган Чепья урта мәктәбе гомер-гомергә Балтач районындагы иң зур мәктәпләрнең берсе саналган. Биредә меңәр бала укыган вакытлар да булган. Бүген исә Чепья урта мәктәбендә 344 бала белем ала. Аерым авыллардан укучылар 10, 11 нче сыйныфларга гына килә. Мәктәптә биш-алты милләт баласы белем ала. Беренче урында – татарлар, барлык укучыларның 52 проценты, икенче урында – удмуртлар, 40 процент тирәсе, 8 процентын мари, керәшен, рус балалары бүлешә.

Мәктәпкә кергәч тә, стенадагы язуга күз төште: дүрт телдә сәламләү сүзләре язылган (татарча, русча, марича, удмуртча). Ә уку рус телендә алып барыла икән.

– Аралашу да русчамы? – дим Чепья урта мәктәбенең директоры Раниф Әхәтовка.

Укучылар мәктәп фойесында безнең өчен чын концерт күрсәтте.

Ашханәдәге язулар да дүрт телдә.

– Юк, алай димәс идем. Мисал өчен татар балалары үзара татарча аралаша. Ә менә мари, удмурт балалары күбрәк рус телендә сөйләшә. Элек барлык укучылар да татар телен укый иде, хәзер инде дәүләт теле буларак рус теле генә керә. Һәм һәр милләт баласы үз телен өйрәнә. Хәер, кайбер удмурт гаиләләре ана теле урынына татар телен сайлады. «Удмуртча өйдә дә сөйләшәбез, татарлар арасында яшәгәч, татарча белсеннәр», – диделәр.

Укучылар мәктәп фойесында безнең өчен чын концерт күрсәтте. Монда «Беренче театр»ны сәхнәләштергәннәр дә, биилар дә, җырлыйлар да. Удмурт, мари балалары, үзләренекеннән кала, татар, рус күлмәкләрен дә бер дигән итеп уйный. Билләһи, бу балаларның чыгышларын тын да алмый күзәттек. Алар бит әллә нинди музыка, сәнгать мәктәпләрендә укучы балалар түгел, ә укытучы апалары өйрәткән, үзлекләреннән өйрәнгән малай-кызлар! Тагын монда спортка да зур игътибар бирәләр.

Чепья мәктәбендә укучыларның төс-кыяфәтләре дә үзгә тоелды: җирән чәчлеләр, кап-кара күзлеләр, сары чәчле, яшел күзле малай-кызлар дисеңме. Директор мондый үзенчәлекне болай дип аңлатты:

– Чепьяда катнаш гаиләләр бик күп. Катнаш никахтан туган малай-кызлар аеруча сөйкемле була, ахры. Мин аны гел әйтәм: безнең мәктәп балалары иң матурлары!

Мәктәпнең биш автобусы, көн саен икешәр рейс ясап, балаларны авылларга барып ала, дәресләр беткәч, кайтарып куя икән.

УДМУРТЛАР: ЧЕЛТӘРЛЕ БИЗӘКЛЕ ТӘРӘЗӘЛӘР

Чепья мәктәбенә Леонид Сапожников та килгән иде. Күрше Сырья авылының мәдәният йорты җитәкчесе ул. Җирле удмуртлар аны бик якын итә – милли җанлы кеше. Милләте буенча – чын удмурт, ләкин татарчасы күп кенә татарларга караганда яхшырак.

– Әти-әни Чепьяга күченеп килгәндә, миңа алты ай була, – диде Леонид Дмитриевич. – Күршедә татарлар яшәде, без алар белән туганнар кебек гомер иттек. Шуның өчен ана телем удмурт теле булса, икенчесе татар теле булды. Рус теленә караганда татарча яхшырак сөйләштек. Соңрак без күрше Сырья авылына күчендек. Ләкин мәктәпкә Чепьяга йөреп укыдык. Шулай булгач, Чепья минем өчен туган авылым кебек якын. Бик күп дусларым биредә яши.

Леонид Сапожников егерме ике ел Сырья башлангыч мәктәбендә удмурт балаларына татар теле укыткан. Югыйсә белгечлеге буенча физика укытучысы, Ижевск дәүләт уни-

Леонид Сапожников егерме ике ел Сырья башлангыч мәктәбендә удмурт балаларына татар теле укыткан.

верситетын тәмамлаган. Тик башына төшкәч, башмакчы булган.

– 1994 елда Сырья башлангыч мәктәбен ачтык, – дип дәвам итте Леонид Дмитриевич. – Нәкъ шул елларда татар теле дәүләт теле буларак башка милләт балаларына да укытыла башлады. Татар телен яхшы белүче кеше буларак, бу эшне миңа йөкләделәр. Әлбәттә, курсларда да укып кайттым. Ихластан әйтәм – бу эшне бик яратып башкардым. Удмурт теле белән татар теле бер-берсенә охшамаган булса да, җөмлә төзү тәртипләре бертөрле, род төшенчәсе дә юк. Тик менә 2017 елда удмурт балаларына татар теле укытылмый башлады. Үзегез беләсез, яңа закон гамәлгә керде бит...

Леонид Сапожников бер зур шатлыгы белән уртаклашты – удмурт халкының җырларын, уеннарын туплап, бик матур китап бастырган. Баксаң, күптәнге хыялы булган. Дистә елдан артык удмуртларның халык иҗатын бөртекләп җыйган. Иганәчеләр артыннан йөри-йөри, халык тырышлыгы белән дә әнә шундый затлы китап барлыкка килгән.

Леонид Сапожников безне Чепья авылының иң атаклы гаиләсе – Черновларга алып керде. Ирле-хатынлы Пётр Григорьевич белән Мария Федоровна күрше Сырья авылында туып-үскән кешеләр. Чепьяда исә 1981 елдан бирле яшиләр. Өч балалары монда үскән, белем алган.

Пётр Григорьевич Чепьяның элеккеге колхоз рәисе, бирелә аны белмәгән кеше юк. Үзе дә авыл өчен күп хезмәт куйган кеше.

Ирле-хатынлы Пётр Григорьевич белән Мария Федоровна – күрше Сырья авылында туып-үскән кешеләр. Чепьяда исә 1981 елдан бирле яшиләр.

– Чепья туган авылым булмаса да, бик якын миңа, – диде. – Хәер, үсмер чак монда узды бит: бишенче сыйныфка Чепья мәктәбенә килеп укыдык. Өч чакрым юлны җәяү йөрдек. Армиядә чакта үземә максат куйдым – ничек тә югары белем алырга. Шуңа да буш вакыт булганда гел китапханәдә утырдым. Нәтиҗәдә, армиядән соң Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтының инженерлык факультетына укырга кердем һәм аны уңышлы гына тәмамладым.

1970 нче еллар... Авыл гөр килеп тора. «Сельхозтехника» берләшмәсе, «Труд» колхозы, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты – бирегә күрше авыллардан да килеп эшлиләр. Яшь белгеч Пётр Григорьевичны башта Чепья авылына партоешма секретаре итеп билгеләделәр. Аннан соң баш инженер, колхоз рәисе итеп куялар. Соңгы вазыйфада ул нәкъ егерме ел эшли.

– Чепья колхозы җиде авылны берләштерде, – дип дәвам итте әңгәмәдәшем. – Удмурт, татар, мари, керәшен авыллары – барысы белән дә уртак тел табып эшләргә тырыштык. Һәр милләтнең үз холкы, үз традицияләре, кайчагында әйтәсе килгән сүзне дә әйтми каласың...

Сөйләшеп утырган арада Черновларның тәрәзә яңакларына күзем төште – эчтән дә бизәкле ул.

– Удмуртлар тәрәзә яңакларын әллә шулай эчтән дә челтәрләп эшлиме? – дим.

– Юк, үзем уйлап таптым аны, лаеклы ялга чыккач үз кулларым белән ясадым. Башта тышкы якны, аннан эчен дә шулай челтәрләп куйдым.

– Бизәкләре татарларныкына охшаган икән? – дим.

– Ә ул татар бизәге дә инде (көлә – **авт.**). Дөресен әйтим, элек культура ягыннан татарлар безгә караганда өстенрәк иде. Без алардан бик күп нәрсәгә өйрәндек, шул исәптән тәрәзә яңакларын бизәкләп эшләргә дә. Ә нәрсә, бик матур бит! Юри генә карап чык: Чепьяда кайсы удмурт, кайсы татар йорты икәнен аермыйсың. Элек аерыла иде, хәзер без дә күршеләрдән калышмый яшибез, гомер буе үрнәк алабыз. Һәм мин моны бик матур күрсәткеч дип күрәм.

– Чынлап та, – дип сүзгә кушылды Мария Федоровна. – Мәсәлән, мин бик яратып өчпочмак, бәлеш пешерәм. Җәмәгатем күп еллар җитәкче булып эшләгәнлектән, татарларның нәрсә яратканын, нәрсә яратмаганын да беләм. Хәтта без хәзер дуңгыз ите дә ашамыйбыз.

МАРИЛАР ДҮРТ ТЕЛ БЕЛӘ!

Мари гаиләсе белән дә таныштык. Беренчедән, шуны әйтим: Чепьяда чын мари гаиләләре бармак белән генә санарлык, күбесе катнаш гаиләләр – удмурт – мари,

Фёдоровлар – үрнәк мари гаиләсе. Виктор белән Лада өч ул үстерә. Күрше урамда гына яшәүче әниләре Нина Сергеевна да – клуб сәхнәсе йолдызы.

Кунакка Валентин Максутовны да чакырганнар – җирле марилар аны үзләренең остазлары буларак кабул итә икән.

татар – мари. Аңлашыла ки, андый гаиләдә чын милли традицияләр бик сакланмый. Ә менә Фёдоровлар – үрнәк мари гаиләсе. Виктор белән Лада өч ул үстерә. Әле Чепья мәктәбендә үк бу малайларның берсе – Ярославның гармунда уйнап җырлаганын сокланып тыңлаган идек. Баксаң, Фёдоровларда җырламаган, гармунда уйнамаган ир-ат юк икән. Күрше урамда гына яшәүче әниләре Нина Сергеевна да – клуб сәхнәсе йолдызы. Безнең алда да бер дә тарсынып тормадылар: марича җырладылар да, биеделәр дә. Малайлар исә рәхәтләндереп гармунда уйнады. Вәт күңелле яшәү бу!

– Олы улыбыз Кирилл югары белем алып безнең янга авылга кайтты, колхозда эшли, – диде эти кеше. – Ярослав белән Юлиан Чепья мәктәбендә белем ала. Малайлар барысы да гармунда уйный. Кирилл үзлегеннән өйрәнде. Ә кечкенәләре безгә карап инде. Бездә көн саен гармун тавышы.

– Оныгым Казан дәүләт консерваториясен тәмамлады, магистратурада укый, – дип сүзгә кушылды Нина түти. – Балалар үземә охшады, мәрхүм ирем алай сәнгатькә якын кеше түгел иде.

Фёдоровлар мари ризыкларыннан мул табын әзерләгән иде. Һәр ризыкның исемен атап, зурлап сөйләде алар. Кунакка Валентин Максутовны да чакырганнар – җирле марилар аны үзләренең остазлары буларак кабул итә икән.

– Удмуртлардан аермалы буларак, Балтач районында марилар бик күп түгел, 300 кешедән дә артмастыр, – дип сүз башлады Валентин Максутов. – Хәтта район газетасы удмуртча басыла, ә без «Хезмәт» газетасының татарчасын укыйбыз. Тик аз булсак та, башкалардан калышмаска тырышабыз: бик актив яшибез. Район күләмендә узган барлык чараларга чакыралар. Тәрбиягә килгәндә исә, балалар белән үз телебездә сөйләшәбез, барлык милли бәйрәмнәрне билгеләп узабыз.



– Татарча камил сөйләшәсез. Әгәр алдан белмәсәм, гомердә дә сезне мари милләтеннән дип уйламас идем, – дим.

– Әйе, өйгә татар газеталары яздырам. Мин иркен дүрт телдә сөйләшәм: мари, татар, рус, удмурт. Удмуртлар арасында яшәгәч, алар телен дә өйрәнергә туры килде. Ә менә удмуртлар марича белми.

– Марилар башка халыклардан кайсы ягы белән аерыла?

– Хезмәт сөючән халык, әллә нинди югарылыкка омтылмыйбыз, җир кешеләре без. Аннары, миллилек тә көчле. Чепья мәктәбендә бөтен балалар да ана теле буларак мари телен сайлады. Чагыштыру өчен: удмуртларның барысы да үз телен укымый, татар, рус телен сайлыйлар. Мин татарлардан үрнәк алырга кирәк дип гел әйтәм – әнә ничек туган телегезне саклыйсыз.

– Хәзер татар гаиләләрендә дә ана телендә бик сөйләшмиләр шул, бигрәк тә шәһәр җирендә, – дип каршы төшәм.

– Юк, алай димәгез. Татар теле, башкалар белән чагыштырганда, бик күпкә алда, милләт саны буенча да Россиядә икенче урында торасыз. Ә без бер миллион да юк, иң зур теләгем – мари теле югалмасын, сан ягыннан кимемәсен иде.

ТАТАР ГАИЛӘСЕ: ГАРМУНЧЫ БУЛСА ЯРЫҢ...

Әлбәттә, Чепьяның татар гаиләсе белән дә таныштык. Марилардан аермалы буларак, татарларны табу авыр булмады – халыкның кырык тугыз процентын биредә татарлар тәшкил итә.

Авылда гармун, тальяннар төзәтүче милләттәшебез бар икән. Җәмәгате белән яши, матур гаилә, диделәр. Шулай итеп Гафиуллиннарның йортына килеп туктадык. Рифат абый белән Залия апа кичке ашка җыенып йөри иде.

– И, хәзер инде, гармуннар төзәтәм дип, зурлап сөйләрлегем юк, картлык якадан тота башлады, – дип куйды Рифат абый.

Ир белән хатын илле өч ел бергә гомер итә икән. Өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Бүген исә төп нигездә икәү генә калганнар.

– Әти белән әни Чепьяга 1948 нче елда килеп төпләнгән, – диде Рифат абый. – Әти күрше Әтнә, әни Куныр авылында үскән. Ул заманда күп яшь гаиләләр Чепьяга килеп урнашырга тырышкан, чөнки монда эш урыннары булган. Без укыганда Чепья мәктәбендә бишәр параллель сыйныф була иде. Авыл еллап түгел, айлап үсте. Мин бәләкәй чакта без хәзер яшәгән урам юк иде әле. Мин Чепьяның район үзәге булып торган вакытларын да хәтерлим. МТСның Балтачка күчкән көне дә бүгенгедәй күз алдымда тора: машина-трактор ремонтлый торган зур җиһазларны ат арбаларына төяп алып киттеләр. Ә Чепья базары үзе ни тора иде! Гасырлар буе күрше районнардан да килеп биредә сәүдә иткәннәр. Без бала чакта базар көнне җигүле атлар белән бөтен авыл тулыр иде...

Чепья авылының татар гаиләсе – Залия һәм Рифат Гарифуллиннар белән дә таныштык.

Рифат абыйга үги әниле тормышны да күрергә туры килә: үз әниләре, биш баласын калдырып, кырык ике яшендә бакыйлыкка күчә. Иң кече энеләре тугыз айлык булып кала. Шуның өченме, кечкенәдән тырыш, җитез була. Олы тормыш юлына аяк баскач та сынатмый ул.

– Гел әйтәм, Рифат укыган булса, әллә нинди үрләргә ирешкән булыр иде – белмәгән эше юк аның, – дип сүзгә кушылды Залия апа. – Бер казык та кагылмаган җиргә йорт салып чыктык. 1981 елны шушы нигезгә күчендек. Башта без Чепьяның «Сельхозтехника» биргән фатирында яшәдек. Тик Рифат, тынгысызланып: «Минем үземчә яшисем килә», – диде. Шушы урамнан җир алып, йорт салдык. Ул гел руль артында булды, мин исә күп еллар ашханәдә хезмәт куйдым, җитәкче дәрәҗәсенә кадәр күтәрелдем. Гомер буе намус белән тырышып эшләдек.

Гармун турында сүз булган иде бит. Бишенче сыйныфта укыганда Рифат абый шушы уен коралы белән җенләнә.

– Тик әти гармунны бирми иде, – дип, бала чагына кайтты әңгәмәдәшем. – Алай гына да түгел, ул аны бикләп китә иде. Хәер, мин аны хәзер аңлыйм да. Без бит МТС паркында уйнап үскән малайлар, миңа бөтен әйберне сүтеп карарга булсын. Әти моны яхшы чамалаган. Шуның өчен дә үсмер чакта гармун сирәк эләкте. Беренче гармунымны өйләнгәч кенә алдым.

Ә инде гармун, тальяннар төзәтүгә лаеклы ялга чыккач өйрәнә Рифат абый. Интернеттан да карый, Чепьядагы бер оста янына да барып йөри. Аннары бит сүтеп карау гадәте дә кечкенәдән канга сеңгән була...

Telegram

Чепья авылыннан видеорепортаж белән таныша аласыз.

вконтакте

– Остарып кына киттем дигәндә, сәламәтлек бетеп куйды, – дип дәвам итте Рифат абый. – Ә бу вак эш, күп вакыт сорый. Хатын да, балалар да сүгә, озак утырма, диләр. Югыйсә гармуннар ясар өчен бөтен эш коралларым да бар. Шулай да, илһам килгәндә, эш өстәле янына килеп утырам әле. Кечкенә тальяным да, берничә гармуным да бар, аларда да уйныйм. Зерә рәхәт булып китә. Балачактан күңелгә кереп калган татлы да, тансык та бер шөгыль ул.

ТАРИХ МУЗЕЙДАН БАШЛАНА

Чепья турында сөйләгәндә аның музее турында әйтми калу дөрес булмас. Дөрес, берничә ел элек без бу үзенчәлекле бина турында язган идек. Әмма аннан соң шактый үзгәрешләр, шул исәптән югалтулар булган...

Чепьяның «Халыклар дуслыгы» музее, тыйнак кына әйткәндә, гаҗәеп урын. Күп кенә район үзәкләрендә дә мондый музейлар юк. Биредә барлыгы ун зал бар. Аларның һәркайсы аерым бер тематика, юнәлеш белән эшләнгән. Музейны оештыручы кеше – СССРның халык мәгарифе отличнигы, II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены иясе Гарифҗан Галиев. Музейны илле биш ел дәвамында җитәкләгән тынгысыз Гарифҗан ага, ни кызганыч, 2023 елның март аенда бакыйлыкка күчте. (Безнең журналның тугры укучысы иде – **авт.**).

Шөкер, ул башлаган эш бүген дә дәвам итә, экспонатлар даими яңарып тора.

– «Сельхозтехника» оешмасы Чепья тарихында зур бер урын алып тора, – дип сөйләде

– Чепья тарихында тирән эз калдырган шәхесләребезнең исемнәрен мәңгеләштерәсебез килә, – дип сөйләде музей хезмәткәре Сания Бариева.

«Халыклар дуслыгы» музее хезмәткәре Сания Бариева. – Менә шуны күздә тотып әлеге оешмага багышлап аерым почмак ясадык. Ул чынлап та тарихта гына калган оешма бит хәзер. «Сельхозтехника»да эшләгән ир-атларны музейга чакырдык, мондый чара беренче тапкыр булды. Дистә еллар очрашмаган кешеләр бергә күреште. Бик сөенештеләр! Безнең өчен дә шатлыклы вакыйга булды ул.

– Гарифҗан Галиевны да онытмыйсыз икән, – дим, икенче залга күчкәч.

– Әлбәттә, онытмыйбыз һәм башкача булу мөмкин дә түгел! Үзе исән вакытында ук аңа багышлап аерым экспозиция эшләгән идек, хәзер аны тулыландырдык. Гомумән, Чепья авылы тарихында тирән эз калдырган шәхесләребез күп әле, аларның исемнәрен мәңгеләштерәсебез килә.

Чепьяда бүген 1502 кеше яши, 527 хуҗалык бар. Алда әйтелгәнчә, зур амбулатория үзәге, «Наз» реабилитация үзәге, подстанция эшли. Һәм шәхси эшмәкәрләр киң колач җәйгән: дистәдән артык кибет, берничә даруханә, автосервис, мех эшкәртү фабрикасы, сөт комбинатының филиалы – май цехы, КФХ ачучылар, кыскасы, монда эш урыннары җитәрлек. Иң сөендергәне – аларда җирле халык эшли. Ә дуслыкка килгәндә, телгә, милләткә бүлү юк, дөресрәге, алар бу хакта уйлап та карамыйлар.



Чепьяның «Халыклар дуслыгы» музее – гаҗәеп урын. Күп кенә район үзәкләрендә дә мондый музейлар юк.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Чыганакларга караганда, авыл XVII гасыр азагында, XVIII гасыр башында барлыкка килгән. Чабья һәм Чипья исемле удмурт кабиләләре бу җирләргә килеп урнашкан, дип карала. Исеме шуның белән бәйле. Халык арта барган саен авыл хәзерге урынына күчә. 1745 елда авылда чиркәү төзелә, һәм халык саны тагын да арта.

(«Халыклар дуслыгы» музее хезмәткәрләре биргән мәгълүмат).

Башкалабыз Казанда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл затлары белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

БОРЫНГЫЛЫК БЕЛӘН БҮГЕНГЕ ТОТАШКАНДА



Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Иске Татар бистәсенең Париж Коммунасы, 18 А адресы буенча урнашкан йорт – икенче гильдия сәүдәгәр Вафа Бигәев йорты. Казанлылар белән килгән кунаклар, туристлар аны хәзер күбрәк Чәкчәк музее буларак белә.

КАЗАННЫҢ ЯҢА МИФЛАРЫ

Йорт турында мәгълүмат әллә ни күп сакланмаган, коры фактлар гына диярлек. Әмма ул, һичшиксез, Иске Татар бистәсендәге милли-тарихи агач йортлар ансамбленең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Әлеге урыннар җирле фольклор, сәүдә эше, һөнәрчелек рухы белән өретелгән.

Хәзерге көндә инде бинаны килгән туристларга күрсәтми узмыйлар, чөнки ул – «XIX–XX гасырлар Казан милли мифы»ның бер өлеше, үз эченә риваять-легендаларны да, экиятләрне дә, көнкүреш колоритын да сыйдырган уникаль урын. Мондый яңа сулыш алган урыннар мәркәзебездә бер Чәкчәк музее гына түгел, алар бар һәм барлыкка килүен дәвам итә.

ТАРИХИ ҖИРЛЕК

Тарихи җирлеккә әйләнеп кайтсак, XIX гасыр башына караган ике катлы яртылаш таш йортның беренче катында элеккеге заманда сәүдә рәтләре булса, икенче катта бай үзе яшәгән. Вафа бай вафат булгач, мирас аның улы – шулай ук икенче гильдия сәүдәгәр Галиәскәргә күчә. Инкыйлабтан соң бу йортта коммуналь фатирлар урнаша.

Йортның баштагы планировкасын саклап кала алалар. Биредә ир-атлар белән хатын-кызлар өчен керү урыннары да аерым, йорт үзе дә ике өлешкә бүленгән, бу үз чоры өчен – гадәти күренеш. Ике якның да аерым баскычларын ишегалды ягыннан пыяла белән каплаулы галерея тоташтырган. Ул Венеция тәрәзәсе рәвешендәге, шул чорга характерлы фронтон лоджия белән бизәп эшләнгән.

Фото: Александр Ефремов

Йортның диварлары охра төсенә буялган була, фризлары белән кәрнизләре – ак. Тәрәзә уемнары ярымайны хәтерләткән, шулай ук кызыл һәм зәңгәр розеткалар белән бизәлгән.

2020 елда Бигәев йорты «Том Сойер Фест» волентёрлык хәрәкәте инициативасы белән реставрацияләнде, шулай ук матур җете төсләргә буялды.

ҮЗЕ МИЛЛИ, ҮЗЕ ЗАМАНЧА

Әйткәнебезчә, бүгенге көндә биредә бик үзенчәлекле, Казан туристлары яратып йөри торган Чәкчәк музее урнашкан. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән хәлле татар гаиләсенең көнкүрешен чагылдырган экспозицияләрдә йорт җиһазлары, көнкүреш әйберләре, эш кораллары урын алган.

Биредә халкыбызның иң тәмле, татлы милли ризыклары – чәкчәк, бавырсак белән татар чәе эчәргә була. Чәкчәкне пешереп карарга, күчтәнәчкә сатып алырга мөмкин.

Экскурсияләрдән тыш, музейда милли уеннар, интерактивлар да уза. Татар әкиятләре, татар риваятьләрен ишетергә теләүчеләр, яңа заман Казанының борынгылык белән бүгенгене ничек тоташтыруын күрергә сусаучылар да биргә килә һәм чараларда катнаша ала.

ТАТАРСТАН

журналын кайдан сатып алырга:

ВЕНДИНГ АППАРАТЛАРЫНДА

- **«Мегастрой»**
  Гаврилов ур., 5
  тәүлек буе

- **Казан-2 тимер юл вокзалы,**
  көтү залы.
  Воровский ур., 33
  тәүлек буе

- **«Тукай мәйданы» метро станциясе**
  6:00 дән 00:00 гә кадәр

- **Аэропорт терминал 1**
  тәүлек буе

- **«Дубравная» метро станциясе**
  (Зорге урамына чыгу)
  6:00 дән 00:00 гә кадәр

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

РЕКЛАМА. 16+

«ТАТМЕДИА» АҖ, 420066, ТР, Казан ш., Декабристлар ур., 2, ОГРН 1071690057843